www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 25 (1441) 30 июнь 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

6

Әлмәт дәүләт драма театрының талантлы артисты Дамирә Кузаеваны театр сөючеләр бүген дә сагынып яши.

12

Күрше республика мәркәзе Уфада татар халкының күңеленә хуш килерлек һәйкәлләр бихисап.

17

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты Люция Камалова сәнгате меңнәргә яхшы таныш.

Әйдә, бер хушланып алыйк әле, Җәйдән җиләк тәме килгәндә!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Дондагы Ростов каласында «Вагнер» шәхси хәрби компаниясе кузгаткан фетнә Мәскәү каласыннан 200 чакрым ераклыкта туктатылды.

- Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия Федерациясе Президенты һәм илнең Югары Башкомандующие В.В. Путин позициясен тулысынча хуплап чыкты һәм республика халкын берләшергә чакырды.

- Россия Президенты В.В.Путин Донецк, Луганск халык республикаларында, Запорожье һәм Херсон өлкәләрендә ирекле икътисади зона булдыру турында законга кул куйды.

- Төмән каласының Дзержинский урамындагы «Төзүче» мәдәният сарае каршында татар яшьләренең Сабан туе үтте.

- Казан үзәгендәге Габдулла Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театрында 35 нче юбилей сезонын ябуга багышланган тантаналы кичә булып узды.

- Казан шәһәренең Тынычлык бистәсендә,Аккош күле буенда һәм Дәрвишләр бистәсендә Сабантуй бәйрәмнәре шаулап-гөрләп үтте.

- Татар мәктәпләренә аяк басучы беренче сыйныф укучылары быел яңа «Әлифба» дәреслеге буенча укый башлаячак, анда тартык авазларның әйтелешенә киңрәк урын биреләчәк, шулай ук озын уку текстлары да тәкъдим ителә.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ, әдәбият галиме:

«Без кайчакта массачыл әдәбият әсәрләренең күпләп язылуына да борчылабыз. Әмма мин, андый әсәрләр язылсын, дип әйтәм. Аларның үз укучысы бар һәм алар әдәп-әхлакка тарта. Ул әсәрләрне укыган укучы икенче көнне профессиональ язучы язган көчлерәк әсәрләрне дә укыячак».

СЫНАМЫШЛАР

3 июльдә яңгыр яуса, тагын 40 көнгә сузылачак ● Бер урыннан бер урынга күчеп күк күкрәсә, боз ява ● Иртән чык күп төшсә, көн бик эссе булачак ● Төш вакытында салават күпере чыкса, көн бозыла ● Коеп яуган яңгыр тиз туктый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 03 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 33 минутта** офык артына күмелачәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 30 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **10 минутка** кыскарачак һәм киләсе җомгада, ягъни **7 июльдә 17 сәгать 20 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

30 июнь – нашир, тәрҗемәче, меценат Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы Хәсәнинең тууына 140 ел (1883-1934).

1 июль – драматург, язучы, Татарстанның, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Диас Назыйх улы Вәлиевнең тууына 85 ел (1938-2010).

2 июль – җырчы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Эмиль Госман улы Җәләлетдиновның тууына 90 ел (1933-2023).

4 июль – рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Газиз Гыйльметдин улы Гобәйдуллинга 75 яшь (1948);

– рәссам Радик Вакыйф улы Минһаҗевка 60 яшь (1963).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июльнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(26 июнь-3 июль)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 12 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Фәүзия БӘЙРӘМОВА

БОЛГАР – милли үзәк

Беренче тапкыр Шәһри Болгарда булуыма быел 40 ел икән! Ул вакытта мин, яшь язучы, бергә татар галимнәре белән килгән идем һәм бик тетрәнгәнем хәтердә. Кече манара янында, яшел чирәм өстендә тәсбих тартып утырган ак яулыклы татар әбиләрен күреп, күземә яшьләр килде, алар, әйтерсең лә, хан заманнардан бирле шулай утыра иде… Җимерек Җәмигъ мәчет хәрабәләре, нигезенә мөселман кабер ташлары салынган зур чиркәү, узган гасырларда урыслар дуңгыз ыслау өчен файдаланган Кара пулат-Хөкем сарае, күп тарихи вакыйгаларга шаһит булган Рабига күле… Алар мәңгегә минем хәтеремә шулай кереп калды.

Аннан соң да Болгарга күп тапкырлар килдем – балаларым, галимнәр, кунаклар белән… 1989 елда, Болгар һәм Казан турында тарихи риваятьләргә таянып, мәктәп балалары өчен «Сәнгать дөньясына сәяхәт» дип аталган китап язган идем. 1991 елның җәендә, сәяси ачлыктан соң, Германиядән килеп, минем турыда документаль фильм төшерделәр, кайбер кадрлар Болгарда да ясалды, ничек бар – шулай тарихка кереп калды. Хәзер элеккеге Болгар юк инде, ул танымаслык булып үзгәрде, бу үзгәрешләрнең сөенечлеләре дә, көенерлекләре дә бар. Сөенерлеге – бөек болгар-татар тарихын иң югары дәрәҗәдә дөньяга тәкъдим итәрлек урыныбыз бар, көенерлеге – анда элеккеге милли һәм дини рух юк…

Былтыр Шәһри Болгарда ике тапкыр булдым: май аенда уздырыла торган халыкара фәнни конференциядә, икенчесе – июльнең соңгы көнендә татар конгрессы делегатлары белән. Ул вакытта юл буе автобуста, микрофонга, Идел буенда рәсми рәвештә ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгы турында сөйләп барган идем. Биш гасыр дәүләтле чор, биш гасыр дәүләтсез чор, халкыбызның иман өчен гасырларга сузылган тиңсез көрәше, көчләп чукындырулар, динебезне һәм милләтебезне саклап калу өчен шәһит киткән каһарман шәхесләр, нинди авыр шартларда да бөтен Евразиягә ислам нуры тараткан татарлар турында рухланып сөйләдем. Конгресс делегатларының күбесе бу хәлләр турында беренче тапкыр ишеткән әйтте...

Менә икенче ел инде май аенда Болгарда уздырылган фәнни җыенда катнашам. Ул вакытта атна буе биредә төрле халыкара форумнар, конференцияләр, түгәрәк өстәлләр уздырыла, анда галимнәр, дин әһелләре дә, төбәк тарихын өйрәнүчеләр дә катнаша. Быел да шулай: «Россия мөселманнарының рухи мирасы» дип аталган бу фәнни җыенга Татарстан, Башкортстан, Дагстан, Карачай-Чәркәс, Чечня, Россия төбәкләреннән галимнәр, шулай ук чит илләрдән – Сүрия, Иордания, Мысыр, Индонезия, Бәхрәйн, Төркия, Һиндстан, Үзбәкстан һ.б. бәйсез дәүләтләрдән динебез тарихын өйрәнүче белгечләр килгән иде. Без, татар зыялылары, бергәрәк туплануп, «Түгәрәк өстәл» форматында эшлибез, чөнки без күтәргән темалар уртак, шәхесләр таныш, тәрҗемә дә бар.

Безнең түгәрәк өстәл кысаларында ике көндә утыздан артык кеше чыгыш ясады, шуның бишесе – татарча, берсе – төрекчә, калганнары русча. Татарча сөйләүчеләр – Чаллыдан «Ак мәчет» мәдрәсәсе директоры Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев һәм мин, Төркиядән Анкара университеты докторанты Ильяс Мифтахов (онлайн), Казаннан галим Айдар Хәйретдинов һәм Иж-Бубый авылының музей хезмәткәре Нурия Маннапова. Түгәрәк өстәл эшен алып баручы Сөләйман Рәхимов аралаш сөйләде, шулай ук КФУ талибәсе Гөлназ Хәйретдинова русча-татарча чыгыш ясады. Бу юлы Дагстаннан, Мәскәү, Петербург, Уфа, Ташкенттан күп галимнәр катнашты, алар өстенлек итте, барысы да русча сөйләде, күбесе башка милләт вәкилләре булса да... Ә инде пленар һәм секция утырышларында чыгышлар гарәпчә һәм русча, тәрҗемә исә русчага һәм гарәпчәгә генә булды. Менә бу очракта үзебездән дә күп нәрсә тора. Халыкара форумнарда татарча да сөйләргә мөмкин, тәрҗемә каралган, әмма татарлар үзләре русча гына чыгыш ясый. Монда инде гарәп тә, рус та гаепле түгел, татарча сөйләмәгән татар галиме һәм дин әһеле үзе гаепле! Мондый фәнни җыеннарда күбрәк катнашу, татарча чыгыш ясау, Болгар форумын Идел-Урал, Себер татарларының фәнни җыенына әйләндерү – һәммәсе үзебездән дә тора...

Мин Болгар форумнарында татар тарихчылары һәм язучыларның катнашуын теләр идем. Анда аерым шәхесләр турында да докладлар укырга мөмкин. Үзем узган ел Михаил Худяковның Идел буенда ислам диненең мең еллыгы турында язылган фәнни хезмәтләренә анализ ясадым, быел Габдрәшит Ибраһимның рухи мирасын өйрәнү турында сөйләдем. Түгәрәк өстәл эше барышында Г.Ибраһим буенча ике тәкъдим керттем, беренчесе – ике елга бер булса да «Габдрәшит Ибраһим укулары» уздырырга, икенчесе – аның бөтен дөнья мөселманнары тарафыннан танылган «Ислам дөньясы» китабын татарча чыгарырга. Бу китап Төркиядә, Японуядә, гарәп илләрендә инде кат-кат басылды, бездә дә галимә Асия Рәхимова тарафыннан тәрҗемә ителде һәм 2017 елдан башлап, «Безнең мирас» журналында басылып килә. Г.Ибраһимның китапларын «Болгар ислам академиясе» нәшрияты бастырып чыгарса, милләткә зур бүләк булыр иде...

Быел түгәрәк өстәлдә Ризаэддин Фәхреддин, Зыя Камали, Габдулла Бубый, Закир Кадыйри, Йосыф Акчура, Габдрахман Гомәри, Мөхетдин Корбангалиев, Таһир Ильяси һ.б. шәхесләр турында да бик мөһим чыгышлар булды. Иң авыр вакытларда да милләткә хезмәт иткән, телебезне, динебезне, тарихыбызны саклап калган бу шәхесләр турындагы докладлар соңыннан китап булып та басылып чыгачак. Язучы һәм тарихчы өчен бик кирәкле мәйдан бу! Бу эшләрне оештыручы Сөләйман Рәхимов – милли җанлы кеше, ул татар язучыларының һәм тарихчыларының мондый фәнни форумнарда катнашуына бик сөенер иде. Биредә азмы-күпме милли һәм дини рухны, традицияләрне академиянең ул җитәкләгән Ислам мирасы үзәге саклап тора. Сөләйман әфәнде Болгардагы фәнни җыеннарда төбәк тарихчыларының катнашуын да хуплый. Узган ел да, быел да безнең фәнни конференциядә Әгерҗе районыннан килгән төбәкче краеведлар катнашты, кызыклы чыгышлар ясады. Бу эшне алга таба да дәвам итәргә кирәк, чөнки татар тарихы архивларда гына түгел, менә шул татар авылларында да саклана бит!

Болгар академиясенең эшендәге уңай якларны да әйтеп үтик. Иң тәүгесе – Сөләйман Рәхимов җитәкләгән Ислам мирасы үзәге. Ул, чын мәгънәсендә, мирасханә һәм милли мәгърифәт музее. Биредә халкыбыз гасырлар буе кадерләп саклаган кульязма һәм басма китаплар куелган, аларның иң борынгысы 1482 елда күчереп язылган «Пәйгамбәрләр тарихы», ул фарсы телендә. Күргәзмә-музейда шулай ук милләтебезнең танылган шәхесләре Ш.Мәрҗани, И.Гаспралы, Р.Фәхреддин, Габдрәшит Ибраһим, К.Насыйри, Муса Бигиев, Г.Тукай, Дәрдмәнд, Г.Исхакый, Зыя Камали, Габдулла Бубый һ.б. татар зыялыларының портретлары, аларның хезмәтләре урын алган. Башка музейлардан аермалы буларак, бу ядкәрләр күргәзмәсе галимнәр тарафыннан яратып эшләнгән, С.Рәхимов аларның һәрберсе турында башка бер җирдә дә ишетеп булмаган гаять бай һәм кызыклы мәгълүмат бирә. Шунысы кызганыч, бу тарихи ядкәрләрне биредә укучылар яки фәнни җыеннарда катнашучылар гына күрә ала, халык өчен экскурсияләр каралмаган. Мондый абруйлы уку йортының Казаннан бик еракта булуы да безнең файдага түгел...

Мирасханә белән янәшә бүлмәдә исә борынгы кульязмаларны, тузган китапларны реставрация бүлмәсе бар, ул да Татарстанда бердәнбер икән. Ертылып эштән чыккан, хәрефләре танымаслык хәлгә килгән китап битләрен, биредә чын мәгънәсендә «терелтәләр» – махсус сыекчаларда юалар, чит ил машиналарында киптерәләр, чистарталар, хәрефләп сипиләр... Монда да үз эшен, китапны, татар тарихын, мирасыбызны, фәнне яратучы зур белгечләр эшли.

Болгар академиясенең тагын бер уңай проекты – аның нәшрияты. Ул татар, рус, гарәп телләрендә югары сыйфатлы академик басмалар, фәнни китаплар, җыентыклар чыгара. Болгарга барган саен, бик сөенеп, ул китапларны җыеп кайтам.

(Дәвамы 5 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

ХӘТӘР УЕННАР

Күпләр игътибар иткәндер, соңгы вакытларда зур сәясәттә бәгъзеләр кабат тактик максатлы атом-төш коралы куллану темасын куерта башлады. Сәбәбе – аңа ышыкланып башлаган хәтәр гамәлләренең барып чыкмавы, атом-төш шантажының йогынтысы калмавы. Ә шантаж өчен арена ролен гаммәви мәгълүмат чаралары һәм глобаль мәгълүмат кыры үти. Бу җәһәттән игътибарны әле узган ел ук анда зур шау-шу тудырган бер интервью җәлеп итә. Аны медиакиңлекләрдә мәгълүм шәхес – «Россия в глобальной политике» журналының баш редакторы Ф.Лукьянов (ул 2012 елдан – Россиянең тышкы һәм оборона сәясәте буенча шура президиумы рәисе, күпләр аны «Валдай» халыкара бәхәс клубында спикер һәм ул клубның фәнни эшләр буенча директоры буларак та белә, «Высшая школа экономики» дигән дәүләт тикшеренү университеты профессоры) шундый ук икенче зат – әлеге ВШЭ университетының тикшерүче профессоры Д.Тренин белән үткәргән. «Международное обозрение» («Россия 24») программасы өчен махсус әзерләнгән ул әңгәмәдә (26.09.2022) сүз геосәясәткә курку тойгысын кире кайтару кирәклеге, чөнки атом-төш коралы белән янауны Америкада «блеф» (куркыту өчен кулланылган ялган) буларак кына кабул итүләре, дөньяның исә бары тик курку хисенә генә нигезләнеп корылуы, шуңа күрә (имеш, шул курку хисен кире кайтару аша дөньяны коткару өчен) тактик максатлы атом-төш коралын куллану кирәклеге турында бара.

Хактыр ки, глобаль медиакиңлекләрдә мондый әңгәмәләр сәяси заказ буенча гына барлыкка килә ала. Ә җәмәгатьчелек игътибарын 13 июньдә «Профиль» журналында чыккан «Применение ядерного оружия может уберечь человечество от глобальной катастрофы» дигән мәкалә дә җәлеп итә. Аның авторы С.Караганов та югарыда телгә алынган даирәдән (Россиянең тышкы һәм оборона сәясәте буенча шура президиумының мактаулы рәисе). Тик әлеге мәкаләсендә автор, геосәяси чынбарлыкны бозып күрсәтеп, хәтәр нәтиҗәләргә килә. Россияне исә ул, Көнбатышның хәрби вә сәяси фикеренә ияреп, алдын-артын уйламыйча, атом-төш коралын куллану бусагасын бик нык күтәрүдә, Украинадагы вәзгыятьне дөрес бәяләмәүдә һәм МХОны уңышлы башламауда гаепли, ә геосәяси вәзгыятьне үз файдасына үзгәртү өчен, Көнбатышка каршы тактик максатлы атом-төш коралы кулланырга чакыра. Россия һәм кешелек цивилизациясен дә коткару җаен бу эксперт болай күзаллый: «Придётся восстанавливать убедительность ядерного сдерживания, понижая недопустимо задранный порог применения ядерного оружия. Это морально страшный выбор – мы применяем оружие Бога, обрекая себя на тяжкие духовные потери. Но если этого не сделать, не только Россия может погибнуть, но, скорее всего, закончится вся человеческая цивилизация».

Йә Хода! Кемгә исәп тотып әвәләнә соң моныңише «иблис саташулары»? Әлбәттә, иң элек – эчке аудитория һәм үзләре дә саташу юлындагылар өчен, дип карарга кирәктер. Күренә ки, нинди тозакка килеп кабуларын, ниһаять, Мәскәүдә дә аңлый башладылар кебек. Ә алмашка нәрсә тәкъдим итә соң андый эшем ияләре? Элегрәк (28 майда) «БИЗНЕС Online»га биргән интервьюсында Караганов, Кытай һәм Россия бүгенге катлаулы вәзгыятьтә бер-берсен кулланса да, аларның мәдәни кодлары төрле булу сәбәпле, Мәскәү бервакытта да Пекинга бәйлелеккә төшмәс, дип ышандырган иде. Ә Украинадагы хәрби конфликт хакында инде ул: «Идет война, которая называется специальной военной операцией. Думаю, что исход её в конечном итоге предрешён. Это победа России», – дип тә әйтте. Проблеманы хәл итү юлын исә ул: «Но единственно возможным решением проблемы, которая перед нами стоит, мне кажется, должна быть ликвидация Украины как антироссийского образования и перелом воли Запада к конфронтации», – дип күрсәткән иде. Шуңа күрә «Профиль»дә дөнья күргән «иблис саташуын» инде шул ниятләрен гамәлгә ашыру ысулы дип карарга кирәктер. Ә аннан соң нәрсә булачак һәм Россиягә нишләргә – Караганов инде аларын да ачыклап, «вакланып» тормый. Мәгълүм геосәясәтче Г.Киссинджерны да (ә ул Кырымны Россиягә калдыру һәм Европада тынычлык урнаштыру өчен, Көнбатышка Украинаны НАТОга кабул итәргә һәм Россия белән якынаерга тәкъдим иткән иде) артыгын чәүчәлдәкләнүдә гаепли, ни сөйләгәнен үзе дә аңламый, ди. Ә Россиягә Караганов бары тик Көнчыгышка күчәргә кирәклеген әйтү белән генә чикләнә, шул ук фикерен ул «Профиль»дә дә кабатлый.

Әлбәттә, бу язмаларга игътибар итмәскә дә була. Әмма аларда әйтелгәннәр әкренләп кенә реаль адымнарга күчә бара. Беларусьта тактик максатлы атом-төш коралы урнаштыру – шундыйлардан. Узган атнада Россиядә кылынган «мятеж» омтылышын да атом-төш коралына ия илдәге кискен хәлләргә Көнбатышның реакциясен ачыклау чарасы дип карарга җирлек бар. Тик анда аңа «Россиянең эчке эше» итеп кенә карадылар кебек.

Фоат УРАЗАЙ.

Болгар ислам академиясе абитуриентлар җыя

Болгар ислам академиясе 2023-2024 уку елына магистратура һәм докторантурага абитуриентлар җыя. Документлар 2023 елның 19 июненнән 4 августына кадәр кабул ителә, дип хәбәр итә уку йортының матбугат хезмәте.

Академия дөньяда әйдәп баручы ислам университетлары программалары нигезендә эшләнгән магистратура һәм докторантура программаларын, шулай ук, «Ислам теологиясе контекстында дәүләт-конфессия мөнәсәбәтләре» профиле буенча теологиядән магистратура программасын тәкъдим итә. Укуны тәмамлаган студентлар дәүләт үрнәгендәге дипломга ия булачак.

Студентлар өчен барлык уңайлыклары булган шәхси бүлмәләрдә яшәү, 3 тапкыр туләүсез туклану шартлары тудырылган. Уку барышында чит илләрнең әйдәп баручы ислам югары уку йортларында һәм фәнни-тикшеренү үзәкләрендә стажировка үтү мөмкинлеге бар. Фәннәрне илебезнең әйдәп баручы мөгаллимнәре һәм чит ил укытучылары укыта. Студентларга айлык стипендия каралган. Укуны тәмалаучыларны эшкә урнаштыру гарантияләнә, дип белдерә Болгар ислам академиясе.

Уку йорты җитәкчелеге әйтүенчә һәр ел саен укырга керергә теләүчеләр саны артып бара. Былтыр, мисал өчен, бер урынга дүрт кешелек конкурс булган. Шуны да искәртергә кирәк, укырга керү өчен тиешле югары белем таныклыгы булуы һәм гарәп телен белү шарт.

1 нче биттә – фото «Татмедиа» фотоархивыннан алынды.

Татарстан көрәшчеләре дөнья чемпионы булды

24 июньдә Саба районында көрәш буенча дөнья чемпионаты узды. Чемпионатта 260 көрәшче катнашты. Беренче әйләнешләр «Саба-Арена»да үткәрелде. Финал очрашулары Мингәр авылының Сабантуй урынында үткәрелде. Ир-атлар арасында ун үлчәү авырлыгының барысында да Татарстан көрәшчеләре чемпион калды.

ҖИҢҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕН ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ.

60 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Илфат Миңнегалиев (Россия, Татарстан).
2 урын – Ариз Гусейнов (Азәрбайҗан)
3 урын – Рим Йосыпов (Россия), Давлатер Абдулхакимов (Таҗикстан)

65 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Алмаз Миңнехуҗин (Россия, Татарстан)
2 урын – Диербек Сайдуллаев (Үзбәкстан)
3 урын – Алексей Крайнов (Россия), Абдунами Суфиев (Таҗикстан)

70 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Ислам Фәләхов (Россия)
2 урын – Нихад Рзаев (Азәрбайҗан)
3 урын – Мөхәммәдсалмон Курбонов (Таҗикстан), Денис Николаев (Россия)

75 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Динар Кәримуллин (Россия, Татарстан)
2 урын – Нусрат Йулдашев (Үзбәкстан)
3 урын – Курбонали Охунов (Таҗикстан), Новруз Кокалыев (Төркмәнстан)

80 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Эмиль Мавлин (Россия, Татарстан)
2 урын – Рахмет Галиев (Казахстан)
3 урын – Абдилмалик уулу Жолболду (Кыргызстан), Абдыкапар уулу Доолотбек (Кыргызстан)

85 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Ренас Кәлимуллин (Россия, Татарстан)
2 урын – Муктарбек Мумарбеков (Кыргызстан)
3 урын – Ренат Шәйхетдинов (Россия, Татарстан), Илес Ахмадов (Үзбәкстан)

90 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Раил Сәлахетдинов (Россия, Татарстан)
2 урын – Абдрахман Кункубаев (Казахстан)

100 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Булат Мусин (Россия, Татарстан)
2 урын – Зайлобиддин Артиков (Үзбәкстан)
3 урын – Илдар Моратов (Россия, Татарстан), Марат Шахмаев (Үзбәкстан)

130 кг үлчәү авырлыгы:
1 урын – Радик Сәлахов (Россия, Татарстан)
2 урын – Тәлгат Жиентаев (Казахстан)
3 урын – Айрат Фәтхуллин (Россия, Татарстан), Фирдәвес Фәйзуллоев (Таҗикстан)

130 кг нан югары үлчәү авырлыгы:
1 урын – Ранис Гыйләҗетдинов (Россия, Татарстан)
2 урын – Җамал Фәйзиев (Азәрбайҗан)

Дөнья чемпионаты баш батыры исеменә Радик Сәлахов лаек булды. Аңа автомобиль тапшырдылар.

tatar-inform.ru.

Фото: ТР Көрәш федерациясе телеграм-каналы.

САБАНТУЙ-2023

Үткән якшәмбедә башкалабызда Сабантуй гөрләде. Өч мәйданда зурлап бәйрәм иттек. Тынычлык бистәсендә ул аеруча күңелле узды.

Быел Сабантуй грандиоз булачак, кебек сүзләр бер ай элек йөри башлаган иде. Шуңа да ничек булыр, нәрсә булыр, дигән уй гел күңелне кытыклап торды.Быелгы Сабантуй, чыннан да, истә калырлык булды.

Иртәнге 9да ук Тынычлык каенлыгына халык агыла. Көн җиләс-миләс, болытлы-кояшлы булып торса да, яңгыр яумады. Сабантуй мәйданына керүгә ике яклап ишегаллары тезелеп китә. Ул ишегалларының үзендә – аерым Сабантуй. Һөнәрчеләр үз осталыкларын күрсәтә, аш-су осталары тәм-томнарын тәкъдим итә, авыл йортларын да китереп куйганнар, һәрберсендә сәхнә, кызлары-егетләре, апалары-абыйлары биеп-җырлап кына тора, кайбер ишегалларында күл-елгалар да, фонтаннар да бар.

Керүгә сул яктан иң беренче капка – Арчаларныкы. Капка алдында ук агачтан ясаган Шүрәле каршылап тора. Янына кешеләр җыелган, үтә торган түгел. Нәрсә генә карыйлар соң, дим. «Кодагыйлар килә!» – дигән тавыш ишетелде. Арчалар туй мәҗлесен күрсәтә иде. Бүләкләр, 2 каз тотып, кодалар килде. «Күрегезче, кодагыйның паштеты ничек уңган», – дия-дия, тәм-томнарны каршы алдылар. Аннан хәзрәт килде.

Алар шау-гөр килеп бәйрәм иткәндә, читтәрәк басмада Су анасы алтын тарагын саклап утыра.

Каршы яктагы Кукмаралар ишегалдында шак-шок килгән тавышлар ишетелә. Итекче абый киез итекләр ясап тора. Быелгы җәйгә ышаныч юк, диләр бугай. 10 елга түзәрлек итек булачак, ди.

Яшел Үзән апалары да калышмый: йон эрли, оекбаш бәйли. Икмәк пешерүчеләре чәкчәктән Татарстан картасын ясаган. Анда барысы да саналган: республикада күпме кеше яшәсә, бу чәкчәктә шул кадәр «токмач» бар. Бу татлы иҗат эшен бизәүдә катнашкан Нурсинә Әшрафҗанова сүзләренчә, чәкчәкне 2 көндә эшләгәннәр. «Чәкчәкне пешерүдә 15 кеше катнашты, икәү бизәдек. 1,5 мең йомыркага 100 килограмм он, 50 килограмм бал салып, 80 килограмм майда кыздырылды. Республикада 173 милләт вәкиле яши, шуңа күрә чәкчәкнең авырлыгы 173 килограмм. Республикабызда 4 001 625 кеше яши, бу чәкчәктә шул кадәр «токмач» бар», – дип сөйләде ул.

Биектау районы коймак өстәле корган. Төрле авыл җирлекләрендәге рецептларны да язганнар. Мәсәлән, Биектау авыл җирлеге коймак рецепты: 1 л сөт, 20 гр чүпрә, 3-4 йомырка, тоз, шикәр комы, сода, 100 гр сыек май, он. Әмма да коймаклары-ы-ы! Өстәл артында мичтә учак янып тора.

Ул вакытта иң шау-шулы ишегалды Нурлат районыныкы иде. Чөнки анда кем? Әйе, анда Фирдүс Тямаев. Ишегалды халык белән тулы. «Туп-туп итеп» җырына «фирменный» биюне башкаралар. Артта торган бер абыйның: «Ул былтыр да шулай җырлап чыккан иде», – дигәне ишетелде. Бераздан инде артист төп мәйданда чыгыш ясады.

Бер ишегалдында кулдан ясалган, татар бизәкле яулыклар, сумкаларны карап торганда, бер бала русчалатып: «Әни, татар бизәкләре шундый матур икән. Миңа бу яулык ошый», – диде. Ул бала үзе өчен бер зур ачыш ясаган кебек тоелды. Бу бизәкләр, эмоцияләр 6-7 яшьлек баланың хәтерендә калачак бит инде.

Быел Сабантуйга милли киемнән килергә киңәшләр бирелгән иде. Башларда калфаклар, киемгә эләктергән лалә чәчәкләре, алкалар, түбәтәйләр еш очрый. Камзул кигән, калфак, изү таккан балалар күренә. Кайбер ишегалларында халыкка изүләр өләштеләр. Синтетик тукымага изү рәсеме төшерелгән. Аны бәйләп куйган хатын-кызлар да күренде.

Ул вакытта төп сәхнәдә Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбле чыгыш ясый иде. Сәхнәнең арткы ягы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Игенчеләр сараен хәтерләтә, диварга береккән агач – имән ясалган.

Сабан туеның кереш өлешен режиссер Айдар Җаббаров эшләгән. Анда Сабан туендагы уеннарның килеп чыгышына бәйле риваять күрсәтелде. Мәйдан уртасына ап-актан киенгән бала йөгереп чыкты, аның артыннан әкрен генә Ак Ана килде. Халкыбыз өчен рухи башлык булган Ак Ана халыкка урнашу өчен Идел һәм Чулман елгалары кушылган җирне сайлый. Бу җирне кара көчләрдән, яман ияләрдән арындырырга кирәк була. Кара көчләрне бу җирлектән атларга утырган изге ияләр куып җибәрә. Мәйданга атка утырган җайдаклар чыкты. Ат чабышы әнә шулай килеп чыккан. Бу – изге ияләрнең яман ияләрне куу икән. Аллага шөкер, Казанда ат чабышлары елына ике тапкыр – Сабантуй һәм Республика көнендә булып тора.

Сөңге һәм кылыч тоткан егетләр, укчылар күзгә күренми торган ияләрне юкка чыгара. Бу егетләр чыккач, мәйданга ялкын төсендәге төтеннәр җибәрелде. Әллә тарих, әллә бүгенге көн, дип, кыен булып китте.

Чистартылгач, яман ияләрнең эзе дә калмагач, иң көчле батырлар җирләрне ташлардан арындыра. Гер күтәреп көч сынашу әнә шуннан калган, ди. Аннан соң иң көчле батыр беренче буразнаны ясый. Ясалма ике үгез артыннан кара тасма сузыла. Атлары чын булгач, үгезен дә чынны чыгарсалармы?! Үгез пошкырган кебек итеп, имән тирәсендә ак төтеннәр генә «пошкырып» куйды.

Һәр иртәнге кояшны каршы алучылар булган, ди. Бер егет колгага менә дә, кояш күренә башлагач, халыкка яңа көн туу турында хәбәр итә. Чыннан да колгага менгән ир-ат аска кызыл тасма ташлады. Аннан инде мәйданга яз, җәй, көз кызлары чыгып биеде.

Сәхнәгә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Казан мэры Илсур Метшин, Саха (Якутия) республикасы хөкүмәте рәисе Андрей Тарасенко күтәрелде.

«Сезне чын күңелдән яраткан бәйрәмебез – Сабантуй белән котлыйм. Республикабыз, илебез гөрләп торсын, алга барсын. Былтыр якут халкының Ысыах бәйрәмендә булдык. Сабантуйның матур булуын, әмма анда тарих җимәвен аңладык. Киләчәктә дә гореф-гадәтләрнең тарихын күрсәтербез», – диде Р.Миңнеханов.

Ул оештыручыларга, ишегалларын ясаган районнарга рәхмәт белдерде.

Андрей Тарасенко сүзләренчә, Сабантуй һәм Ысыах бәйрәмнәре бердәмлекне символлаштыра. «Саха (Якутия) һәм Татарстанның дустанә мөнәсәбәтләр бәйләп тора. Сабантуй һәм безнең Ысыах бәйрәме бердәмлек, дуслыкны символлаштыра. Быел беренче тапкыр Казанда Ысыах бәйрәме булды», – диде ул.

«Кадерле казанлылар һәм башкалабыз кунаклары, чын күңелдән Сабантуй белән котлыйм. Балачакта бу бәйрәмне көтеп ала идек, бүген дә шатланып каршы алабыз. Сабантуй безнең тарихта зур урын алып тора, ул – Татарстанның визит картасы», – диде Илсур Метшин.

Җитәкчеләр сәхнәдән төшкәндә, мәйданга Фирдүс Тямаев «Татарлар» җыры белән чыкты. Бер мәйдан биючеләр, өстән яуган ялтыравыклы кәгазьләр, артистның энергетикасы беркемне битараф калдырмады, кемнәрдер торып басып җырлый башлады. Артта русча гына сөйләшеп утырган кызлар да «әй, татарлар» дип җырлады. «Туган тел»не җырларга бөтен кеше торып басты.

Аннан соң сәхнә алдындагы төп мәйдан уеннар мәйданына әйләнде. Халык уеннарга чират тора башлады. Көрәш өчен әзерләнгән урынны халык шунда ук әйләндереп алды. Чиратта балалар да, олылар да – барысы бар. Һәр катнашучыга бүләкләр бирәләр. Ул арада сәхнәдә артистлар чыгыш ясый, трибуналарның бер өлеше бушап калды.

Монда, нигездә, Казанның Идел буе һәм Вахитов районы көрәшчеләре көч сынашты. Лениз Абдуллин батыр калды.

Кемнәрдер инде каеннар төбенә җәймәләрен җәеп куйган да, ял итә. Авыл хуҗалыгы техникасына менеп карарга балалар чират тора. Һәр ишегалды сәхнәсеннән чыгышлар яңгырый.

Ишегаллары ягын урап килгәндә, каен төбендә утыручылар куерган. Бер гаилә җәймәсен әле генә җәеп куйды. Балалар бакчасында эшләүче Алсу Әмануллина үзе дә, балалары да уеннарда катнашкан. Ике пакет бүләк җыйганнар. Ике улы «исәнмесез» дип йөгереп килде.

Чирмешәннән Мидхәт абый көрәш карарга килгән. Үзегез көрәшә идегезме, дигәч: «Мин гомер буе менә болар белән көрәштем», – дип, артта торган авыл хуҗалыгы техникасына төртеп күрсәтте дә елмаеп куйды. Ул да түбәтәй киеп килгән: «Бәйрәмгә гел шулай чыгам», – ди.

Өч бала иярткән, берничә пакет бүләк тоткан апа чыгу юлына бара. Энже апа балалар бакчасында эшли.

– Сабан туена 20 ел йөрибез инде. Бөтен уеннарда катнаштык, ике пакет бүләк алдык. Бүген карап утырган Сабан туен Себердәге туганнарга җибәрдек, аларга шундый кызык. Шунысы да ошады: күпме кеше татар киеменнән, ул бик сизелә. Руслар да, татарлар да татар киемен кигән. Безгә милли кием кияргә, дип киңәш иткәннәр иде. Без генә милли киемнән булырбыз инде, дип уйлаган идем. Ә монда... Колхоз базарында калфаклар беткәндер. Хәзер ел саен шулай булыр, дип уйлыйм. Милли кием киясе килә, ә киеп барырга урын юк. Сабантуй рәхәтләнеп милли кием кия торган урын булыр. Күреп торырсыз: ел саен милли киемнән киләчәкләр, – дип сөйләде ул.

Чыгу ягына, шәһәргә кайта торган автобусларга барганда, гармун тавышы ишетелде. Тавыш алда бара, ерак та түгел. Ул уйнаудан тактады да, арттан бер ир-ат: «Уйна, туктама», – дип кычкырды. Гармунчыны куып тоттым. Аның янында үткән халык, туктап тормый гына, шул көйгә салынган сүзләрне кабатлап уза. Яшел Үзәннән килгән Фәрит абый Хәлиуллин кеше күңелен нечкәртү максатыннан шулай уйнап йөри икән.

Шулай, шау-гөр килеп Сабантуй да узып китте.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.
intertat.tatar.
Владимир ВАСИЛЬЕВ
фотолары.

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Быел Р.Фәхреддиннең «Ислам дине» – «Религия ислам» китабын конференциядә катнашучыларга тараттылар. Бу хезмәт мөфти Р.Фәхреддин тарафыннан 1924-1925 елларда язылган, әмма моңа кадәр беркайда да басылып чыкмаган. Риза хәзрәтнең кулъязмасы гарәп хәрефләре белән факсимиледә, кирилл хәрефләре белән транскрипциядә, теге елларда ук урысчага ирекле тәрҗемәсе кулъязма-факсимиледә бирелгән. Болгар ислам академиясе һәм Уфаның тарих, тел, әдәбият институты галимнәре белән бергә эшләнгән 460 битле бу академик басма дин әһелләре өчен дә, ислам белгечләре өчен дә зур бүләк булыр, дип көтелә.

БОЛГАР – милли үзәк

Быел Болгар ислам академиясе нәшриятында тагын бер затлы китап дөнья күрде, ул – XII гасыр галиме, дин белгече Сөләйман бине Дауд әс-Сувари әс-Саксинның «Бакчаларның гүзәллеге һәм сырхау күңелләрнең юанычы» дип аталган дини-фәлсәфи хезмәте. Ул – Идел Болгары чорыннан безгә килеп ирешкән иң борынгы әсәр, аның кулъязмалары дөнья архивларында һәм китапханәләрендә саклана. Әсәр XII гасырның беренче яртысында башта фарсы телендә язылган, аннан автор үзе аны гарәп теленә тәрҗемә иткән. Татарстан Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, Болгар ислам академиясе белгечләре белән бергә, бу тарихи ядкәрне рус һәм татар телләренә тәрҗемә итеп, 3 томда чыгарган. Бу зур фәнни эш, аның белән дөньяның күп илләрендә файдаланырлар әле.

Күнелгә уелган тагын бер вакыйга – милләттәшебез Гөлназ Исмәгыйлова-Гатиятуллинаның шәмаилләр күргәзмәсе булды. Азнакайда туып-үскән, Казанда төрек-татар лицеен, Төркиядә университет тәмамлаган Гөлназ – бүген бөтен дөньяга билгеле каллиграф. Ул Россия рәссамнәр берлеге әгъзасы, күргәзмәләре Россия, Төркия, Америка, Алжир, Һиндстанда, тагын бик күп илләрдә булган. Коръән аятьләре һәм Пәйгамбәребезнең хәдисләрен кулланып эшләнгән, алтын белән йөгертелгән, җан җылысы белән өретелгән бу шәмаилләр – иң югары сәнгать әсәре, динебезнең сәнгати дәгъватчысы. Гөлназ һәр шамаил янында татарча, русча, кирәк икән, төрекчә, гарәпчә, инглизчә бик мавыктыргыч итеп сөйли белә, аны тыңлагач, динебезнең бөеклегенә, сәнгатьнең илаһи көченә, милләтебезнең талантына тагын бер тапкыр инанасың.

Фәнни жыеннан күңелдә калган төер дә бар. Конференциядә Төркиядән профессор Исмәгыйль Төрекоглы да катнашырга тиеш иде, программада аның «XX гасыр башында татар дин әһелләренең һәм Рәшит Ибраһимның тормышы һәм эшчәнлеге» дип аталган доклады бар иде. Әмма Исмәгыйль бәйне шул көнне Казан аэропортында тоткарлаганнар, Татарстанга кертмәгәннәр һәм кире Төркиягә кайтарып җибәргәннәр. Әле тагын кулына 30 ел буе Россиягә керергә рөхсәт ителми, дигән кәгазь тоттырганнар, ягъни ул яңадан монда 86 яше тулгач кына килә алачак... Мин шул көнне үк Исмәгыйль Төрекоглы белән элемтәгә кердем. Ул үзе дә бу хәлгә бик гаҗәпләнгән, әле ничек кулга алмадылар, утыртып куймадылар, дип сөенә. Югыйсә, Исмәгыйль бәй сәясәттә катнашмый, ул – галим, гомере буе татар тарихын, аның бөек шәхесләрен өйрәнгән, алар турында фәнни китаплар язган академик. Танылган галим Надир Дәүләтнең шәкерте, аның тәкъдиме белән Г.Ибраһимның тормышын һәм иҗатын өйрәнеп, әле 1997 елда ук Анкарада «Себерияле мәшһүр сәяхәтче Габдрәшит Ибраһим» дип аталган фәнни китап бастырып чыгара. Аның шулай ук Йосыф Акчура, Исмәгыйль Гаспралы, Надир Дәүләт һ.б. татар шәхесләре турында да хезмәтләре бар. Үзе әйтүенчә, ул Казанда 25 тапкыр булган, 3 ел анда яшәгән, Казан дәүләт университетының «Тюркология» бүлегендә эшләгән кеше. Һәм менә шундый хәл! Эшләр болай барса, без хәзер Төркиядән өйгә кунак та чакыра алмабыз, үзләре дә мондый илгә килергә ашыгып тормас...

Шуны онытмыйк: Болгар академиясе – Мәскәү проекты ул, идеология, программа, акча да алардан. Болгар академиясе, татар җирендә булса да, бөтен Россия өчен дин белгечләре әзерли. Үзләре өчен кулайны, әлбәттә. Әмма безнекеләр ныграк торса, фән буларак, татар телен, һичьюгы иске татар телен өйрәнүне кертергә була иде. Бер дә булмаса, факультатив, түгәрәкләр рәвешендә булса да шәкертләргә Идел буенда ислам тарихын укытырга, татар халкының бай дини-мәдәни мирасын җиткерергә кирәк. Болгар академиясендә уку-укыту эшләре бары тик рус һәм гарәп телләрендә генә алып барыла, ә фәнни эшләр (докторантура) бары тик гарәп телендә генә язылa һәм яклана икән. Бу хезмәтләр милләткә ничек барып җитсен, аны кем укысын һәм аңласын инде? Ә нигә татарча да язмаска һәм якламаска? Татарстан бит бу! Бездә ике тел дә – дәүләт теле! Укучылар арасында да Кавказ, Урта Азия вәкилләре күп икән, югыйсә, татар җирендәге уку йортында күпчелек татарлар белем алырга тиеш. Һәм шушы белем белән милләткә хезмәт итәргә тиеш! Ә Болгар академиясен бүген татар халкын иманга кайтаруга хезмәт итә, дип әйтеп булмый әле. Бик кызганыч...

Хәер, Шәһри Болгарның үзендә дә әллә ни милли рух юк, анда урыс теле өстенлек итә, ул тарих сатып, акча эшләү урынына әйләнеп бара. Ирешкән хәбәрләр буенча, урыс православ чиркәве башлыгы Кирилл бу көннәрдә Болгарга килгәч, анда музей булып торган чиркәүне яңадан христианнарга кайтару мәсьәләсен күтәргән. Нигезенә мөселман әби-бабаларыбызның кабер ташлары салынган чиркәүне яңадан торгызырга телиләр! Шәһри Болгарда, борынгы Җәмигъ мәчет каршында... Мөселманнарга чиркәү чаңнары астында намаз укырга туры килүе дә бар, чөнки Ак мәчет биредән шактый ерак, күпчелек халык иске мәчет урынында намаз укырга килә иде. Татар халкы элеккерәк елларда Болгарга хәшәрәт сынын куйдырмады, инде монысын да туктатып кала алыр, дип дога кылыйк. ЮНЕСКО тарафыннан тамгаланган урында алар тыелырга тиеш. Шәһри Болгар – милләтебез өчен дә кадерле, тарихи, тамгалы урын булып калсын!

Күренекле сәнгать иясе, Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Дамирә Нәҗмиҗан кызы Кузаеваның тууына 75 ел тулды. Дамирәнең күпчелек иҗат гомере Әлмәт драма театры белән бәйле.

Талантлы кызыбыз Дамирә

Дамирә Нәҗмиҗан кызы 1948 елның 16 маенда Пермь өлкәсенең Барда районы Төнгүк авылында туа. Бала чагыннан ук иҗатка, сәнгатькә тартыла. Авылларында үткәрелә торган концертлардан калмый. Урта мәктәпне үз авылларында 1964 елда тәмамлый. Шуннан соң ук ул махсус белеме булмаган яшьләр өчен Әлмәт театры каршында баш режиссер Г. Юсупов тарафыннан оештырылган студиягә йөри башлый. Анда берникадәр тәҗрибә туплагач, Казан театр училищесының Марсель Сәлимҗанов курсларына укырга керә, аны 1970 елда тәмамлый. Укыганда һәм практика вакытларында ул башкарган рольләр һәркемне сокландыра. М.Сәлимҗанов аңа Камал театрында калырга тәкъдим итә. Әмма Д.Кузаева Әлмәт театры укырга җибәрсен дә, ничек инде анда эшкә кайтмыйсың, дип исәпли.

Кузаева Әлмәттә тиз үсә. 31 яшендә аңа инде Г.Тукай премиясе тапшырыла. Биш елдан соң республиканың халык артисты исеменә лаек була.

Аның геройларына драматизм, кайнар темперамент, гаделлек хас. Училищены тәмамлаганнан соң аның беренче рольләре Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» пьесасы буенча эшләнгән спектакльдә Зөбәрҗәт, И.Абдуллинның «Их, Уфа кызлары» спектаклендә тормыш сөючән Майя образлары була.

А.Салынскийның «Барабанчы» әсәреннән Нила Снижко Бөек Ватан сугышы чорында яшерен эш алып бара, сугыш чоры кешеләрен генә түгел яшерен эш белән шөгыльләнүчеләрнең барысын да гаҗәпләндерә.

1971 елда актриса Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» данлыклы романы белән беренче тапкыр таныша. Шул ук елны ул бу әсәрдәге Алиман образын башкара. Әмма алты елдан соң Дамирәгә спектакльнең икенче редакциясендә төп героиня Тулганай роле тапшырыла. Кузяева сугышта ирен, улын югалткан ана трагедиясен бик оста чагылдыра. Тулганайның зур кош канатларын җәйгән кебек кулларын ике якка сузып тимер юл рельсына егылуы тамашачыны гаҗәпләндерерлек килеп чыга.

Кечкенә,ябык, физик яктан көчсез кызчык икенче бер спектакльдә гаҗәеп куәт иясе Креонга каршы чыга. Рухи яктан ул Антигонны да җиңә. Фикерләренең, эчке кичерешләренең мөстәкыйль булуын күрсәтә. Спектакль геройлары бу очракта актриса рухына бик якын була. Хәтта аларны бер-берсенә тәңгәл дияргә дә мөмкин. Ә менә К. Гольдониның «Трактирщица» әсәрендәге Мирандолина алардан бөтенләй аерылып тора. Ул җитез, шат күңелле.

Үзенең күңеленә бик нык охшаган, якын булган әсәрләрне башкаруы белән Дамирә үзен бик бәхетле саный. Алар исәбенә артист Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәрендә Мәдинә, Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры»нда Тулганай, борынгы грек драматургы Софоклның Ж. Ануйя трагедиясендәге Антигонаны кертә.

Әлмәт театрындагы бу чор иҗади яктан бик уңышлы була. Театрда Кузаева белән кулга-кул тотынышып тагын бер зур талант – баш режиссер Гали Хөсәенов эшли. Гали абый үзенә дә, башкаларга карата да бик таләпчән кеше иде. Без Казан телевидение студиясендә шактый еллар бергә эшләдек. Ул студиянең баш режиссеры, ә мин иҗтимагый-сәяси тапшырулар буенча баш мөхәррир идем.

Биредәге хезмәткәрләр раславынча, Гали абый Әлмәт театрында иҗади мохит тудыра. Кузаева һәм Хөсәенов дусларча бергә җигелеп эшли.

К.Гольдониның «Трактирщица» әсәреннән Мирондолина, Салынскийның «Барабанчы»сыннан Нила Снижко, А. Островскийның «Соң килгән мәхәббәт»еннән Лебедкина, Аяз Гыйләҗевнең «Әгәр бик сагынсаң» әсәреннән Фәүзия, М. Байҗиевнең «Кияү һәм кәләш»еннән Регина, М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» әсәрендә Зөбәрҗәт, Ибраһим Абдуллинның «Их, Уфа кызлары»ннан Майя, Шамил Шаһгалинең «Янгын»ыннан Фәйрүзә – Дамирә башкарган сокландыргыч рольләр.

Тора-бара Кузаевага актерлык һөнәрендә генә казыну тар була башлый. Ул режиссерлык эшенә күчә. 1980 елда Дамирә М. Байҗиевнең «Кияү һәм кәләш» спектаклен куя. Аннары Р. Мингалимовның «Өченче бүлмәдә эт яши» әсәре сәхнәләштерелә. Үзе кебек үк талантлы актриса Луиза Солтанова өчен Кузаева моноспектакль әзерли. Ул Ризван Хәмиднең «Олы юлның тузаны» пьесасы буенча эшләнә.

Әмма бу чорда Дамирә тормышында бик үк аңлашылмый торган хәлләр дә барлыкка килә. Казанга Тинчурин театрына кайтырга тели – барып чыкмый. Мәскәүгә китеп режиссерлык курсларында укымакчы була – кире кагалар. Театрда аның гамәлләрен аңламый башлыйлар. Ире белән дә аерылыша. Кузаева театрдан китәргә мәҗбүр була. Башта мәктәптә, аннары телевидение студиясендә эшләнә.

Күрәсең, яшәү Дамирәне бөтенләй туйдыргандыр, ул 1993 елның 20 декабрендә безнең арадан китеп тә бара. Казанга абыйсы килеп сеңлесенең мәетен туган авылына алып китә. Дамирә туган авылы зиратында җирләнә. Кызганыч, шундый зур талант иясе 45 яшендә бакыйлыкка күчә.

Һәр елны Кузаева туган Төнгүк авылы мәдәният сараенда театр сәнгате конкурсы үткәрелә. Анда яшь талантлар үзләренең осталыкларын күрсәтә.

2016 елның августында Әлмәт театрының художество Советы карары белән спектакльләрдә иң талантлы башкаручыларны ачыклау, актерлык һөнәре дәрәҗәсен күтәрү ниятеннән Дамирә Кузаева премиясе булдырылды. Ул ел саен иң сәләтле артистка тапшырыла.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

● «Их, Уфа кызлары». (И.Абдуллин).

● Дамирә Кузаева (сулда) сыйныфташы белән. Төнгүк авылы. 1960 нчы еллар.



Ренат ХАРИС

КАЗАН «МӘРЬЯМ АНАСЫ»

(Поэма)

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып.
Г. Тукай

– Күзләр ничек? Бераз яхшыргандыр –
дәваландың инде ничә ай, –
диеп шылтыратты Мәскәвеннән,
хәл белешеп, дустым Николай...

...Заманында, ул кунакка килгәч,
мин, Казаным белән мактанып,
йөрткән идем аны укый-укый
һәрбер мемориаль тактаны.

Без Мәрҗани мәчетен дә күрдек,
барып килдек Раифага да...
Студент-юлбашчы[1] да, геометр[2] да
калмадылар кебек ягада...

– Могҗизалы Казан иконасын
бик күрәсем килә, – диде ул...
Шактый хәтәр операциядән
чыгып җиткән генә иде ул.

Ул ышана иде булса кирәк:
фәкать Казан Мәрьям Анасы
авыр чирдән арындырыр диеп,
бирер диеп изге дәвасын.

Ул көннәрдә Казан иконасы
Ватиканда, Папа кулында,
газапланып, форсат көтә иде
чыгар өчен кайтыр юлына.

Әле булса җаным сыкрап куя:
аһ, телгән үти алмадым...
Һәм бүген дә, тавышын ишеткәч,
хәтеремне сызлау ялмады...

Дустым котелмәгән киңәш бирде,
сайлый-сайлый әйтер сүзләрен:
– Беләсеңме, Казан иконасы
күзсезнең дә ача күзләрен,

ышан әле аның тылсымына,
могҗизасын сына үзеңдә –
күзеңдәге проблемаларның
калмаячак хәтта эзе дә...

Мине яшен суккан кебек булды –
тел очыма утлар кабызды...
Николайга мин рәхмәтләр әйттем,
ярсуыма салып авызлык.

– Православный түгел бит мин, – дидем,
ярдәм итмәс миңа иконаң,
чөнки һәркем үз Алласы гына
аны аңлый диеп укына.

– А, Бог един! – диде дустым шунда,
һәм башкага борды сүзләрен...
Мин уйлана калдым... Әкрен генә
авырайды авыру күзләрем.

Табиб биргән дәва тамчыларын
чирле бәбәгемә тамыздым.
Чытылдылар күзләр... Кара бушлык
эче йолдызларын кабызды.

Йомылдылар күзләр... Чиксез Галәм...
Күңел күзем белән күрәмен –
Казан иконасы, экран булып,
очып йөри Җиршар тирәли[3].

Ул монитор тарих хәтеренә
минем зиһен аша тоташкан.
Тарих мизгелләре, кино булып,
агып тора анда тоташтан.

*

Кузьма Минин Түбән Новгородта
җыеп алган халык тупламы,
һәм илаһи көчле корал итеп,
Казан иконасын тоткан ул.

Урыс, татар, чуаш, мари, мордва,
удмурт иңен иңгә терәткән –
православлар белән мөселманнар,
мәҗүсиләр бара бер рәттә!

Казан иконасын тоткан ташкын
азат итә Мәскәү калыгасын –
полякларның, Лжедмитрийларның
эзе түгел, исе калмасын...

Ялган патша кача карак кебек,
илне талап, җирне яндырып...
Канлы эзен аның юып сөртә
Россиянең карлы яңгыры...

Казан иконасы шул вакыттан
күчермәләр булып ишәйгән.
Аны тотып барган яу юллары
дан эзләре белән түшәлгән!

*

Полтавада швед гаскәрләре...
Кошлар сайрап торган тын иртә...
Пётр Первый авыл чиркәвеннән
Казан иконасын китертә.

Пётр үбә Казан иконасын,
ярдәм сорый Мәрьям Анадан:
– Салып таптыйк Карл Уникене,
Россиягә ялыйк янә дан;
Мәскәү юлын мәңгегә онытсын,
уйларга да хәтта базмасын;
сатлыкҗанга таянган Карл да,
Мазепа[4] да алсын җәзасын...

Һәм ишетте аны Мәрьям Ана –
калфак булып ал нур чәчрәде,
сыйпап куйды сабые Гайсәнең
Галәм төсле кара чәчләрен.

*

Петербурда, Казан соборында,
канкоешлы күпме юл узып,
Мәрьям Ана фатихасын сорый
башкомандующий Кутузов:

– Күз чокырым аша пуля үтте –
саклап калдың күру сәләтен;
Наполеонны куар вакыт җитте –
Россиянең шөһрәт сәгате!
Бу юлы да минем җиңү юлым
синең фатихаңнан башлана.
Бу юлы да, изге Мәрьям Ана,
ярдәмеңнән безне ташлама!..

Һәм ишетте аны Мәрьям Ана –
калфак булып ал нур чәчрәде,
сыйпап куйды сабые Гайсәнең
Галәм төсле кара чәчләрен.

Ярдәм итте Казан иконасы
ватан өчен изге бу эштә –
дәрья булып килгән Наполеон,
кайтып китте сап-сай инешләй...

*

Балкып алды экран... Үткәннәргә
яңа манзаралар өстәлде...
Бөек фельдмаршалны алыштырды
генералиссимус Сталин...

Йөзе кырыс... Ыргылышка әзер
бөркет канатыдай кашлары...
Күздә борчу – чынлап тамы немец
таптар Кызыл мәйдан ташларын?..

Сталинның хәтеренә килде
Наполеон, сөмсез поляклар...
Ә бу шашкан фюрер афәтеннән
Мәскәү кремлен соң кем яклар?..

Дошман инде кырык чакрымда...
Күз алдына килде Кутузов.
Фили[5] авылында хәрби шура –
бәхәс бара анда пыр тузып:

бирергәме вакытлыча гына
башкаланы дошман иркенә?..
Генераллар, уйларыннан куркып,
матур чатка карап, төртенә...

Матур чатта Казан иконасы –
Мәрьям Ана нурга төренгән...
Ныклы карар иңә Верховныйга...
Һәм ул телефонга үрелә.

Үзе уйлый: чиркәү, мәчетләрне
күпләп кырдым, ләкин сугышта
корал гына түгел, Ышаныч та
хаклы эштә илгә булыша.

Башы онытса да поп булырга
җыенганын бала чагында,
күңел көзгесендә шул омтылыш
авыр вакытларда чагыла...

Аю адымыдай йомшак тавыш
телефонга боерык пышылдый:
– Мәскәү күгендәге крестный ходка
берәр епископ та кушылсын,
үзе тотсын Богородицаны;
кирәк булса минем самолёт,
ул да очсын – тик тормасын зерә
ил сакчысы булып саналып...

Һәм икона оча – Мәскәү күген,
гаскәрләрнең рухын ныгыта!..
Һәм чигенә фашист – адымнарын
килгәндәгедән дә тиз тота!

Һәм сыпырта тәкәббер Бонапарт,
Лжедмитрийлар салган сукмактан –
түзә алмый безнең яу утына,
Суык бабай суккан тукмакка...

*

Күзләремне мин ачарга куркам...
Юк, курыкмыйм, көтәм могҗиза –
укый алмый, шигырь яза алмый,
ничә айлар чигәм мин иза!..

Телевизор карый алмыйм рәтләп...
Колак кына җитми кешегә.
Дөнья йөзен бераз күрми торсам,
күңел күкси, җаным күшегә...

*

Нидер салып, күзне туңдырдылар...
Күңел күзем ачык... Күрәмен:
Казан иконасы очып йөри
ничә еллар Җиршар тирәли

халыкара космик корабльдә!
Шәт шуңардыр әле тынычлык
Җирдә Шәйтан, әнә, фашистланып,
чайкаса да хәтәр кылычын,

Аллаһ күрми, диеп уйлап, Шәйтан
ил өстенә илләр өстерә,
кача-поса, җен-пәриләр җыеп,
Армагеддон[6] явы үстерә.

Богны оныткан ул, Аллаһны да!
Будда да юк аңа, Яхве дә –
үзе кылган һәрбер җинаятьне
юратырга тели яхшыга.

Үзе җиңәсенә ышанган ул –
күңеленә кертми пошаман,
һәм, үз башын долларына тыгып,
исән калырына ышана.

Ә Җир тирәсендә ничә еллар
Казан иконасы оча бит!
Бәлки, шуңа кабынмыйча тора
дөньякүләм сугыш учагы...

*

Казан иконасын барып күрдем...
Шәм куймадым – ахры, кыймадым,
мин – мөселман – аны, христианны,
рәнҗетермен диеп уйладым.

Бар кылучы бердер... Бәхәсләшмим!..
Ә «иман» һәм «вера» бер микән?..
Мин төшендем: алар – игез, әмма
җаның гына аңлар сер икән!..

Кемнәргәдер серне Аллаһ ача,
кемнәргәдер аны Бог ача!
Икесе дә, берсен берсе аңлап,
яшәделәр миңдә моңача...

Тукайда да, Пушкин, Гётедә дә
Толстойда да диннәр – янәшә!..
Хәтта Чыңгызханда диннәр тыныч,
тату күрше булып яшәгән...

Диннәр тату булса, илләр тату,
тату яши илдә халыклар!
Бу – тарихи хаклык! Аннан өстен
Җирдә тагын нинди хаклык бар?!

Казан кирмәнендә Колшәриф һәм
Благовещение храмы
җаннар берлегенә үрнәк булып,
торалар ич нурга уранып!

*

Донбасс солдатлары хат укыйлар
окопларда, танк эчендә...
Балаларның ихлас теләкләре
әверелә гаскәр көченә.

Бер кызчыкның язган хатын күрәм –
кем торгандыр аны өйрәтеп –
ак кәгазьнең өске почмагында
Казан иконасы сурәте:

Мәрьям Ана сабые Гайсәгә
калкан итеп җылы кочагын,
әйтерсең лә аны саклап тора,
кире кагып афәт пычагын.

Дулкынлана солдат!.. Улниндидер
былиналардагы хис белән
хат сүзләрен, снарядлар итеп,
ыргылдыра дошман өстенә.

Ә бер хатта, әнә, Сөембикә –
ярымайлы кызыл манара –
аны күргәч, татар солдатының
дошманнарга үче кабара...

Бер вертолёт һава сугышыннан
кайтып төште... Корал алганда
күреп калдым «Аллигатор» эчен –
Казан иконасы анда да...

Запастагы офицер энем дә
еш Донбасста була... Аны да
кайсысыдыр илаһи көчләрнең
саклап тота үзе янында...

Окопларда атеистлар булмый!
Бөтен диннәр бер үк тәхеттә!
Һәр солдатның ирешәсе килә
«Исән калдым!» дигән бәхеткә...

*

Хирург өстәлендә ярты сәгать
могҗизалы гомер кичердем...
Күңел күзем шул вакыт эчендә
чордан чорга мине күчерде.

Могҗизага ия микән әллә
Николайның ихлас сүзләре –
сәяхәттә миңа юлдаш булды
Мәрьям Ана, аның күзләре...

Колагыма кемдер «Ля хәүлә...» дип,
пышылдады Коръән сүрәсен...
Минем белән изге сәяхәттә
фәрештәләр йөрде, күрәсең...

Мәрьям Ана пышылдады мәллә
изге Коръән сүзен? – димен мин –
ике диндә бер үк пәйгамбәрләр,
бөтен Галәм өчен Бог един!..

«Тәмам!» дигән тавышны ишеттем...
Әллә уяу, әллә төшләнү –
мин йолдызга менеп җиткән идем,
хәзер кая егылып төшкәнмен?

Беравыкка аңышмыйча тордым –
нәрсә тәмам?.. Әллә сугышмы?
Бугазымны ярып чыга язды
күкрәгемне кыскан сулышым...

Һәм уяндым җанда «Урра!» дигән
татар сүзе – бөек гөрелте –
кырык бишнең Тугызынчы Мае
кайтавазын миндә терелтеп.

Урра! кычкырасым килде минем,
тик өлгерә генә алмадым...
«Күзеңне ач!» диде җылы тавыш...
Күзем ачтым... Шунда аңладым:

күз хирургы эшен тәмамлаган!
Бу да – шатлык! Шәхси булса да!
Бу да – җиңү, чөнки юк ителде
яктылыкны япкан бусага.

Олырагы булыр җиңүнең дә,
сүнәр, сүнәр сугыш учагы –
космик корабльдә Җир тирәли
Казан могҗизасы оча бит!

Ышанырга кирәк! Ышанырга
барлык илаһилар куша ич!
Сүзебездә генә түгел, күзебездә,
эзебезгә булсын Ышаныч!

*

Операциядән палатага
килеп кенә җиткән чагында,
кесә телефоным чытырады,
сискәндереп мине чак кына...

– Күзләр ничек? – диеп, үзгәчәрәк
Николай дус хәлне белеште,
әйтерсең лә мине дәвалауда
аның да бар иде өлеше.

Ә бит операция буласын
белгертмәгән идем аңа мин.
Кайчан, каян, кем аркылы белгән –
әлегәчә шуны аңламыйм.

Әйтерсең лә махсус дрон аша
ул күзәтеп торган эшемне...
Мин ышанам хәзер – могҗиза бар
йөрәгендә кайбер кешенең!

– Әйбәтләнә, – дидем Николайга, –
сабыр итәсе бар чак кына...
– Әйбәтләнер – өченче көн генә
мин шәм куйдым синең хакыңа
Кызыл мәйдандагы Казанский
соборындагы Изге Анага, –
диде Николай, һәм «Бог един!» дип,
беркетеп тә куйды яңадан.

Кем дәвасы, кем догасы икән
минем яклы булып көрәшә?!
Ышанычым булды – Ышанычта
дога белән дәва берләшә.

*

Ватан тарихына үз исемен
җаны белән яза башкалам!
Россиянең бөек җиңүләре
Казан исме белән башланган.

Бусында да элеккечә булыр –
күңел күзем белән күрәмен:
Казан иконасы Мәрьям Ана
әйләнә ич Җиршар тирәли.

Кайсы гына пәйгамбәр телендә
инсәләр дә изге догалар,
Җир шарына илаһи ышаныч,
якты өмет булып йогалар!..

Изге Казан иконасы белән
безнең горурлану хаклыдыр...
Үз исемен бирде аңа Казан –
шәт, Казанны шул да саклыйдыр...

13 ноябрь -2 декабрь, 2022 ел.

---

[1] Казан университеты студенты В. Ульянов-Ленин һәйкәле.

[2] Бөек геометр Н. Лобачевский һәйкәле.

[3] 2011 елдан бирле иконаның бер күчермәсе халыкара космик корабльнең Россия сегментында.

[4] И. Мазепа – Полтава сугышы алдыннан Пётр I-гә хыянәт итеп, швед короле Карл XII ягына күчкән Запорожье гетманы.

[5] Фили – 1812 елда Бородино сугышы алдыннан хәрби совет узган авыл.

[6] Армагеддон (Библ.) – ахырзаман алдыннан яхшы көчләр белән яман көчләр сугышачак урын.

Жаны-тәне белән укытучы ул. Ярты гасырдан артык гомерен балалар тәрбияләүгә, укытучылар әзерләүгә, югары белем мәктәбен үстерүгә багышлаган, шушы юнәлештә күп законнар башлангычында торган гаҗәеп акыллы, зиһенле, затлы шәхес. Бөтен теләге, уй-хыяллары – мәктәпне яхшырту, яңарту, укытучыларның имин тормышын тәэмин итү, укучыларны шәхес буларак ачып, яхшы кешеләр тәрбияләү. Без Башкортстан Дәүләт Корылтаеның Мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт комитеты рәисе Раил Әсәдуллин белән аны борчыган темаларга җанлы әңгәмә кордык.

ТӘРБИЯ –

– Раил Мирваевич, Сез Чишмә районының кечкенә генә Чишмә авылында туып-үскәнсез. Авыл малае бәләкәйдән укытучы булырга хыялланды микән?

– Без гаиләдә өч малай үстек. Авылда әнинең өч улы бар: берсе – инженер, икенчесе – агроном, өченчесе – Раил, дип көләләр иде. Бәләкәйдән укытучы булырга теләдем, дип әйтә алмыйм. Хыялым гражданнар авиациясендә штурман булу иде. Штурманнар әзерли торган вузга конкурстан үтмәдем. Башкорт дәүләт авыл хуҗалыгы институтына киттем, ләкин имтиханнарга әзерләнергә вакыт җитмәде, агрономия факультетына янә конкурстан үтә алмадым. Йөгердем автотранспорт техникумына. Берике көн укып йөрдем дә, кире авылга кайттым. Югары белем алу турында хыялым көчле иде. Безнең гаиләдә югары уку йортында белем алу һәм, әтием әйтмешли, «авылда һәм районда хөрмәтле кеше булу» мәҗбүри шарт һәм тормыш стратегиясен сайлау факторы булып торды.

Армиягә кадәр Келәш мәктәбендә укыттым. Бүген: «Күпкырлы укытучы идем: бер елда физкультура, хезмәт, тарих, сызым, рәсем дәресләрен алып бардым», – дип үз-үземнән көләм. Ләкин берчакта да андый «универсал» укытучы булырга теләмәс идем.

Әйе, мин балалар белән уртак тел таба алдым, мөгаен, алардан бик азга гына өлкән булуым аркасындадыр. Армиягә киткәндә, балалар сигез чакрым озата барды. Армиядән бер хат язган идем, алардан көненә унлап хат ала башладым. «Абый, кайтыгыз!» – дип язалар иде. Шушы һәм мәктәптәге искиткеч яхшы укытучыларымның үрнәге миңа педагогиканы сайлавыма йогынты ясагандыр. Армиядән кайткач, игълан күреп калдым: «Башкорт педагогика институты химик-биолог буенча белгечләккә студентлар кабул итә». Мин биология, химия, физиканы яхшы белә идем, урыс теле генә авыррак булды. Өч фәнне дә «5»кә биреп, укырга кердем.

Укып бетергәч, районга кайтырга ниятләдем, ләкин пединститутта комсомол комитетында эшкә калдырдылар. Ул чакта гаилә, ике бала бар иде инде. Планнарны яңадан карарга туры килде. Вузда калып, фән кандидаты булмау минем планга керми иде.

– Гомерегезнең күпчелек өлеше педагогика институты белән бәйле. Сез гади укытучы, вуз ректоры булдыгыз, әле депутат эшчәнлеге алып барасыз. Аларның кайсы якынрак?

– Мин педагогика университетында барлыгы 52 ел: 13 ел – ректор, 12 ел – проректор, 11 ел кафедра мөдире булып эшләдем. Әле дә укытам, фән белән шөгыльләнәм. Комсомолда, кафедрада эшләгәндә диссертация яздым. Авырлык белән якладым. Акча юк иде. Менә иртәгә чираттагы 26 нчы китабым кайта. Монысы очерклар һәм мәкаләләр җыентыгы – «Образование для будущего» дип атала. Минем кандидатлык диссертациям дә, докторныкы да укытучының субъект буларак үсешенә багышланган. Ягъни мин – укытучылар әзерләү буенча белгеч. Һөнәр буенча да, фән буенча да.

Соравыгызга килгәндә, аларның барысы да якын. Ахыр чиктә, минем бөтен эшчәнлегем укыту, укытучылар белән бәйле. Шөкер, гомерем дәвамын да Укытучыга, аның буыннар һәм тарихлар арасында бәйләнеш булдыру бурычын үтәгән һөнәри эшчәнлегенә хезмәт итү мөмкинлеге булды.

– Сез җитәкчелек иткән вакытта Башкорт дәүләт педагогика университеты бик зур дәрәҗәләргә иреште. Бу Сезнең хезмәт җимешегез, Сезнең өлешегез, дияр идем. Моның сере бармы?

– Минем өлешем тиешле акыллы кешеләргә таяна алуымдадыр. Яхшы команда туплауда. Анда яхшы кешеләр эшли иде. Профессорлар һәм укытучылар белән каты фикер алышуларда, бәхәсләрдә, алар белән бергә булачак укытучының шәхесен формалаштыру стратегияләрен билгеләп, мин педагогиканың чын мәгънәсенә, идарә итү серләренә төшендем. Үз эшемне боерыклар бирү юлы белән төзи алмадым, чөнки кул астымдагыларның күбесе минем укытучыларым иде, ә башкалар белән бергә студентлар эскәмиясендә һәм аспирантурада фәннәрнең асылына төшендем. Мин алардан үтенә, аларны инандыра, алар белән бергә проблеманы хәл итүгә кушыла, алар алдыннан бара алдым. Шул рәвешле табигый рәвештә вузның автономиясе мәсьәләсе килеп басты. Мин коллективта булган яхшы якларны күрә алдым һәм шуны үстерергә тырыштым. Ректоратта күп нәрсәләргә интуиция аша төшенә һәм проблемаларны хәл итә, дип еш кына минем өстән шаярталар иде.

Интуиция генә түгел, миңа тәүлекләр буена традицияләр һәм новацияләр арасында авыр сайлау ясарга, шулай ук вуз эшчәнлеге буенча коллегаларыма, яңа карарлар моңа кадәр булган укытучылар әзерләү практикасын бозмаячак, дип исбатларга туры килде. Ректор булган елларда публикацияләр, чыгыш ясаулар, китап язу өлкәсендә мин университет профессурасы арасында соңгы урында булмадым. Ректор менеджер гына түгел, ул галим дә. Мин Диссертация советын да, үзем нәшер иткән журналны да җитәкләдем. Бу катлаулы булды, вакыт җитмәде, шуңа да төннәрен эшләргә туры килде.

Югары мәктәптә иң зирәк кешеләр утыра. Югары мәктәп ул – хәзинә, байлык, акыл. Аның белән командалык итәргә ярамый, аны тыңларга гына кирәк. Бөтен кешеләр дә докторлык диссерациясен язып, профессор була алса, барысы да профессор булыр иде. Ә бит алар санаулы гына.

Интуиция дә булгандыр, тәҗрибә дә булды. Миңа Мәгариф һәм фән министрлыгы белән уртак тел табып эшләргә насыйп булды. Министрлар белән яхшы элемтәдә идем.

– Заманында Башкорт дәүләт университеты белән Башкорт педагогика институтын кушу турында җитди сүзләр йөрде. Сез моңа катгый каршы булдыгыз. БДУ БДПУны «йотар» дип уйладыгызмы?

– Аларны берләштерү бөтенләй ике төрле вузны берләштерү булыр иде. БДУ – фундаменталь югары уку йорты, БДПУ – гамәли вуз. Тагын шунысы: классик университет тәмамлаган кешеләр мәктәп турында хыялланмый. Алар җитештерү, зур фән турында хыяллана. Педагогик һөнәр сайлаган абитуриентларны башка мотив аерып тора. Мәктәпкә балаларны чыннан да яраткан кешеләр генә бара. Укытучының шәхес сыйфатларын гармонияләштерүче һәм педагогик эшчәнлекнең сыйфатын билгеләүче шундый дәртләндергеч һәм бер үк вакытта интеграцияләү көче булып балаларга мәхәббәт, мәктәптә эшләргә теләк, киләчәк буынны тәрбияләү һәм укыту тора. Шуңа күрә БДПУдан соң мәктәпкә кайтучылар күп.

– Бүген укытучылар мәктәпләрдә кәгазь эшенең күплегенә, бюрократиягә зарлана. Күпчелек шуңа түзә алмый эштән китә. Бу хакта фикерегез?

– Бүген мәктәптә биш төрле документ булырга тиеш, аннан да күбрәк түгел. Бу хакта В.Путин указы, федераль дәрәҗәдә закон бар. Мәктәпнең проблемалары күп. Иң җитдие – мәктәпкә ул мохтаҗ булган акчаны бирә алмау. Шулай да мин үземнең хезмәт юлымны бик оптимистик рухта тәмамлыйм. Ике ел рәттән без мәктәпләрне капиталь ремонтлауга зур суммада акча алабыз. Совет чорында төзелгән мәктәпләр шул акчага ремонтлана. Авылларда хәзер иң матур бина – мәктәп. Алар шушы өлкәгә бүленгән бик күп акчалар нәтиҗәсендә яңара. Элек ел саен бөтен системага капиталь ремонтка 600 миллион сум акча бүленгән. Ә былтыр 63 мәктәпкә 3 миллиардтан артыграк ала алдык. Быел 77 мәктәпкә 4 миллиард 200 миллион сум биреләчәк. Болар – федераль, төбәк һәм муниципаль акчалар. Илдәге «Яңа мәктәп» проекты формасындагы халык программасы гамәлгә ашырыла. 2025 елга кадәр без 400дән мәктәпне ремонтларга тиеш. Бу – Башкортстан мәктәпләренең өчтән бере. Бу – укытучы хезмәттәшләрем өчен зур шатлык.

Мәктәпләрнең яңаруын зур канәгатьлек белән күзәтәм. Әйтик, күптән түгел Стәрлебашка бардык. Анда бәләкәй дүрт мәктәп ремонтланды. Шул авылларга балалар һәм аларның ата-аналары кире кайта.

Проблемалар да бар: укытучыларның хезмәт хакы югарырак булырга тиеш. Минем өчен тагын да бер җитди мәсьәлә: мәктәпкә яшьләр килми, шул хафага сала. Штат расписаниесенең классик структурасы мондый булырга тиеш: 25 проценттан да ким булмаганча – яшьләр, 25 проценттан да күп булмаган – өлкән яшьтәге укытучылар һәм 50 процент урта буын. Бездә яшь укытучылар бүген нибары – 3-8, өлкәннәр 40-50 процент.

– Укытучының тәҗрибәсе никадәр зуррак, балалар өчен шулкадәр яхшырак түгелмени?

– Мәктәптә стажлы укытучы булу яхшы, әлбәттә. Ә алар күп булса, буыннар аша күчәкилүчәнлек һәм бәйләнешләр югала, чөнки тормышка төрлечә караш, төрле кыйммәтләр. Яшь укытучы белән балалар күпкә кызыклырак аралаша. Яшьлек һәрвакыт инновацияләр белән бәйле, аның мәдәнияте икенче төрле. Бу – культурологлар, социологлар тикшеренүләре. Ягъни, балаларга үткәннәр белән килешмәүчәнлек хас, алар һәрвакыт яңарышка омтыла. Мәктәптә тормышның яңа чынбарлыгын инновацияләр һәм адаптация белән тәэмин итүче механизмнар корылмаган. Үсеш күп очракта яшь кешеләргә бәйле. Әлбәттә, традицияләр тәҗрибә белән бәйле, анысы да бик мөһим, әмма алар да яңарып то-

АВЫР ГАМӘЛ

рырга тиеш. Ә без производство һәм технологияләр биш ел элеккегә караганда да күпкә тизрәк алмашынган чорда яшибез. Тикшеренүләр күрсәтүенчә, 5 елдан соң бүген булмаган яңа белем бирү технологияләре барлыкка киләчәк һәм алар өстенлек алачак. Киләчәк кебек берни дә тиз һәм интенсив картаймый. Бу бик гаҗәп бит.

Без бүген укытучыларны типик стандарт ситуацияләрдә эшләргә өйрәтәбез, ә хәл стандарт түгел. Шуңа күрә белем бирү траекториясе башка булырга тиеш. Ә тәҗрибәле укытучы элеккечә эшләргә күнеккән. Югыйсә, яңа техника, компьютерлар бирәбез, социум үзгәрә, шуңа ярашлы көн кадагына суккан яңа педагогик технологияләр барлыкка килергә тиеш. Иң мөһиме – баланың эчке дөньясын аңлау, аның потенциалын ачу. Без аны ачарга, энергиясен чыгарырга мөмкинлек бирергә тиеш. Ә без аңа белемне өеп тутырабыз. Яшьләрнең «куллары гына тиз» түгел, фикерләве дә, үз-үзен тотышы стратегиясе дә тиз адымнар белән алга атлый. Шуңа бүген мәктәпкә яшьләр килү бик мөһим. Аларны хезмәт хакы җәлеп итәр иде, ләкин бүген эш башлаган укытучы 18 мең сум акча ала. Менә без комитетта укытучыларның хезмәт хакы структурасын алмаштыру зарурлыгын билгеләдек. Социологлар бәяләвенчә, бүген ил халкының 65 проценты укытучы һөнәрен хөрмәткә лаек булганнар исемлегенә кертми. Укытучыларның 39 проценты гына булганыннан канәгать. Кабатлап әйтәм, укытучының хезмәте лаеклы бәяләнергә тиеш.

Тәҗрибәле укытучыларга, яшь педагогларның остазларына зур рәхмәт. Аларның күпчелеге мәктәпсез яши алмый. Алар – чын укытучылар. Без – өлкән буын кешеләре – үткәннәр белән яшибез. Ләкин мәктәптә яшь укытучылар кирәк, аларның менталитеты башка, алар бүгенге һәм киләчәк белән яши. Бу – бик көчле дөньяны кузаллау. Мәгълүмат күплеге һәм технологияләр үсеше югары һөнәри белем һәм компетенцияләргә ия булган яшь белгечләр таләп итә. Мәктәпне традицияләр һәм инновацияләрнең күчәкилүчәнлеге үстерә. Без шушының белән шөгыльләнергә тиеш.

– Хәзер балалар да усалланды. Соңгы арада Башкортстан мәктәпләрендә генә берничә инцидент булды: балалар бер-берсенә пычак күтәрүгә кадәр барып җитте. Укытучыларны шушы хәл дә өркетми микән?

– Балалар усал, сүз дә юк. Ләкин аларның кыйммәтләре башка, ә без аларга үзебезнекеләрне көчләп тагабыз. Алар дәрәҗәсенә төшеп, бергә күтәрелсәң, әйбәт булыр иде. Әмма мәктәп бик олыгайды, шуңа күрә аңа балаларның кызыксынулары, борчулары һәм яшьләр мохитендәге яңа традицияләр артыннан өлгерү авыр. Өстәвенә, мәктәптә укытучыларның тәрбия эшен оештыруга, балалар белән ышанычлы мөнәсәбәт булдырырга, аларның романтика белән тулы булырга тиешле энергияләрен чыгарырга, башкаларга ярдәм итеп яшәргә өйрәнергә мөмкинлек бирүче педагогик мәгънәле балачак тормышын оештыруга вакыты бик аз. Аның урынына без алар алдына, чишү юлларын өйрәтергә өлгермичә, ашыга-ашыга төрле бурычлар куябыз.

Мәктәпнең проблемалары ул – мәгариф системасыныкы гына түгел, гомум җәмгыять проблемасы. Куандырганы: соңгы биш елда ил Президенты кардиналь карарлар кабул итә. Беренчедән, ул педагогика университетларына зур акча бүлде. Соңгы 3 елда педуниверситетларга өстәмә рәвештә акча бүленде, вузларда һәм колледжларда белем бирү процессының заманча инфраструктурасы барлыкка килде.

– Депутат буларак, мәктәпләрне үстерүгә юнәлтелгән закон проектлары кертүгә дә өлешегез зур дип беләм...

– Мәгариф турында законны атап үтәсем килә. Дәүләт думасына «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты ике тапкыр кертелде. Өченчегә җыенабыз. Анда бик күп нәрсәләр бар. Безнең барлык тәкъдимнәр укытучының һәм аның педагогик эшчәнлегенең абруен күтәрү, туган телләрне өйрәнү, мәктәп инфраструктурасын камилләштерү өчен шартлар булдыру, укучыларны тукландыру, белем бирүне хәвефсез шартлар белән тәэмин итү һ.б. белән бәйле.

– Бердәм дәүләт имтиханы – киләчәктә ул калырмы?

– Бердәм дәүләт имтиханы – сакланырга, ә аны оештыру формалары камилләшергә тиеш. Иң мөһиме – чыгарылыш сыйныф укучыларында психологик киеренкелекне булдырмау. Мин мәктәп тәмамлаганда, чыгарылыш имтиханнарын тапшырдым. Стресс кичердем. Вузга кергәндә дә сынау булды, тагын яңа стресс кичердем. Ә монда бер тапкыр тапшырасың, димәк, бер тапкыр кичерәсең. Икенчедән, БДИ белән мин берьюлы биш вузга кереп карый алам. Өйдән чыкмыйча гына. Тагын бер ягы: элек ата-анасы хәлле кешеләр вузларга, ни өчендер, җиңелрәк керде. Ә бүген барысы да бер шартларда кабул ителә. Тагын шунысы да бар: БДИ укытучының эшенә объектив бәя бирә.

Ләкин кабатлыйм: биремнәрнең эчтәлеген һәм БДИны оештыру ысулларын камилләштерүне дәвам итү мөһим. Аның бер начар ягы бар: репетиторлык белән шөгыльләнергә мәҗбүр итә. Ә баланы үстерү белән мәктәп шөгыльләнергә тиеш. Үсеш балага үзен күрсәтергә мөмкинлек биргәндә генә мөмкин. Хәзерге мәктәп укучыларының еш кына үз ихтыярыннан тыш укый башлауларын һәм «сканерланган» белемнәр алу алар өчен уңайлы булуын тануы да сер түгел. Укучылардан өстән-өстән генә тест чиштерүне дә бетерергә кирәк. Белем бирү процессында төп фактор – укытучының укучыны уйларга һәм борчылырга мәҗбүр иткән акыллы һәм тирән мәгънәле сүзе. Мәгариф тарихы укытучыдан да абруйлырак кешене белми. Мәктәп нинди генә технологик җиһазлануга ирешмәсен, ул һәрвакыт рухи тәҗрибәгә һәм акыл мәдәниятенә ия булган акыллы укытучыга мохтаҗ булачак. Шуңа күрә укучы белән укытучы арасында акыллы аралашу өчен вакытны арттыру һәм баланың миен имгәтүче репетиторлык белән азрак шөгыльләнү мөһим.

Программаны аңлы рәвештә үзләштергән укучы үзенә югары мәктәптә урын гарантияли. Быел мәктәпне якынча 17 мең бала тәмамлаячак. Күп дигәндә. Башкортстан югары уку йортларында 13500 бюджет урыны бар инде. Башкача әйткәндә, бүген абитуриентларның һәрберсенә урын әзер. Көчле 4легә укы гына.

– Сез җитәкләгән комитет тагын нинди законнар кабул итте?

– Яшьләр сәясәте, матди булмаган сәнгатьне саклау турында законнар кабул иттек. Патриотик тәрбия турында закон әзерләнә, бер-ике айдан кабул итәчәкбез. Безне тиргиләр, патриотизм хисен закон белән тәрбияләп буламыни, янәсе. Ә башкача мөмкин булмаса? Иленә куркыныч яный икән, син аны сакларга бурычлысың. Законда без шуңа шартлар системасы булдырачакбыз. Без законны патриот булмаган кешеләрне зинданга ябар өчен булдырмыйбыз. Патриотизм социаль статуска бәйле түгел. Син – йә патриот, йә юк. Илнең менә дигән гражданнарын һәм патриотларын үстергән совет системасын искә төшерергә кирәк.

Шушы уңайдан гел бер очракны хәтерлим: безнең сыйныфта ике Рамил бар иде. Алар артык тырышып уку һәм тәртипләре белән аерылып тормады һәм, әлбәттә инде, аларны безгә үрнәк итеп куймадылар. Бервакыт «Зарница» уенында шуларның берсе гәүдәсе белән гранатаны каплады. Уйлап тормыйча, ниндидер бер эчке омтылышына буйсынып. Директор, аны мәктәп алдына чыгарып, кочаклап: «Рәхмәт, улым!» – диде. Әлегә кадәр аның батырлыгын һәм мәктәп линейкасында булган хәлне онытмыйбыз. Ә мәктәп директорының сүзләре һәм гамәлләре Александр Матросов һәм Миңнегали Гобәйдуллинның батырлыкларына башкача карарга мәҗбүр итте. Безгә үзен практикада аклаган тәрбия методикасын югалтырга ярамый. Ә тәрбия ул – иң авыр эш. Бүген үсеп килүче буынны тәрбияләү, укыту һәм социальләштерүнең барлык институтларына мәктәп укучыларына һәм бөтен яшьләргә аларның фикеренең, хисенең һәм гамәленең әхлакый нигезен ачыклауда ярдәм күрсәтергә кирәк, бу аларның карарларын контрольдә тотарга һәм туган илләренең патриоты буларак, үз-үзен тотышын дөрес якка юнәлтергә мөмкинлек бирәчәк.

Резеда ГАЛИКӘЕВА.

«Кызыл таң» газетасыннан.

Атнаның
сәяси мизгелләре

Хәйләле «мятеж»

Узган ял көннәрендә Россиядә урын алган «мятеж» омтылышы инде төрле яктан һәм шактый ук киң яктыртылды, хәтта рәсми нәтиҗәләре дә мәгълүм булды. Россия Президенты В.Путин ЧВК «Вагнер» белән бәйле хәлләр турында Россия халкына аерым мөрәҗәгать белән дә чыкты. Ул анда ошбу коралды фетнәне оештыручыларны хыянәттә гаепләде, ә «Вагнер» төркеменең аларга алданып иярген һәм, соңгы сызыкка барып җиткәч аңга килеп, бердәнбер дөрес карар кабул иткән патриотларына рәхмәт тә белдерде. Алай гына түгел, ул аларны «Вагнер» хезмәткәрләренә биргән вәгъдәләр барысы да үтәләчәк, дип тә ышандырды, хәтта Саклану министрлыгы белән контракт төзү, яисә Беларуська чыгу мөмкинлеге дә калдырды. Ә төп нәтиҗәне президент: «Всех объединило и сплотило главное – ответственность за судьбу Отечества», – дип ясады. Шул ук көнне В.Путин көч структуралары җитәкчеләре белән дә киңәшмә үткәргән һәм ул чорда куйган тырышлыклары өчен рәхмәт белдергән. Ә «Вагнер» төркеме җитәкчесе Е.Пригожин белән сөйләшүләрдә арадашчы ролен алган Беларусь Президенты А.Лукашенконың осталыгы турында инде Россия тышкы эшләр министры С.Лавров үзенең Russia Today телеканалына биргән интервьюсында сөйләгән. Аныңча, Лукашенко бу эшкә үзе алынган һәм моны Мәскәүдә дә хуплаганнар. Нәтиҗәләр һәммәбезгә дә билгеле.

Әмма, сәяси күзәтүче буларак, ошбу «мятеж»га карата үз карашымны да белдерергә җөрьәт итәм. Аңа кагылышлы кайбер фактларның (баш штаб урнашкан каланың бер атусыз алынуы, зур колонналарның ерак араларга бернинди тоткарлыксыз үтүе, махсус хезмәтләрнең коралды фетнә турында алдан белмәве һ.б.) шик уятуы һәм коралды фетнәнең бик шома гына туктатылуы аның хәйләле «мятеж» булу ихтималлыгы турында да сөйли. Мәгәр аның сәяси максатларын да чамаларга була: якын-тирә даирәләрнең (ШОС һәм ОДКБ илләрен, кайбер коралды структураларны, илдәге эчке вәзгыятьне һ.б.) реаль куркыныч шартларында сынау; кайбер дошманнарның да кылларын тартып карау. Нәтиҗәләр исә монда да күренә.

Инде сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. Кытай Россия белән тиз үзгәрә торган бүгенге шартларда да эшләргә әзер булуы турында белдергән. В.Путин Россиянең «атом-төш өчлеге»н алга таба да үстерәчәге турында әйткән. ЕС Россиягә карата санкцияләрнең 11 нче пакетын кертергә җыена. АКШ Украинага 1,6 миллиард долларлык өстәмә хәрби ярдәм күрсәтәчәге турында белдергән.

Фоат УРАЗАЙ.

МОСТАФА

Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ



(Ахыры. Башы 20-24 нче саннарда).

Мостафа төз атуы белән монда да һәрчак беренчеләрдән санала иде. Бүтәннәр, байтак тәҗрибә тупласалар да, әллә каударлыйлар, әллә күңелләренә йомшаклык иңә, аталар, кеше авып та төшә, ләкин җаны чыкмый кала, тыпырдап-ыңгырашып ачу чыгарып ята. Мостафа бер ата, кеше туп-туры теге дөньяга китеп бара. Ишекне ачык калдырып, бәхәсләшеп, ерактанрак атып караганы да бар: ике күз уртасына гына чәпи егет, корбаны аһ итәргә дә өлгерми.

Начальство телендә Мостафаның исеме: «Ул илнең иң ышанычлы сакчыларыннан берсе, ул ватанны, туган җирне сатарга, җимерергә ниятләгән шпионнарны, диверсантларны, ил корткычларын юк итә бара!» Мостафа аңлы егет, коммунист, партбюро члены, үлемгә хөкем ителгәннәр арта барган саен, илдәге хәлнең тыныч түгеллеген сизенә ала торган көрәшче. Бу уй аңа эчке канәгатьлек, күңеленә олылык өсти тора. Дөрес, җәзаны ул билгеләми, анысын өстәгеләр, начальство карый. Аларын да бик яхшы белә сизгер җанлы Мостафа! Бикле бүлмәдә өчәү утыралар, аларны «тройка» дип атыйлар. Укыган, инсафлы, партия билгеләгән олы затлар! Партиянең өлкә комитеты секретаре Алемасов, Татарстанның Югары совет Президиумы рәисе Динмөхәммәтов, Дәүләт иминлеге комитеты хуҗасы капитан Михайлов төйнәлеп ала да һәр төнне йөзәрләгән дошманнарның муенына балта сала... «Бар бит хәтәр адәмнәр!» – дип, сокланып һәм куркып уйлый Мостафа. Михайлов кәттә егет, бил каешы, портупеялары чын күннән, ялтырап-шыгырдап тора. Билен кысып буып куйсамы...нәкъ явыз шөпшә инде! Шөпшә генә түгел – быжан, шөпшәнең явызы, бармак буйлысы. Хатын-кызлар ярата Михайловны, түшен бизәп торган «Кызыл Йолдыз» орденын күрсәләр, тәмам һуштан язалар.

Тик капитан Михайлов кеше күзенә алай бик күренеп тә йөрми. Депутат! Елтыр машинасыннан төшә дә эшенә керә, почмак саен баскан егетләр үрә катып аңа честь бирә. Өч катлы йортта шау-шу тына, хәтта чебен очканы да ишетелә башлый. «Үзе килде! Үзе! Тс-с!» Явыз тикшерүчеләр каезлаганда җан ачысы белән кычкырган тавышлар Михайлов утырган киң, кышын җылы, җәен салкынча бүлмәгә барып җитми. Ә Динмөхәммәтов!..Дөньяның бер әүлиясе! Йөзеннән елмаю, шатлык чаткылары китми, шәһәр урамнарында саксыз-нисез бер үзе иркенләп йөри. Университет урамы ташларына иплән кенә баса-баса менә, сөекле юлбашчыбыз, дөнья халыкларына бары тик бәхет кенә китерергә туган Ленин урамына чыга һәм җәяүләп Кремльгә хәтле бара. Гел елмая, белгәннәрнең сәламнәрен башын түбәнчелек белән иеп ала, үтеп киткәч борылып карый, күтәрелеп якты кояшка сәлам бирә, сылу кызлар белән очрашканда каш сикертә, иреннәрен ялый... Рәхәт яши белә адәм баласы! Булса да булыр икән кече күңеллелек! Һай, дөнья бәясе торырлык итагатьле, инсафлы кеше. Югыйсә эше чутлап бетермәслек, президиум утырышларын алып бара, барлык тантаналарда ул түрдә, докладларны менә дигән итеп ясый. Чапмас җирдән кулларны чабарсың! Кунак кабул итә, каршылый, озата, республика абруен һәр даим югары тота. Кайчан ял итә диген дә кайчан йоклый! Сизгер җан, «Тройка» утырышларында фамилиясе ишетелүгә, кемнең кем икәнен ярты ымлыктан аңлап ала, хөкем чыгарганда үтә кыю: «Атарга дигәч, атарга! Дошманнар кимегән саен яшәү рәхәтрәк була барачак! Әнә бөек язучы Горький да: «Әгәр дошман бирелмәсә – аны юк итәргә!» – дип иманын ачкан».

Беркөн Мостафа Динмөхәммәтовны университет колонналары каршында очратты. Бөек кеше белән очрашу Мостафага шулкадәр тәэсир итте, авызын ачып туктап ук калган иде, чак кына икенче трамвай астына барып кермәде. Динмөхәммәтовка нәрсә? Бара да бара! Атлый! Трамвай йөртүче дә кем барганын абайлаган, трамвай астан ыжгырып менеп, сулга борылам дигәндә шәһәрнең бөек кешеләреннән берсен күреп, хәвеф-аварияләр белән исәпләшеп тормады, йөрешен акырынайтты. Аллам сакласын! Динмөхәммәтовка бер-бер кыен була күрмәсен! Дөньяның тоткасы аңарда, нинди җаваплы, мәсьүл эштә утыра! 1937 елның октябрендә генә дә Черек күлгә беркетелгән взвод 546 тоткынны атып үтергән иде, декабрьдә атылган дошманнарның саны меңнән артып китте. Төнлә-төнлә кабер казырга, җирләгәндә күз-колак булыр өчен өстәмә көчләр билгеләделәр, атучыларның паекларын икеләтә арттырдылар. Бер Мостафа гына түгел, шактый әле алар, төнлә-төнлә эшләп, таң яралганда аракы шешәсе белән кочаклашып кайтып керүче ирләр. Коммунистлар партиясенең таянычын тәшкил иткән ирләрнең бәясен беләләр Черек күлдә! Мостафа ишеләрнең эше муеннан, аталар да аталар, аталар да егалар. Ник бу бичараларны суд хөкеменә тартмыйлар соң? Прокурорлар кайда да, адвокатлар нигә юк дип уйланып торырга вакыт калдырмаганнар аларга! Үзара бу хакта авыз ачып сөйләшкәннәре дә юк, ике дөнья бер – уртасы камыр! Ни уйлап торасың, Татарстанның баш кешеләре чыгара ич хөкемне, сыналган большевиклар, Ленинның тугры шәкертләре! Тирән, йомшак көрсиләргә чумып утыралар да, танаулары гына күренеп кала. Куе чәй чөмерәләр, шоколад чеметкәлиләр, ара-тирә коньяк белән иреннәрен чылаталар. Эшләре авыр, җитди, бер кичтә йөзәр кешегә үлем җәзасы биреп кара әле! Күпме көч, гайрәт кирәк моңа?! Нәзек билле бәллүр чәркәләр аша киселеп чыккан якты лампа нурлары тоткыннарның язмышына чик куйган аксыл-соргылт кәгазьләр өстендә туктаусыз бии, нык куллар салган имзалар таш сукмаклардан чәчрәп ята. «Атарга... атарга... атарга!!!» Боларның теленнән «Азат итәргә! Коткарырга!» дигән мәгънәләрне әллә кайчан сызып ташлаганнар.

Мостафа тугры хезмәт иткән взвод әгъзаларына да бүләкләр еш вә мул эләгә: һич зарланырлык түгел! Партия, власть үзенә тугры хезмәт итүчеләрне ленинча кайгырта. Ай саен ике тапкыр акчалата премия тараталар. (Ведомостьлар аткан кеше башы исәбеннән аерым төзелә!) Өстәмә паек, ит-май, шикәр-кәнфит, шулар өстенә, кулга алынучыларның мал-мөлкәте конфискацияләнеп, йөк-йөк маллар Черек күлдә батып юкка чыга. Хәзер Мостафа элеккеге арыш боламыгы түгел, тәҗрибәле, аңлы, алдын-артын исәпләп яши торган стажлы коммунист, кулга төшкән әйберләрне ул бөркет күзе белән тикшерә, сүрүләрне актара, кесәләренең киң төпләрендә казына. Теге чакта шытырдап янды дияргә булыр иде, шөкер, Халисәсенең холкы әйбәт, аңадан төпченеп, авырткан теш төбендә казынмады. Табылдык хатны ертып ташламады Мостафа, икенче көнне үк командирына китереп бирде. Тиз үк рәхмәт белдереп приказ чыгардылар. Чибәр апа белән Чибәр абыйларның кемлеген ә дигәнче белделәр. Тиз таптылар аларны, капитан Михайловның егетләре сынатамы соң?! Апа-абзыйларның чибәрләре күп үтте Мостафалар кулыннан... Бичараларны Черек күл подвалында сугып үлгә олактырганда, Мостафа кешелек сыйфатларын җуйган чибәр-чибәр хатыннарга, күз төпләре шешенеп беткән ирләргә карап: «Боларның кайсысы җакет кесәсенә хат язып салды икән?» – дип уйлап куйгалый иде. Тора-бара җакет та, хат та, хат аркасында ләхеткә кереп яткан дошманнар да онытылды.

1993-1994 еллар.

Кайтмаган солдатлар онытылмый

Археолог, «Татар төбәкчеләре оешмасы» җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Альберт Борһанов өчен сугыш темасы бик якын. Ул – Әфганстан җирләрендә барган утлы бәрелешләрдә катнашкан, фронт михнәтләрен татыган кеше. Шуңа күрә Бөек Ватан сугышы темасына да ул беркайчан да битараф булмады. Германиянең Советлар Союзына хыянәтчеләрчә бәреп кергән 22 июнь якынлашкан көннәрдә төбәкне өйрәнүчеләр катнашында ул Бөтендөнья татар конгрессы бинасында «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында татарларның һәм татарстанлыларның Җиңүгә керткән өлеше» дигән темага түгәрәк өстәл утырышын уздырды.

● **Сулдан уңга: Энгель Таһиров, Индус Таһиров, Вахит Имамов, Александр Малов.**

РЕЙХСТАГТА ТАМГАСЫН КАЛДЫРГАН ВЕТЕРАН

Бөек Ватан сугышы ветераны, бүген 97 яшен тутырып килүче Александр Михайлович Малов – Берлинга барып җиткән, Рейхстагка үз тамгасын калдырган сирәк ветераннарыбызның берсе. Сугыш башланган елда Кайбыч районының Иске Корбаш авылы мәктәбеннән VII сыйныфын тәмамлаган, 15 яшен генә тутырган үсмер окоп казырга да, тракторчы һөнәренә укып машина-трактор станциясендә эшләргә дә өлгерә. Әмма сугышта югалтулар коточкыч. Җитмәсә, сугыш алды елларындагы репрессияләр нәтиҗәсендә, саботажлар, ватанга хыянәт итүләр, дезертирлык кебек хәлләр дә була. Фронтка 17 яшьлекләрне дә ала башлыйлар. А.Малов та 17 яшеннән сугышка барып керә. Аны Рязаньда бронетранспортер механик-йөртүчесенә укыталар. Бу вакытта егетләргә ашау җитми, ачлыктан аңын җуючылар да була.

А.Малов генерал Рыбалко җитәкчелегендәге 3 нче гвардия танк армиясенең 57 нче авыр танк полкы составында Берлинга барып җитә, 1 нче Украина фронтының алты зур сугыш операциясендә катнаша, Украина, Польша, Германия, Чехословакияне азат итү өчен барган бәрелешләрдә фронт сызыгында була, яралана.

Аның хәтеренә сугышның бер көне аеруча уелып калган. Германиядә 1945 елның февраль аенда бер бәрелеш барышында безнең берничә танкны аерып калдыралар. А.Маловка алар өчен сугыш кирәк-яраклары илтеп тапшырырга әмер бирелә. Аның белән алты разведчик та була. Ә дошман алар узачак юлга атып тора, шуңа ул тирәлекне бик тиз узарга кирәк. Егет тырыша, зур тизлек белән бара, ә снарядлар уңга-сулга оча. Берсе бронетранспортер алдына килеп төшә. Машина туктап кала, егетләр, шул исәптән капитан Чигринец та чыгып йөгерә. Ә устав буенча механик-йөртүче сугыш машинасын теләсә нинди хәлдә дә ташларга тиеш түгел. Александр, дошман утын кызганмыйча атканда да, бронетранспортер астына кереп, снаряд ясаган зыянны төзәтә. Фашистның тагын бер снаряды эләксә, барысы да һавага очарга мөмкин, чөнки бронетранспортерда бензин һәм снарядлар да була бит. Әмма егет ул турыда уйламый, бераздан машинага җан керә, Александр алга томырыла һәм куркыныч участокны да узып өлгерә.

2 майда Берлинны алгач, солдатлар Рейхстагны карарга китә. Александр Михайлович стенага «Малов» дип язып куя. Ул, разведкага барып, куелган бурычны һәрвакыт төгәл һәм җиренә җиткереп вакытында үтәве, машинасын тәртиптә тотуы өчен I дәрәҗә Ватан сугышы, III дәрәҗә Дан орденнары, «Батырлык өчен», «Берлинны алган өчен», Праганы азат иткәне өчен» медальләре һәм башка дәүләт бүләкләре белән хөрмәтләнә.

СУГЫШ ЧОРЫ БАЛАЛАРЫ

Тарих фәннәре докторлары, академиклар Индус һәм Энгель Таһировлар – сугыш чоры балалары. Булдыклы, бер ай эчендә алты почмаклы йорт салып куйган әтиләре Риза ага фронтка киткәндә, әниләре Әминә берсеннән берсе кечкенә өч бала белән кала. Олы уллары Дамирга – сигез, Индуска – биш, төпчеге Энгельгә бер яшь була. Риза аганың үзен озата килгән уллары Дамир белән Индусны аерылу ачысына түзә алмый елауларыннан туктату ниятеннән Шөгер кибетеннән сатып алган мандолинасы аларга соңгы бүләге була. «Сезгә мандолина калдырам, мин кайтканчы уйнарга өйрәнеп куегыз!» – ди ул. Балалар мандолинада уйнарга өйрәнә, әтиләре генә кайтмый, 1944 елның ноябрендә Латвия җирләрендә ятып кала. Әтиләре солдатлар ачлыктан, төрле авырулардан кырылган Суслонгерга эләгә. Шөкер, ул бу үлем базыннан котыла. Батыр йөрәкле әниләре Суслогерга барып, шушыларны күреп, язып чыга. Әтиләреннән башта сагынулы хатлар килеп тора. «Язган хатларын матбугатта бастырып та чыгарганым бар. Шул вакыттагы тормышны, хәрбиләрнең ни рәвештә сугышта катнашуын, аларның адәм баласының эчке кичерешләрен күрсәтүе – олы сабак», – дип белдерде Индус ага. Уллары әтиләренең җирләнгән урынын 40 ел дәвамында эзли, зур авырлыклар белән таба, әниләре белән бергәләп барып баш ияләр...

1945 елда сугышта исән калган, күпчелеге кулсыз-аяксыз фронтовиклар кайта башлый. Ул вакытта әтиләре Риза аганың төпчегенә биш яшь тулып килә. Бер көнне малай үзләренең капка төбендә ниндидер хәрбинең басып торганын күрә. Әлбәттә, сабый аны әтисе итеп кабул итә һәм йөгереп барып, аның бер аяксыз икәнен дә абайлап өлгермичә, аңа каплана һәм солдат егылып китә яза. Икесе дә капкага тотынып калырга өлгерә, әмма икәүләп елыйлар. Малай хәрбинең әтисе булмавына әрнеп, ул исә ятим баланың әтисен өзелеп көткәнен, өметләре акланмавы ачысын йөрәге аша үткәреп елый. «Ятимнәр белән авыл тулды. Алар исән калу, яшәү өчен түзде. Мин шул вакыттагы авыл халкына рәхмәтле. Балаларны авыл күтәрде, чишмәләре, урманнары, исән калган бабайларның вөҗданлыгы күтәрде һәм аякка бастырды», – дип тәгаенләп үтте Энгель ага. Ул шулай ук хәзер инде ул чор балалары бик аз калуын да искәртеп, бу теманы кабат күтәрергә кирәклеген, барысын да теркәтеп калдыру соралуын да искәртте. «Бу тарих берничә китап булып дөнья күрсен иде», – диде Э.Таһиров. Егетләр үсеп җитешкәч, Шөгердән китеп Казанга килә. Бүген алар – озак еллар халкыбызга хезмәт иткән, олуг ихтирамга ия галимнәребез. Энгель ага ике илнең короленә, Иран һәм Төркия Президентларына, ЮНЕСКО ның дүрт генераль директорына, Берләшкән милләтләр Оешмасының ике генераль секретарена Диплом тапшырган кеше буларак та мәгълүм.

ҺӘЛАК БУЛГАННАР ОНЫТЫЛМАСЫН

Питрәч районының Чыты авылы мәдәният йорты директоры, туган як тарихын өйрәнүче Миңнур Шәмсетдиновның Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашларының исемнәрен һәм язмышларын ачыклауда кылган гамәлләре башкаларга да үрнәк булырлык. Ул, Брест ныгытмасының соңгы сакчысы, Советлар Союзы Герое Петр Гавриловның каберенә туган авылы туфрагын илтеп салу белән бергә, Белоруссиядә мәңгелеккә ятып калган авылдашларын да ачыклый алган, аларның каберләреннән дә туфрак алып кайткан. Белоруссия җирендә Чыты авылыннан гына да алты ир-егет һәлак булган. Абдулла Камалиев Рыленко авылында туганнар каберлегендә җирләнгән. Аның исеме мемориаль комплекстагы һәйкәлгә уеп язылган. Аннан 15 чакрымда урнашкан Питренко авылындагы каберлектә Нуретдин Гайнетдиновның җәсәде ята. Сугыш вакытында 352 нче Шталаг концлагеренда 80 мең хәрби әсирләрнең гомере киселгән. Бер көндә бишәр мең әсир юк ителгән. Чытыдан сугышка киткән Җамали Батталов, Әхмәтҗан Имаметдинов та Масюковщина авылындагы 352 нче Шталаг концлагерында һәлак булган. Миңнур Шәмсетдинов «Хәрби Дан клубы» ассоциациясе рәисе Михаил Черепанов ярдәме белән авылдашы Сафиулла Кәримов турында язылган кәгазьнең күчермәсен алган. «Сафиуллага 19 яшь кенә була. Бәлки, 1943 нче елда әнисе бу кара мөһерле кәгазьне алган да булгандыр, әмма ул инде югалган. Яңа күчермәне туганнары кадерләп кабул итте. Шул ук елда бу егетнең әтисе дә һәлак була», – диде М.Шәмсетдинов. Ул тагын бер Чыты егете Мөстәкыйм Гариповның Белоруссиянең Клецк шәһәрендәге хәрби госпитальдә яралардан вафат булуын, авылдашы Мәйсәрә апаның ике яктан да бабалары Белоруссия җирендә ятып калуын, Габдулла Камалиевнең дә каберен ачыклаган. Концлагерьда һәлак булган Җамалый Батталов турында озак еллар хәбәрсез югалган дигән мәгълүмат булган. «Әни гомере буе әтисен эзләде. Күрше Күн авылына барып сугыштан кайткан фронтовиклардан ишетмәдегезме, дип сораштырып йөргәнен хәтерлим», – дип сөйләгән Мәйсәрә апа.

Миңнур Шәмсетдинов Белоруссиядән алып кайткан туфракны зиратның бер урынына салып, истәлек тактасы куярга ниятли. Эш башланып киткән инде. Бәлки, парк кебек аллея да ясау мөмкин булыр. Химаячеләр таптым, эш кузгалып китте», – ди төбәкне өйрәнүче.

Мари Эл республикасында «Татар төбәкне өйрәнүчеләр» җәмгыяте җитәкчесе Сания Газизҗанова Бәрәңге районының Куян авылында укытучы булып эшләгән, «Идел-Урал» легионында яшерен оешманы җитәкләгән Гайнан Кормаш батырлыгы турында бәян итте. Легионның үзебезнекеләр ягына чыгуы, халкыбызны да депортацияләнүдән коткарып кала.

Тарихи романнар авторы Вахит Имамовның «Башкортстанда туган татар Геройлары», икътисад фәннәре докторы, Казан федераль университет профессоры, Татарстан фәннәр академиясенең вице-президенты Вадим Хоменконың «Германиянең куәтле экономикасы һәм Советлар берлеге икътисады» дигән темага ясаган чыгышы да кызыксыну белән тыңланды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.



● **Альмира Шәрифуллина.**



● **Александр Малов.**



● **Сания Газизҗанова.**

Мәдәни җомга
30 июнь
№25, 2023

1906 елда ачылган «Галия» мәдрәсәсе.

«Галия» мәдрәсәсе бинасының ихатадан күренеше.

ШАНЛЫ

Революциягә кадәр үк төзелгән ике манаралы һәм артта мәдрәсә бинасы да булган Хаким мәчете.

Уфа үзәгендәге Совет мәйданына куелган Миңлегали Шәйморатов һәйкәле.

Халык шагыйре Мостай Кәрим һәйкәле.

Агыйдел ярына куелган Салават Юлаев һәйкәле.

Республика телевидениесе бинасы каршына куелган Шәехзадә Бабич һәйкәле.

Россия Каһарманы М.Шәйморатовка туган авылында куелган һәйкәл.

● М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры.

● Башкорт дәүләт университетының төп корпусы.

УФА ЯДКӘРЛӘРЕ

Вахит **ИМАМОВ** фотолары.

● Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте карамагындагы Лалә-Тюльпан мәчете.

● Курайчылар әзерли торган махсус музыка мәктәбе бинасы.

● Риза Фәхретдин һәм аның ике улына куелган кабер ташлары.



● Атаклы композитор Заһир Исмәгыйлев хөрмәтенә куелган һәйкәл.

● Атаклы шагыйребез Әнгам Атнабай кабере өстендәге таш.

● Атаклы җырчыбыз Фәридә Кудашева каберенә куелган таш.

● Уфаның мөселман зиратында Мостай Кәрим каберенә куелган таш.

Рус уку йортларыннан аермалы буларак, хөкүмәт татар мәктәп-мәдрәсәләрен беркайчан да финансламаган. Алар йә мәхәллә халкы, йә аерым хәйриячеләр ярдәмендә оеша һәм эшчәнлек итә. Зур шәһәрләрдә сәүдә иткән яисә эшмәкәрлек белән шөгыльләнгән байлар, гадәттә, туган якларында мәдрәсә ачып, аны тулысынча акча белән тәэмин итеп торган. Авыл җирлегендәге атаклы мәдрәсәләрнең күбесе Казан арты төбәгенә карый: Кышкар, Курса, Мәтәскә, Түнтәр һ.б. Мамадыш ягындагы Сатыш мәдрәсәсе дә тирә-якта данлыклы була. Татарлар балаларын, белем бирү максатыннан, ерактагы мәдрәсәләргә илтеп укыта торган булганнар.

● Заһидулла Шәфигулла улы Шәфигуллин.

● Энесе Шәйхулла.

МӘГАРИФТӘ БЕРТУГАН

Фәнни әдәбиятта Казан, Оренбург, Уфа, Иж-Буби мәдрәсәләренең эшчәнлеге инде күпмедер күләмдә өйрәнелгән. Бу мәдрәсәләрнең уку-укыту программалары белем бирүнең югары дәрәҗәсе хакында сөйли. Әлеге тикшерүдә без Тау ягы мәдрәсәләренә тукталырбыз.

1909 елгы мәгълүматлар буенча, Тәтеш өязендә 112 мәктәп булган, Зөя өязендә – 25, Чар өязендә 5 мәдрәсә эшләгән. Атаклы мәдрәсәләр дәрәҗәсендә үк булмаса да, XX гасыр башында Тәтеш өязенең Атабай, Идрәс-Тенки, Олы Кариле, Келәнче, Олы Тормы авылларында шактый көчле уку йортлары булуы билгеле. Идрәс-Тенки, Олы Кариле авылларында Әҗем мәдрәсәсен тәмамлаган Әхмәтҗан Габделгаффаров һәм Шаһимөхәммәд Нурмөхәммәтев мөгаллимлек итә, Келәнчедә – Буа мәдрәсәсен тәмамланган Шиһабетдин Мифтахетдинев, Олы Тормыда – Апанай мәдрәсәсе шәкерте Зыятдин Шәрәфетдинев, Атабай авылында Әҗем мәдрәсәсен тәмамлаган Шаһимөхәммәд Госманов белем бирә.

XIX-XX гасыр башында Тау ягындагы иң атаклы мәдрәсә Акъегет авылында урнашкан була. Бу мәдрәсәне нигезләүче һәм матди тәэмин итеп тотучы ике бертуган Шәфигуллинның берсе – Заһидулла Шәфигуллин эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге шәхеснең хәйриячелек гамәлләре Тау ягында гына түгел, Россиянең ерак Себер якларында да билгеле.

Заһидулла Шәфигуллин 1840 елның 16 декабрендә Акъегет авылында дөньяга килә. 1859 елда, әтисе үлеменнән соң, ул Урал якларына эш эзләп китә. Томск, Иркутск шәһәрләрендә сәүдә эшләрен башлап җибәрә: энесе белән берлектә Кырым алмалары китереп сата башлыйлар. Шулай ук күлмәкләр, җәнлек тиреләре белән сәүдә итәләр. Энесе Шәйхулла белән 1894 елның сентябрендә «Бертуган Шәфигуллиннар» дип исемләнгән сәүдә йорты оештыралар. Иркутск, Красноярск, Чита шәһәрләрендә җәнлек тиреләре сата торган кибетләр челтәре ачыла.

1887 елда Иркутскидагы үз йортлары утарында мәчет төзетәләр. 1907–1908 еллар аралыгында өч катлы табыш йорты барлыкка килә. Шулай ук Шәфигуллиннар Иркутск, Чита шәһәрләрендә мәчет төзелешләренә зур сумма иганә итә. Томск шәһәрендәге мөселман балаларына белем бирү мәдрәсәсенә дә зур матди ярдәм күрсәтеп торалар. Хаҗи Шәйхулла Шәфигуллин мәктәп белән идарә итү өчен Төркиянең атаклы уку йортларында белем алган Исмәгыйль исемле мөгаллимне китертүгә ирешә [Казан мөхбире, 1907].

XIX гасырның 90 нчы елларында Заһидулла Шәфигуллин сату-алу эшләре белән җитәкчелекне энесенә, өч улы – Зиннур, Гарифҗан, Хәйруллага һәм туганының уллары Гыйлаҗетдин, Сәлахетдин һәм Абзалетдингә тапшыра. 1912 елның августында «Шәфигуллиннар һәм Әхтәмевләр» ширкәте оеша. Алар Вятка, Вологда, Архангельск шәһәрләренең атаклы бай сәүдәгәрләре белән туганлашып, нәсел-туганлык капиталын арттыруга ирешә, табышларының бер өлешен җәдиди мәктәпләр ачуга тота. «Русия сәүдәсе» газетасында түбәндәге юллар теркәлгән: «Аның [Заһидулла] тарафыннан салынган мәктәпләрнең һәммәсендә ысулы җәдидә берлә тәгълим ителә. «Тәрҗеман» мөхәррире Исмәгыйль Гаспринский җәнаблары халыкны ысулы саутиягә өндәгән вакытта иң башлап кабул итүче Заһидулла хаҗи булган» [Русия сәүдәсе, 1913, б. 6–7].

Дөньяны күреп өлгергән, зур капитал туплауга ирешкән Заһидулла Шәфигуллин туган авылы Акъегеткә кайтып төпләнә. Шул заманның чиновниклары язмаларында ул коры холыклы, кире, үзсүзле, куркусыз кеше буларак сурәтләнә. Җирле халык аны хөрмәт итә, тәэсирле кеше булганга, аңа берникадәр курку аша карый. Архив документларында, З.Шәфигуллин нинди генә гамәл кылса да, халык аны «сатмаячак», аңа хыянәт итмәячәк, диелә.

Шәфигуллиннар Чар, Зөя, Тәтеш өязләрендә мәчетләр төзү, мәдрәсә, мәктәпләр ачуга зур матди ярдәм күрсәтә. Заһидулла Шәфигуллин хисабына Акъегет авылында да 3 мәчет һәм мәктәп төзелә һәм төзекләндерелә [Русия сәүдәсе, 1913, б. 6–7]. Шулай ук ул башка бай сәүдәгәрләрне дә мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр төзетү эшенә җәлеп итә. Мәсәлән, аңа Акъегет мәдрәсәсе чыгымнарын күтәрергә Архангель сәүдәгәре Закир Ишмәтев ярдәм итә. Хәзерге Кайбыч районына керә торган Кошман авылының ике катлы икенче агач мәчетен үз хисабына төзетә.

З.Шәфигуллин үз заманында сәүдәгәр, эшмәкәр булып кына түгел, ә җәдидче буларак бик ихтирамлы һәм танылган шәхес була. Аның эшчәнлеген И.Гаспралы, Г.Баруди, Г.Апанаев кебек атаклы кешеләр югары бәяли. Жандармерия документларында аның хакында «он был Галеевского и Иж-Бобьинского закала», дип теркәлә. Чабаксар өязе исправнигы В.А. Лохвинцкий Казан вице-губернаторы Г.Б.Петкевичка биргән рапортында З.Шәфигуллин турында «известный крупный мусульманский деятель-панисламист, человек прогрессивного направления по своим политическим убеждениям, примыкающий по своему мнению к партии конституционалистов-демократов», дип яза. 1870 елда әдип үз туган авылы – Акъегеттә мәдрәсә ачып җибәрә. Бинасы ике катлы итеп, 36 аршин озынлыгында төзелә. Мәдрәсә берничә мәртәбә төзекләндерелә. XX йөз башында шәкертләр саны 300 гә җиткәнлектән, 1895 елда бина киңәйтелә. Мәдрәсә утары тулы бер комплексны хәтерләтә, аның янында укытучылар яши торган ике катлы йорт, шәкертләр юыну өчен мунча, ашханә урнаша. Мәдрәсә комплексының янында алма бакчасы үстерелә.

Шәкертләрнең җитмешкә якыны ерактан килеп укучылар була. Әлеге уку йортында Чистай, Буа, Минзәлә өязе авылларыннан килгән балалар һәм яшүсмерләр белем ала. Бер шәкертнең Владивостоктан булуы да мәгълүм. Мәдрәсәдә торып укучылар аскы катта яшәгән. Алар тулысынча Шәфигуллиннар хисабына көн күргән. 1913 ел мәгълүматлары буенча, бу мәдрәсәдә 9–18 яшьлек 114 шәкерт белем алган.

Шәфигуллин татар халкын гыйлемле, укымышлы итү максатыннан күп көч куя. Документларда: «Шафигуллин – убежденный сторонник распространения образования в мусульманской среде. При разговорах с должностными лицами Шафигуллин высказывает, что татары необразованны, некультурны и экономически оскудели и что только образование может сделать татар культурными и поднять экономический их уровень», дип теркәлеп калган.

З.Шәфигуллинның эшчәнлеге аерым кешеләр арасында ризасызлык тудыра. Тирә-як авылларның муллалары җәдиди укытуга шикләнеп, хәтта куркып карый. Шулай ук мәдрәсәдә рус сыйныфлары эшләп килү традицион карашлы халыкны, руханиларны да шик-шөбһәгә сала. Әлеге ситуация хакимият вәкилләрен дә өркетә. Айдар авылы мулласы Гарифулла Шаһиәхмәтев Шәфигуллин мәдрәсәсе турында халык арасында ялган сүзләр дә тарата, бу мәдрәсәнең эшчәнлеген миссионерлар белән хезмәттәшлектә гаепләргә маташа. Ул 1901 елның 21 декабрендә намазга дип килгән Акъегет мәдрәсәсендә укый торган 2 шәкертне төртеп чыгарып җибәрә. Чиновник Н.В. Смирнов «Шафигуллин инспирирует идею национализации мусульманской школы и тратит очень

●Иркутскида Шәфигуллиннар тырышлыгы белән төзелгән мәчет.

● Акъегеттә З. Шәфигуллин йортын мәчет итеп үзгәртеп коралар.

ШӘФИГУЛЛИННАР

большие средства на осуществления этой идеи», дип белдерә.

Акъегет мәдрәсәсе уку программасында хәтта рус сыйныфында да рус һәм гомум тарих дигән предмет булмый, ә аның урынына Шәрык тарихы укытыла. Чабаксар өязе исправнигы болай дип яза: «Я лично убежден, что медресе в д. Акзигитово создано и поддерживается Шафигуллиным в целях религиозно-национального объединения мусульман».

1897 елдан башлап Акъегет мәдрәсәсе җәдиди уку программасы белән эшли башлый. Мәдрәсә 1907 елда Казан укытучыларының икенче корылтаенда эшләнгән программа буенча, аерым алганда, Апанай мәдрәсәсенә якын программа белән укыта. Мәдрәсә 5 бүлектән һәм 2 сыйныфтан тора. Беренче сыйныфта курсны узу вакыты 3 ел, икенче сыйныфның уку курсы 7-8 ел дәвам итә. Биредә гакаид, тәҗвид, ана теле, арифметика һ.б. предметлар укытыла. Дәресләр татар телендә алып барыла. Жандармерия документында «он большое внимание обращает на народное образование. В этом старается, чтобы муллы и учителя больше обращали внимание на обучение татарскому языку и светским предметам образования», дип күрсәтелә. Мәдрәсәдә уку дәреслекләре буларак Х. Искәндәревнең «Белек йорты», «Гарәпчә сарыф», «Мең дә бер хәдис», «Тарихы ислам», «Гыйльме хәл», Г.Тукайның «Яңа кыйраәт», «Татар сарфы», «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре», Я.Хәлилинең «Яңа мәктәп», «Гыйльме хәл», Г. Гыйсмәти һәм Ф.Туктаровның «Татар теле», Ф.Кәриминең «Мохтасар тарихы исламия» һ.б. кулланылган.

Мәдрәсәдәге ысулы саутия методы белән укытуның нәтиҗәлелеген, файдасын, укыту дәрәҗәсен күрсәтү максаты белән дә ел саен ачык имтиханнар оештырылган. Имтиханнарга тирә-як муллалары, Чар һәм күрше өязләрдән мөхтәрәм кешеләр чакырылган. Бу ачык имтиханнар башка төбәкләрдәге уку йортларының да җәдиди укыту ысулына күчүенә этәргеч булып торган.

XIX йөз башында мәдрәсә мөгаллиме вазыйфаларын авыл мулласы Нурулла Ярулла улы үтәгән [ТР ДА, 160 ф., 1 тасв., 1834 эш, 1а кгз.]. Авылның бу беренче мулласы ике башлангыч бүлектә дәресләр алып барган. Дүрт өлкән бүлекләрдә дин дәресләрен һәм башка предметларны башлангыч бүлегендә рус теле укытучысы Фатыйх Сәйфуллин (Фатыйх Сәйфи-Уфалы буларак билгеле) укыткан.

1912 елда мәдрәсә каршында рус сыйныфы ачыла, үз хисабына андый сыйныф ачуны сорап «Бертуган Шәфигуллиннар» сәүдә йорты әгъзасы Заһидулла Шәфигуллин чиновникларга 1908 елда ук мөрәҗәгать итә. Ул үз үтенечендә бу сыйныфның укытучысы итеп Бирскида укытучылар мәктәбен тәмамлаган Әхмәди Гордеевне куерергә тели [160 ф., 1 тасв., 1215 эш, 28а–28б кгз.]. Рус телен өйрәнү җирле халык арасында шактый популярлаша, теләүчеләр артканнан-арта бара. Бу сыйныфта 84 кеше белем ала, укырга килергә теләүчеләр саны 40 кеше була. Әлбәттә, мәдрәсә берьюлы шулкадәр кешене сыйдыра алмый, шуңа да рус теле укытучысы Әхмәди Гордеев Шәфигуллин исәбенә рус телен укыту өчен кичке курслар ачарга рөхсәт бирүне сорап мөрәҗәгать итә. Әмма Чар һәм Зөя өязләре исправнигы И.М. Крестников Казан губернасы халык мәктәпләре директоры М.Н. Пинегинга биргән җавабында мондый курслар ачу ягында булмавын белдерә. Ул үзенең фикеренә дәлил итеп түбәндәге сәбәпләрне атый: беренчедән, укытучының нагрузкасы тиешле нормадан күпкә артачак, икенчедән, 300 шәкерт укыган һәм дә яшәгән мәдрәсәгә тагын да өстәмә шәкертләр сыя алмаячак, көне буе шәкертләр булган бинаны җилләтергә дә кирәк булачак, өченчедән, олыларны рус теленә укытуны һәрвакыт күзәтеп торырга кирәк булачак. Гордеев «не внушает мне пока еще доверия, ввиду кратковременной службы в моей инспекции», дип, чиновник татарларга рус теле укытсаң, аларның дөньяга чыгу, аралашу даирәсе киңәячәгеннән шөрли. Шулай итеп, кичке курслар ачуга ризалык бирелми.

З.Шәфигуллин авылда кызлар укыту эшенә дә нигез сала. Иң беренче итеп кызлар мәктәбен үз өендә, үз исәбенә ачып җибәрә. 1913 елга кадәр кызларны укыту эшен озак еллар буе аның кызы җитәкли. Соңыннан кызлар мәктәбенең үз бинасы барлыкка килә. Мәктәп берәр катлы ике бинада урнаша. 1913 елга караган волость идарәсе документлары буенча күрсәтелгән вакытка монда 130 (кайбер мәгълүматлар буенча 140) кыз белем алган. Кызлар мәктәбендә дә рус сыйныфы эшләгән. Рус сыйныфларында уку срогы 4 ел булса, татар сыйныфларында уку срогының кысалары билгеләнмәгән була. 1912 елдан башлап монда рус теленнән М.Салихова, ә татар сыйныфларында 1913 елдан башлап М.Камалова мөгаллимлек итә. Укытучылар өчен дә, укучылар өчен дә яхшы шартлар тудырылган була. Ике мөгаллим укытучылар өчен махсус төзелгән бинада яшәгән.

Картлык көннәрендә З.Шәфигуллинга югарыда күрсәтелгән уку йортларын тәэмин итү авырлаша башлый. 1910 елда 71 яшендә булган З.Шәфигуллин эшләренә ярдәм итүне сорап хөкүмәткә мөрәҗәгать итә. З.Шәфигуллинның хакимият белән мөнәсәбәтләре нинди генә катлаулы булуга карамастан, аның мәгариф өлкәсендә күрсәткән хезмәте югары бәяләнә: мөрәҗәгате канәгатьләндерелеп кенә калмыйча, Земство собраниесе исеменнән күпьеллык фидакяр хезмәте өчен бүләкләүгә тәкъдим ителә. Хөкүмәт тарафыннан да финансланганга бу мәдрәсә соңгы елларда инде «Русско-татарская школа» буларак эшләвен дәвам итә. Мәдрәсә бинасы 1929 елга яраксыз хәлгә килә һәм уку йорты ябыла. Аның күргәзмә материаллары, географик карталары Норлат мәктәбенә алына. Акъегет авылында бары дүртьеллык мәктәп кенә кала [Тимершин, 2001].

З.Шәфигуллин 79 яшендә үлеп китә һәм үз туган авылы зиратында җирләнә. Заманында үзенең белем алу мөмкинлеге булмаса да, укуның ляземлеген, аның заман таләпләренә туры килерлек югары дәрәҗәдә булырга тиешлеген аңлый. Беренчеләрдән булып, үзе оештырган мәдрәсә-мәктәпләренә җәдидчә укытуны кертә, үз мәктәпләренә укытучы итеп бары тик алдынгы карашлы яшьләрне генә сайлап ала, заманының зыялы кешеләре белән аралаша, мәктәпләренә татар газеталары яздыра, мәктәп китапханәләре булдыра. Жандармерия документларында «в дни пресловутой свободы он мечтал иметь в своей деревне нечто вроде татарского университета», дип күрсәтелә.

XX йөз башындагы иҗтимагый һәм сәяси хәлләрдә дә ул актив катнаша. Үз мәктәбе тирәсендә үзгәреш, яңарыш яклы муллаларны туплаган. Шул ук жандармерия документларыннан күренгәнчә, «... перед съездом мусульман в Петербурге устраивают Шафигуллины в его школе большое собрание мулл своего околотка, среди которых было много из враждебного Шафигуллину лагеря, но несмотря на это, в этом собрании Шафигуллин был почти единогласно выбран как представитель от них на съезд». 1906 елда социал-революционерлар партиясе файдасына акчалата ярдәм күрсәтә, Гаяз Исхакый аша «Таң йолдызы» газетасын химаяли. Шулай итеп, Заһидулла Шәфигуллинның татар мәгърифәтчелеге өлкәсендәге эшчәнлеге һәм татар мәгарифе үсешендәге роле фәнни яктан танылырга һәм бәяләнергә хаклы.

Эльмира СӘЛАХОВА,
тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре
«Фәнни Татарстан» журналыннан.

Мәдәни җомга
30 июнь
№25, 2023

Рухи күперләрне ялгап...

Азәрбайҗан халкы белән уртак кыйммәтләргә ия төрки халыклар арасында әдәби бәйләнешләр һәрвакыт көчле булды. Төркия һәм Урта Азиядә яшәгән төрки халыклар кебек үк якын булмасак та, Татарстан белән әдәби-мәдәни мөнәсәбәтләр беркайчан да өзелмәде. Тел һәм графика охшашлыгы бу бәйләнешләрне тагын да ныгытты. Революциягә кадәр азәрбайҗаннар да, татарлар да гарәп графикасында, совет чорында исә кириллицада язды һәм иҗат итте.



Әдәби бәйләнешләрне үстерү мөмкинлеге биргән төп гамәлләрнең тагын берсе – әдәби текстларның тәрҗемә ителеп бастырылуы, альманахларга, җыентыкларга, дәреслекләргә кертелүе. Азәрбайҗан укучысы татар әдәбияты белән киң рәвештә Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Германиядә әсирлектә үтерелгән Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең шигырьләре аша таныша. Аның поэзиясе үзендә татар халкының баш имәс сугышчан рухын, каһарманлыгын чагылдыра:

Öldür! Diz çökmərəm qarşında, qatil!
Dustağam, ürəyim sənə qul deyil?
Başımı baltanla üzə bilərsən,
Fəqət ayaq üstə öləcəyəm, bil!
(Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә,
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.)

Муса Җәлилдән соң да татар әдәбияты азәрбайҗан теленә тәрҗемә ителеп һәм популярлаштырылып килә. Бу популярлаштыру бүгенге көндә дә дәвам итә. Соңгы вакытларда тәрҗемә ителгән шагыйрьләрнең берсе – Рәмис Аймәт. Аның Бакуда дөнья күргән «Şimşəklər qoynunda» («Яшеннәр кочагында») исемле җыентыгы ике төрки халык арасындагы рухи күперләрнең өзелмәве, тарихи бергәлекнең һаман да нык булуы турында сөйли.

Рәмис Аймәт шигырьләренең илебездә басылып чыгуы бары тик бер әдипнең азәрбайҗан теленә тәрҗемә ителүе генә түгел, ул хәзерге татар әдәбиятының монда танытылуы, әдәби багланышларның киләчәктә дә даими дәвам итәчәгенә ышанычның тагын бер дәлиле булып тора.

Рәмис Аймәтнең поэзиясе стиль һәм эчтәлек ягыннан игътибарны җәлеп итә. Шагыйрь үзенең фикерен әйтеп бирү өчен татар халкының рухын гәүдәләндергән образ һәм гыйбарәләрдән файдалана. Бу нисбәттән аның шигырьләрен, М.Җәлил шигырьләре кебек үк, татар халкының сынмас характеры, батырлыгының чагылышы дип атап булыр иде.

Keçir... Keçir qaraçı arabaları,
Hara baxırsan, hər yerə azadlıq sərilib!
(Уза... уза... чегән арбалары,
Кая бакма – җәйрәп ята Ирек!!!)

Бу юлларда шагыйрь чегән арбаларын тасвирлый. Чегән арбасы авторның бу шигырендә ирек, азатлык символы булып тора. Чөнки чегәннәр беркемнең дә әмеренә буйсынмыйча, кайда теләсә шунда яшәгән халык ул. Бу текстта чегән арбалары күченү символы буларак та файдаланылган.

Шагыйрь поэзиясенең тагын бер үрнәгенә – «Тукай карашы» шигыренә игътибарыбызны юнәлтик:

O baxışda... Ölkənin canına sığınıb
Bütün gecə payız rüzgarı ağlar.
O baxışda... Qan ağlayır, gərilib
Bir müqəddəs hüzünlü sazın teli.
(Ул караштa... ил җанына сыенып,
Төннәр буе көзге җилләр елый.
Ул караштa... зеңләп тартылган күк
Бер мөкатдәс моңлы сазның кылы.)

Р.Аймәт монда үз фикерләрен мәшһүр татар шагыйре Г.Тукайның күз карашын тасвирлау аркылы бирә. «Тукайның карашлары» гыйбарәсе шигырьдә символик мәгънәгә ия. Асылда, шагыйрь Тукай әйтәсе килгәннәрне, Тукай язасы килгәннәрне әйтеп бирә. Татар халкының моң-сагышын, гамь-кайгысын шагыйрьнең карашы аркылы чагылдыра алган. Шигырьдә «...Ул караштa… ил җанына сыенып, Төннәр буе көзге җилләр елый» тәгъбире тирән яшерелгән эчке мәгънәне белдерә күбрәк. Ягъни, илнең, ватанның, халыкның дәрте, сагышының чиге юк, ләкин кайгы-хәсрәткә бирелеп, елау да кыен. Шуңа күрә дә төнлә искән көзге җил һәркемнең телендә «елый», аз булса да сагышны баса.

«Ул караштa… зеңләп тартылган күк, Бер мөкатдәс моңлы сазның кылы» юлларында исә автор Тукайның күз карашларын образга әверелдерә. Карашларны шагыйрь гамь чиккән, үксегән саз кылы белән чагыштыра.

Р.Аймәт шигырьләренең образлар системасы бай. Шагыйрь поэтик табышларын образлар белән берләштереп, үзенә генә хас стиль формалаштырган. Аның шигырьләре никадәр заманча булса, шул кадәр үк классик традициягә дә нигезләнгән. Каләм әһеленең поэтикасы классик татар шигърияте җирлегендә тамыр җәйгән.

Шагыйрьнең шигырьләре төрле-төрле темаларга багышланган булса да, алар күбрәк татар халкының үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыра. Аның «Сөрелү» шигырендә моңа тагын бер мәртәбә шаһит булабыз:

Sürgün edildim mən. Sağlıqla qal sonsuzluq!
Sözümdə durmadım.
Mən yenə yalnız ququ quşu kimi
Ömür keçirirəm özgələrlə.
(Сөрелдем мин Күктән. Хуш чиксезлек!
Тугры калалмадым антларга.
Үзем тагын ялгыз күке кебек,
Юрап ятам гомер ятларга.)

Сөрген тормышын тасвирлаган шагыйрь үзенең мәңгелек белән хушлашып китүе турында яза. Монда мәңгелек белән хушлашу үлемсезлеккә ишарә ул. Ягъни дөньяда мәңгелек – беркайчан да соңы булмаган нәрсә. Сөргеннең дә ахыры булмаячагын, башка кайта алмаячагын ассызыклый. Үз илендә кала алмавында үзен гаепле сизеп, «тугры кала алмадым антларга» ди. Алдагы юлларда сөргенлек тормышын күкенең яшәү рәвеше белән чагыштырып, сөргеннән соң һәрвакыт йорт-җирсез булачагына ишарәли. Күке биредә сөрелгәннәрне, йортсыз-оясызларны гәүдәләндергән образ булып тора. Шигырьнең башка юлларында сөрген белән бәйле башка образлар да иҗат ителгән. Монда мәгънәви, рухи сөрген, телдән-сүздән сөрелү һәм башкалар да урын алган.

Р.Аймәт шигырьләре, хәзерге татар әдәбиятының күпкырлы, бай үрнәге буларак, азәрбайҗан укучысы тарафыннан кызыксыну белән кабул итәлде, яңа татар әдәбияты белән танышу өчен нигез тудырды.

Сәхавәт САҺИЛ,
азәрбайҗан шагыйре,
тәрҗемәче, галим.
(Азәрбайҗанчадан
Фәридә Таһирова тәрҗемәсе).

Яңа алым

Татар теле бетә, юкка чыга, кирәге калмый, диләр. Ана кеше үз баласын, татар сыйныфына эләкмәсен өчен, махсус рәвештә рус сыйныфына яздыра. Чын татар әниләре шундый юлдан тайпылганда, ничек итеп милләт киләчәген күтәргә була, ди?

Мондый күренешкә тыныч кына карап булмый шул. Шул максат белән, зуррак балалар төркеме тәрбиячесе Наилә Назмеева белән «Бәләкәч ТВ» проектын чыгардык. Атна саен мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән интервьюга йөрибез. Махсус сайтка урнаштырып барабыз. Әлеге төркемдәге рубрика, интервьюларны бик яратып күзәтеп баралар.

Интервью булдырганчы, балага җанлы сөйләмгә чыгар өчен тыңлап алу күнекмәсен булдырырга кирәк. Бала шул рәвешле монологик сөйләмгә бара. Безнең максат – мәктәпкә әзерлекле бала булдыру, татарча киң аралаша, татарча фикерли ала торган итеп, төрле юнәлештәге белгечләр белән рәхәтләнеп сөйләшә ала торган балалар әзерләү.

Балалар һөнәрләр турында без – зурлар кебек фикер йөртми. Интервьюга әзерләнгән вакытта бу сорауларны бергәләп әзерлибез, ләкин безнең сораулар олылар тормышыннан алынган. Без – олылар тормышны олыларча күрәбез, ләкин балаларның фикерләве башкача. Тәрбияче үзе дә бала кебек уйлый, фикерли белергә тиеш. Гадәттә, укучы укытучыдан өйрәнә, безнең очракта без үзебез нарасыйлардан өйрәнәбез.

Үз эшенең остасы булган кешеләр янына барып, алардан төрле сорауларыбызга җаваплар алганчы, башта балаларның фикерен тыңлыйбыз. Һөнәр ияләренең атрибутлары белән уйнап карыйбыз, нинди сорауларга җавап табырга теләгәннәрен, нәрсә борчыганын белешәбез. Аларга нәрсә кызык, ниләр белергә теләүләрен ачыклыйбыз. Интервью өчен сорауларны шулардан чыгып әзерлибез.

Мәктәптә татар телен чит илләрдән кергән яңа алымнар алып өйрәтәләр, башка чит төбәктән үрнәк алалар, аларга карап укыту планын төзиләр. Ә безнең балалар бакчасында без башлап җибәргән проект – интервью әзерләү аша татар телен өйрәнү, үстерүне «яңа алым» дияр идем. Чөнки әле беркемнең дә болай эшләгәне юк. Бу – безнең өчен сынау, тәҗрибә, үсеш. Татар методикасында яңалык, дияр идем.

Бу проектыбыз, бәлки, уңышлы да чыкмас, ләкин бу процесс безгә, әти-әниләргә, балаларга нык ошый. Әти-әниләр бу очракта безгә канат куя. Без әлегә бирешмибез, алга барабыз, тырышабыз, тәҗрибә, яңа идеяләр туплыйбыз.

«Һөнәрләр» тапшыруы – татар телен үстерү, яисә олылар тормышы белән танышу гына түгел, ул безнең социаль проект та. Социаль проект – безгә мегаполистан еракта булган шәһәрләрдә үз эшенең остасы булган алтын куллы, сәләтле, алдынгы кешеләрне таныту, аларның фикерләрен халыкка житкерү, эш процессын күрсәтү. Проектыбыз Татарстанга гына түгел, чит төбәкләрдә яшәүчеләр өчен дә актуаль проект булырына ышанам.

Һәрбер тапшыруыбыз чын йөрәктән эшләнә. «ВКонтакте» социаль челтәрендә дә «Бәләкәч ТВ» дигән үзебезнең сәхифәбезне булдырдык. Барлык видео, рубрикаларны шунда урнаштырып барабыз. Әти-әниләрнең фикерләрен дә шунда ишетәбез.

Эшебез дәвамлы булсын иде. Татар телебез бетмәс, үсәр, әлбәттә, киләчәге бар, дигән өметләр белән янып эшлибез. Тел бетсә милләт бетә, милләт бетсә – халык бетә, дигән сүз. Телебез, милләтебез язмышы безнең – тәрбиячеләр кулында.

Гөлия СӨНГАТУЛЛИНА,
Мамадышның «Бәләкәч» балалар бакчасында татар телен өйрәтүче тәрбияче
intertat.tatar

Гармунчы Люция

Халкыбыз көйләрен сәхнәдә яңгыраткан, күп кенә җырчыларга аккомпаниатор булган хатын-кыз баянчы-гармунчыларыбыз бармак белән генә санарлык. Заманында Рокыя Ибраһимова белән Мохтар Әхмәдиевнең чыгышларын, Усман Альмеевнең Римма Сафинага кушылып җырлавын тамашачы көчле алкышларга күмгән, Флера Хөрмәтова уйнаган бию көйләре бүген дә бәйрәм-мәҗлесләрнең күрке булып тора. Аларның иҗатларын дәвам итүче танылган музыкант Люция Камалова – гомере буе профессиональ сәхнәдә кулында кош сайраткан, аккордеонда, эреле-ваклы гармуннарда уйнау остасы!

Аның уен кимәле нәзакәтле, хатын-кызларча мөлаем. Бигрәк тә кечкенә концерт гармуннарында татар халык көйләре тезмәсен уйнап җибәрсә, аңа карап тагын бер кат сокланып куясың. Нигездә, ул гомере буе аккомпаниатор буларак бик күп җырчыларга аккордеонда, синтезаторда уйнаган музыкант. Шөкер, аның кечкенә чагыннан ук булган хыялы – олпат артистларга сәхнәдә уйнау теләге тормышка аша, заманында ул Илһам Шакиров, Габдулла Рәхимкулов, Хәнәви Шәйдуллин кебек күренекле җырчылар белән күпмедер эшләү бәхетенә ирешә. «Әлфия апа Авзалова белән генә гастрольләргә чыгып булмады, бик эшлисем килгән иде дә, тик ул вакытта Хәмдүнә апа Тимергалиеваны ташлап булмый иде шул», – дип искә ала Люция ханым. Әйе, әлеге шәхесләр белән зур тәҗрибә туплый, иҗат мәктәбен үтә ул. Шулай ук аңа Рөстәм Маликов, Искәндәр Биктаһиров, Рабига Сибгатуллина, Фердинанд Фәтхи, Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар кебек танылган җырчыларга да уйнарга насыйп була. Аларның байтак чыгышлары Татарстан радио-телевидениесе алтын фондында урын алган.

Люция Хәсән кызы июль аенда үзенең алтмыш яшьлек юбилеен каршы ала. Аны күркәм юбилее белән тәбрик итәбез, саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез. Аның Кадыш мәдәният йортында узачак юбилей-иҗат концерты сентябрь аена ниятләнгән.

Ул Пермь өлкәсенең Гайнә районы Кебрат бистәсендә туа. 1971 елда аларның гаиләсе Казанга күченеп килә, ул кечкенәдән музыкаль мохиттә тәрбияләнеп үсә, чөнки эти-әнисе икесе дә бик яхшы тальянда уйнаган. Дүрт-биш яшендә Люция дә әлеге тальянны кулына ала, үзенчә көйләр чыгара. Тора-бара остарып, бик күп көйләр өйрәнә. Мәктәптә укыганда ул үзешчән сәнгатьтә катнаша, концертларда уйный. Гармунчы булырга хыялланган кызны эти-әнисе Гайдар исемендәге балалар студиясенә юллый. Аны тәмамлагач, ул 1980-1985 елларда Казан музыка училищесында аккордеон классында белем ала. Берникадәр вакыт Апас районы музыка мәктәбендә балаларга баян дәресләре бирә. 1988-1992 елларда Якутиядә Нерюнгри шәһәрендә «Шатлык» татар-башкорт ансамблен җитәкли. Уңышлы чыгышларыннан соң, коллективка «Халык ансамбле» исеме бирелә. Әлеге ансамбль белән татар халкының Казанда Бөтендөнья татар конгрессы уздырган беренче корылтаенда делегат буларак чыгыш ясавын, ул әле бүген дә горурланып искә ала.

1992 елда ул Казанга кайтып, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә урнаша, аны күренекле җырчы Хәмдүнә Тимергалиева иҗат бригадасына билгелиләр. Кайда гына чыгыш ясамый алар, Татарстанның һәм Рәсәйнең бик күп төбәкләрендә гастрольләрдә булалар. Люция Камалова филармониядә 2003 елга кадәр эшләү дәверендә тагын бик күп татар җырчыларының аккомпаниаторы була, үзе солист булып вак гармуннарда уйный.

2003-2012 елларда ул Казан шәһәре Авиатөзелеш районында «Балалар тәрбияләү үзәге»ндә педагог-оештыручы булып эшли. Ул төрле кичәләр оештыра, мәктәп балаларын музыка осталыгына өйрәтә, иҗат итүдән туктамый.

2019 елдан бүгенге көнгә кадәр ул Казан шәһәре Кадыш бистәсе Мәдәният йортында «Зәңгәр күл» вокаль ансамбле җитәкчесе һәм аккомпаниаторы булып эшли. Өлкән буын сәнгатькә гашыйк җырчыларны туплаган бу коллектив белән алар бик күп мәдәни чараларда, сабан туйларда, концертларда чыгыш ясый, республика күләм фестиваль-конкурсларда җиңүләр яулыйлар. Әле күптән түгел өлкән булуларына карамастан, Башкортостанга кадәр барып Хәмдүнә Тимергалиева исемендәге беренче җыр фестивалендә җырлап кайтканнар.

Былтыр ул республика күләмендә үткәрелгән «Ел хатын-кызы» бәйгесенең «Мәдәният һәм рухият» номинациясендә җиңеп, Казан мэры И.Р.Метшин тарафыннан истәлекле дипломга һәм бүләккә ия була.

Люция Камалова Татар дәүләт филармониясе сәхнә ветераннары катнашында узган төрле чараларда да чыгыш ясый. Узган елларда ул филармония музеена үзенең концерт аккордеонын һәм вак концерт гармуннарын бүләк итеп тапшырган иде. Бик кадерле булган әлеге тарихи гармуннарны аңа заманында музыкант, сәхнә остасы Мостафа ага Сәләхетдинов бүләк итә. Люция ханым үзе белән бергә эшләгән сәнгать осталарын хөрмәт, рәхмәт белән искә ала.

Алсу ХӘКИМОВА,
Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музее мөдире.

●Беренче рәттә сулдан Диләрә Ильясова, Люция Камалова, икенче рәттә Ганс Сәйфуллин, Илһам Шакиров, Рөстәм Вәлиев.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

1 июль (шимбә). ***Зөлхиҗҗә аеның 13нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 19.57 сәгатьтә калка, 1.47 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.28 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Сарут сихәте (1)

Подагра, остеохондроз, артрит, артрозны дәвалау өчен, 2 аш кашыгы вакланган сарут тамырын ярты литр кайнар суга салып, термоста 8 сәгать тәнәтәләр. Көненә 3-4 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, яртышар стакан эчәләр. Чуан чыкканда, 3 аш кашыгы вакланган тамырны 3 стакан кайнар суга салып, сүрән утта 5 минут пешерәләр, 1 сәгать тәнәтәләр. Тәнәтмәне җылытып, көненә 3 тапкыр, ашарга 1 сәгать кала 1 әр стакан эчәләр.

2 июль (якшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 14нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,21.17 сәгатьтә калка,2.36 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.28 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Сарут сихәте (2)

Бөердәге һәм бәвел куыгындагы ташлардан котылу өчен, 4 аш кашыгы вакланган тамырны 1 литр суда 4 тапкыр кимегәнче кайнаталар, 1 сәгать тәнәтеп, сөзәләр, көненә 4-5 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр аш кашыгы эчәләр. Экзема, нейродермит, псориазны дәвалау өчен, 50 шәр грамм вакланган сарут һәм әрекмән тамырларын кушып, 3 литр кайнар суга салалар, сүрән утта 10-12 минут пешерәләр, ярты сәгать тәнәтәләр, сөзеп, ваннадагы җылы суга кушалар да, йокларга 1 сәгать кала 10-15 минутка шунда кереп яталар.

3 июль (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 15нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 22.49 сәгатьтә калка. 14 сәгать 39 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 17.26 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Алабута

Алабута аскорбин кислотасы, каротин, эфир майлары, кузгалак кислотасына бай. Эч киткәндә, авитаминоз булганда, иммунитетны ныгыту өчен, 1 аш кашыгы вакланган үләнне 1 стакан кайнар суда җылы урында ярты сәгать тәнәтәләр, сөзәләр, көненә 4 тапкыр, ашарга 1 сәгать кала, 50 шәр мл эчәләр.

(**Дәвамы 18 нче биттә**).

Айга кырын карама

4 июль (сишәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 16нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 22.49 сәгатьтә калка, 3.52 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.25 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

5 июль (чәршәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,23.11 сәгатьтә калка, 5.25 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.23 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Безләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Уяу булу зарур

Кардиологлар фикеренчә, 35 яшьтән соң һәр кеше артериаль кан басымын контрольдә тотарга тиеш – нәкъ шул яшьтә гипертония башлану ихтималы зур. Шуңлыктан әледән-әле тикшеренергә: көндәлек табыннан майлы һәм холестеринлы ризыкларның санын киметергә; тәмәкене ташларга; ябыгырга; физик активлыкны арттырырга кирәк. Кан тамырларын чистарту өчен, 5әр аш кашыгы нарат ылысы һәм суган кабыгын, 3 аш кашыгы гөлҗимешне 4 стакан суда кайнатып, җылы урында төн буе төнәтәләр, иртән сөзеп, көненә 3-5 тапкыр эчәләр, һәр порциягә 1 чәй кашыгы яңа сыгылган лимон согы кушалар.

6 июль (пәнҗешәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 18 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 23.25 сәгатьтә калка, 7.05 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.21 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Бөерне чистарту

Чөгендерне чистартып, дүрткә бүләләр дә, ярты стакан су, 2 аш кашыгы үсемлек мае өстәп, томалап, газ мичендә ярты сәгать пешерәләр. Аннары чөгендерне һәм 2 бүлем сарымсакны эре угычта уып, каймак өстиләр дә, кичке аш урынына икмәксез ашыйлар, аннан соң балсыз чәй эчәләр.

7 июль (җомга). ***Зөлхиҗҗә аеның 19нчы көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында,23.35 сәгатьтә калка, 8.44 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.20 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җыеп үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Җылы салат

500 г ташкабак, 1 бәйләм яшел суган, берничә бүлем сарымсак, үсемлек мае, төелгән кызыл борыч кирәк. Яшь ташкабакларны башта буйга кисеп, ярымтүгәрәкләп турыйлар да, тоз сибәләр. 10 минуттан соң, суын сыгып, кипшендерәләр, табаның капкачын каплап, үсемлек маенда кыздыралар. Ташкабак йомшаргач, уттан алып, вак туралган сарымсак һәм яшел суган өстиләр, яхшылап болгаталар да, кызыл борыч сибәләр.

Табылдык хөкеме

Табылган әйберләр (локта) турында нинди хөкемнәр бар?

Ризалыгыннан башка бүтән кешенең малын алу дөрес булмаган кебек, югалган малны алып үзләштерү дә рөхсәт ителми. Бәндә берәр урында күпмедер күләмдә акча яки әйбер тапса, аны иясенә тапшыру өчен алырга мөмкин. Ләкин үзенең малы итү өчен алу башка кешенең малын урлау белән тиң була.

Әгәр табылган урында калдырылса, юкка чыгуыннан куркып, әйберне иясенә бирү максатыннан алу вәҗиб. Юкка чыкмаячак нәрсәне алу исә мөбах. Тапкан берәр нәрсәне алганда, кеше аны иясенә тапшыру өчен алуына әйләнә-тирәдәгеләрне шаһит итә. Әгәр иясе табылып, аның үзенеке булуын раслый алса, әйбер аңа тапшырыла.

Табылган әйбер әманәт хөкемендә санала. Кулында табылган әйбер булган кеше моны тиеш дип исәпләнгән вакыт кадәр игълан итеп көтәргә тиеш. Әгәр иясе табылмаса, аны фәкыйрьләргә иясе исеменнән сәдака итеп бирә. Әгәр үзе мохтаҗ булса, аннан үзе дә файдалана ала. Ләкин соңрак иясе табылса, шул әйбернең бәясен түләргә тиеш. Иясен эзләү урынсыз арзан бәяле әйберләр исә, көтеп тормастан, мохтаҗларга бирелергә мөмкин, ихтыяҗы булса, тапкан кеше дә файдалана ала.

Тәкәбберлек

Бер көнне Габдуллаһ ибне Гамр Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Матур кием киюем тәкәбберлекме?» – дип сорый. Рәсүлуллаһ: «Юк», – ди. Аннары Габдуллаһ: «Нәселле дөягә атланып йөрүем тәкәбберлекме?» – дип сорагач, Рәсүлуллаһ янә: «Юк», – дип җавап бирә. «Яхшы, – дип дәвам итә Габдуллаһ. – Берәр ризык әзерләп, кешеләрне чакырсам, алар минем янымда ашасалар, артымнан йөрсәләр, бу тәкәбберлекме?» Аллаһ Рәсүле тагын: «Юк», – дип кабатлый. «Алайса тәкәбберлек ни була?» – дип сорый Габдуллаһ.

Шуннан соң Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип ачыклый: «Тәкәбберлек Хак Тәгаләгә әһәмият бирмәү һәм кешеләргә түбәнсетеп карау» (Ибне Хәнбәл, II, 170).

Пәйгамбәребез әйткәннәрдән нигъмәтләрне чикләгән бердәнбер нәрсәнең тәкәбберлек һәм исраф булуы күренә. «Тәкәбберлеккә төшмичә һәм исраф кылмыйча (теләгән кадәр) ашагыз, сәдака бирегез һәм киенегез!» – хәдисендәге (Нәсаи, «Зәкят», 66) күрсәтмә түбәндәге аятьтә аеруча басым ясап әйтелә: «Әй, Адәм балалары! Мәчеткә барганда һәрчак матур киемнәрегезне киегез, ашагыз, эчегез, ләкин исраф итмәгез, чөнки Ул (Аллаһ) исраф кылучыларны сөймәс» («Әл-Әгъраф», 7/31).

Илаһи тәртип хикмәте

Аллаһ Тәгалә аяти кәримәдә әйтә: «Алар Аллаһның ихтыяры белән аларны тар-мар иттеләр. Давыт исә Җалутны үтерде. Аллаһ аңа (Давытка) хакимлекне дә, хикмәтне дә (пәйгамбәрлек) бирде һәм аңа үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтте. Әгәр дә кешеләрнең берәүләрен икенчеләреннән Аллаһның яклавы булмаса, җир бозылыр иде. Әмма Аллаһ – бөтен галәмнәргә карата фазыйләт иясе» («Әл-Бәкара», 251).

Бу аяти кәримә дөнья тормышында хакимлек иткән илаһи тәртип турында билгеле бер аңлатма бирә. Чыннан да, әгәр Аллаһ Тәгалә кешеләр арасында гаделлек белән идарә итә торган җитәкчеләр булдырмаса, кешеләрнең көчлеләре зәгыйфьләрне изеп-кимсетеп бетерер иде. Бу яктан караганда, риваять кылынган бер хәдисне искә алырга мөмкин: «Солтан – Аллаһның җир йөзендәге шәүләсе ул». (Хәйсәми, «Мәҗмагуз-Зәваид», Дәйләми, «Мүснәд»).

Хәзрәти Госман радыйаллаһу ганһе: «Һичшиксез, Аллаһ Коръән белән тыймаган нәрсәне солтан белән тыяр», – дип әйткән (Ибне Кәсир, «Кыйсасүл-Әнбия»).

Икенче яктан караганда исә, Аллаһ Тәгалә кешеләр арасында иҗтимагый баланс урнашуны берничә сәбәпкә бәйләгән. Шул нигездә кешеләрнең бер өлеше бай, бер өлеше ярлы, кайберләре көчле, кайберләре зәгыйфь, бер өлеше сау-сәламәт, бер өлеше авыру, бер өлеше мөэмин, бер өлеше кяфер булачак, ләкин алар арасында корылырга тиешле мөнәсәбәтләр кешеләрнең җәмгыять рәвешендә яшәвен тәэмин итә алсын. Электрик көчәнешле уңай һәм тискәре полюслар арасында очкын һәм энергия барлыкка килгән кебек, уңай һәм тискәре холыклы кешеләр арасында формалаша торган көрәш-сугышларда бик күп хикмәтләр бар.

Сорау бирү

Белем ачкычы – сораулар бирү. Кешеләргә сораулар бирергә этәргән нәрсә – бер яктан кызыксыну, икенче яктан – яңалыкны өйрәнү өчен инстиктив омтылыш.

Кешеләр арасында элемтәләрнең бер төрен тәшкил иткән сорау бирү гамәленең үз әдәп һәм ысуллары бар. Формасы диалог рәвешен алса да, ике төп шарт һәрвакыт үтәлергә тиеш. Беренчесе – белгән кешедән сорау, икенчесе – кирәксез сораулар бирмәү. Коръәни-Кәримдәге: «Белмәсәгез, китаплылардан (гыйлем ияләреннән) сорагыз», – аяте («Әл-Әнбия», 21/7) кешеләргә белмәгәннәрен сорарга һәм белгәннәрдән сорарга киңәш итә. Ә Пәйгамбәребезнең: «Шөбһәсез, Аллаһ сезнең өчен өч нәрсәне әшәке дип күрә: гайбәт, мал-мөлкәтне әрәм итү, һәм күп сораулар бирү», – хәдисеннән (Бохари, Зәкят, 53) кирәксез сораулар бирелмәскә тиешлеген аңлыйбыз.

Дәрес вакыты, әңгәмә, урамда, мәчеттә, кыскасы, сорау бирү тормышның барлык өлкәләренә хас. Нинди генә мохиттә бирелсә дә, сорау бәхәс яки полемика максатын күз уңында тотырга тиеш түгел. Сорауның максаты мәгълүматны куллану һәм аңлау булырга тиеш.

Сөйләшү әдәбе

Аллаһ Рәсүле: «Сүзнең иң матуры – Аллаһның Китабы, юлларның иң күркәме исә – Мөхәммәднең юлы», – дип әйткән (Нәсаи, «Сәху», 65). Шуңа күрә әңгәмәләр, Коръән һәм сөннәт принципларына туры килү дәрәҗәсенә карап, кыйммәткә һәм күркәмлеккә ирешәчәк. Чөнки мөселманның Алла каршында кыйммәтен арттыра торган үзенчәлекләрнең берсе – аның күркәм сүзле булуы (Ибне Хәнбәл, V, 378).

Коръәндә төрле хәерле һәм күркәм сүзләр, аеруча кәлимәи тәүхид, тамыры ныклы, ботаклары күккә ашкан һәм һәрвакыт җимеш бирә торган агачка (Ибраһим, 14/24-25); төрле начар сүзләр, аеруча ширк каты, җирдән тартып алынган һәм басып тора алмаган тамырсыз агачка тиңләнә («Ибраһим», 14/24-26).

Шуңа күрә әңгәмәдән файдалы нәтиҗәләр алу өчен, матур һәм файдалы сүзләрне сайлап алырга һәм дөрес һәм эффектив стиль кулланылырга тиеш, чөнки «Золымга тарыган хәлдән кала, Аллаһ ачыктан-ачык әшәке сүз әйтүне яратмый» («Ән-Ниса», 4/148). Хәзрәти Пәйгамбәр беркайчан да әшәке сүзләр әйтмәгән.

Күкләр дә разый булгандыр

Июнь көненең бер иртәсендә Исмәгыйль авылының урамнарында гадәттән тыш җанлылык сизелде: авылга кергәндәге урам чатында корылган стендта күренекле авылдашларның портретлары куелган; урамнардагы агач ботакларына, коймаларга төсле шарлар эленгән; урамда – бәйрәмчә киенгән олысы-кечесе югары оч зиратына ягына атлый; саф һавада тамакны кытыклап пылау вә үләнле чәй исе тарала...

Чишмә янындагы аланда учаклар тирәсендә хатын-кызлар мәш килә; ир-егетләр өстәл-урындыклар, радио-аппаратурасын көйли... Бәләбәйнең тарихи мәчете имамы Илдар хәзрәт ирләрне авылның зиратына әйдәде... Үзенең җыйнак кына вәгазеннән соң, әрвахлар исеменә Коръән аятьләре укыды, Бәләбәй мәчетенең мәдрәсәсендә белем алган шәкертләр теленнән дә аятьләр яңгырады.

Исмәгыйльлеләрнең әрвахларны искә алу чарасы – авылга бәрәкәт сорап оештырылган Коръән ашы шулай башланып китте. Чишмә буенда инде табын корылган, ашлар пешкән, өстәлләр тәмле ризыклар белән тутырылган.

Хәзрәт Коръән аятьләре укып, тагын дога кылу оештырды. Ошбу җыенның тирә-юньдәге авыллар өчен бик күркәм үрнәк булуын ассызыклады. Аннары әлеге чараны оештыруны башлап йөрүчесе Финүс Хәлиуллин сүз алды:

– Төш күрдем. Имеш, авыл өстенә таба ниндидер утлы яңгыр килә. Халык, кубарылып, яклау, котылу эзләпме Бәләбәйгә таба йөгерә, имеш. Ни эшләргә? «Авылдашлар, болай качып котылып булмастыр төсле, әйдәгез, туктап, бергәләп җыелып, Аллаһтан сорыйк, тәүбә итик, афәт китермәсен үзебезгә һәм авылыбызга...» – дим. Уянгач та уйлап яттым: ә бит чынында да мондый заманда, Аллаһка сыгынуыбыз җитеп бетми түгелмени? Тик бу эшне ничек оештырырга?

Нәкъ шул көннәрдә, мәчетебезнең шура әгъзасы Нурмөхәммәт әфәнде Хөсәенов, үзләренең туган авылына Бәләбәйдән җыйналып кайтып сабантуй уздырулары, булачак мәчет җирлегендә корбан чалып, казаннар асып, өстәлләр корып, авылдашларын җыйнап Коръән ашы үткәргәнен сөйләгән иде... Бу үрнәк күңелемә хуш илде.

Җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, Бәләбәй татар гимназиясенең элеккеге директоры Нурмөхәммәт Хөсәеновка сүз бирелде. «Татары Уфимского уезда в переписях» китабында Исмәгыйль авылына кагылышлы очракларны яктыртып, шул исәптән бу авылның, кайчандыр калмыклар һәм казаклар ярдәмендә кыйратылган Нугай татарлары урдасы җирләрендә килеп урнашкан татарлардан башланганлыгы һәм башлангыч чорда аларның ике «типтәр командасы» составында Россиянең Оренбург линиясендә «кыргыз – кайсаклар» белән булган чикләрен саклап, «мишәр-татар гәскәре»ндә хезмәт кылулары турында сөйләде. Ник «типтәр» дип язылган? – дигән сорауга ул, әлеге (3 нче) җанисәп алдыннан бирегә күчкән, хезмәткә яраклы бар ир-егетләрне дә «реестровый казаклар» өчен язылган Устав буенча хезмәткә буйсындыру сәбәпле, шулай ук «реестровыйлар», ягъни, татарча әйткәндә, «дәфтәргә теркәлгән» дигән сүздән алып, аннары, кыскача гына «дәфтәрле», «тәфтәрле», ә урыс теленә бераз бозылган рәвештә, кыскартылып, дәфтәр – «типтәр» булып язылып кереп киткәнне ачыклап бирде.

Исмәгыйль авылының башлангычының Мәскәүнең «Борынгы актлар теркәү буенча Дәүләт Архивы» фондларындагы, 1762 елга караган 3 нче җанисәп нәтиҗәләрендә күрсәтелгән мәгълүматларында беренче башлап теркәлүдән гыйбарәт булып бер «команда»ның, ә 4 нче җанисәптә (1782) «ясашная татара» статусында, икенчесенең «татар-типтәр» командасы булып калуын күрсәтеп үтте.

Тарихчы, бер ел гына элек басылган «Контуры Великой Татарии» китабы турында әйтеп китте: «Бу китап басылып чыгып 7 ай үтүгә, Россия фәннәр Академиясе, Казан федераль университетында халыкара фәнни семинар үткәрде һәм, моңарчы фәндә өстенлек иткән «монгол» империясен инкяр итеп, Бөек Татария дәүләте булганлыгын таныды: «Һәм дә моның белән «монгол-татар игосы» мифының үзәге җимерелә башлады, – дип ассызыклады ул – озакламый ул тарихи әкият тәмам фаш ителер», – диде тарихчы.

Татарның чын тарихын барлауга багышлаган күләмле хезмәтне гамәлгә куюга исмәгыйльле өч ир-егет тә – аталы-уллы Әфгать һәм Илгиз Исхаковлар һәм Финүс Хәлиуллин иганәчелек ярдәме күрсәткән икән.

Нурмөхәммәт Хөсәенов җыелган халыкка, «Уфа уезды татарлары» турындагы китаптан алып әзерләнгән, Исмәгыйль авылына кагылышлы белешмәлек белән беррәттән, үзләре язылып-алдырып килгән «Мәдәни җомга», «Безнең гәҗит», «Безнең мирас», «Бәләбәй хәбәрләре» басмаларын да таратуны оештырды.

Җыенда Рузилә ханым Халиуллина моңлы тавышы белән эчтәлекле мөнәҗәтләр башкарды.

Дистә еллар элек, данлыклы Бәләбәй педучилищесының татар бүлеген тәмамлагач, бирегә килеп, Исмәгыйль авылы балаларына аң-белем биргән укытучылар – Рузилә Садыйкова, Нәгыймә Хайретдинова, Лилия Исхакова фәһемле вә сагышлы истәлекләрен сөйләде. Әлеге матур очрашу эшчән, үз вакытында тирә-юньдә хезмәт батырлары белән дан тоткан, илебез өчен күп эшлекле шәхесләр үстергән Исмәгыйль авылы халкының олысына да, кечесенә дә хуш килде...

Раил ЮСУПОВ.
Бәләбәй шәһәре.

Җиңүчеләр Мәскәүгә бара

● **Конкурсның Казандагы сайлап алу турында катнашучылар.**

«Талантлар җире» X Бөтенроссия балалар һәм яшүсмерләр иҗаты конкурсының регионара сайлап алу турында Татарстан, Башкортстан һәм Пермь краеннан ике йөзләп вәкил катнашты, алар 92 концерт номеры күрсәтте. Ул Казанның А.С.Пушкин исемендәге мәдәни үзәгендә узды. Конкурсның беренче этабы май аенда Әлмәт, Чаллы, Казан зоналарында җиңүчеләрне ачыклады. Аларда җыр, бию һәм нәфис сүз номинацияләрендә 7-17 яшьлек балалар чыгыш ясады.

Яшь иҗатчыларны Россия Дәүләт Думасы депутаты Артём Прокофьев, аның ярдәмчесе, Татарстан комсомолы лидеры, республика яшьләр парламенты әгъзасы Илнур Зарипов, ЛКСМ Үзәк комитеты секретаре Денис Курочкин, Казан шәһәр Думасы депутаты Динара Хәлимдарова һ.б. рәсми затлар сәламләде, истәлекле бүләкләр тапшырды.

Жюрины узган елларда Г.Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, язучы Ренат Мөхәммәдиев, Татарстанның халык артисты, композитор Әнвәр Шәрәфиевләр җитәкләгән булса, быел Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор Риф Гатауллин рәислек итте. Жюри әгъзалары арасында Татарстанның атказанган артисты, баянчы Рафинад Сәләхов, Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты хореографы Бәхрүз Мәүлүнов, Мәскәүнең театр һәм кино йолдызы Ольга Зейгер бар иде.

Конкурста җиңүчеләр сентябрь аенда Мәскәүдә көч сынашачаклар. Алар арасында Казаннан – җырчылар Диләрә Фәсхиева, Зәринә Кәримова, шулай ук җыр һәм бию буенча күмәк номерлар белән чыгыш ясаучылар бар. Катнашучылар арасында Чистай, Азнакай, Сарман, Туймазы (Башкортстан) районнарыннан килгән балаларны күрү конкурсның киләчәктә киңрәк колач алачагына өмет тудыра.

Мәдәният һәм Яшьләр министрлыклары, «Транснефть-Прикамье» АҖ, шулай ук иҗтимагый оешмалар, шул исәптән комсомол оешмалары белән берлектә үткәрелә һәм яшь талантларга үсәргә этәргеч бирә торган мондый чараларда катнашучылар киләсе елларда барлык район-шәһәрләрдән дә булыр дип өметләнәбез.

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

30 июнь, 1-3, 5 июль – 13.00, 15.00, 17.00, 19.00 – Шәрык клубына театраль сәяхәт. 20.00 – Г.Камал театры оркестры концерты.
4 июль – Шәрык клубында – саксофон музыкасы кичәсе.
6 июль – Шәрык клубы кинотеатрында – «Банкрот» спектаклен экран аша күрсәтү (Г.Камал).
7 июль – Шәрык клубында – «Моңлы бер җыр» дип исемләнгән концерт.

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

1, 2 июль – «Ромео и Джульетта» (С.Прокофьев).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

4, 6 июль – «Тинчуринда кунакта» дип исемләнгән квест.

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

30 июнь – «Ал җилкәннәр» спектакленең ачык репетициясе. (А.Грин).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

30 июнь – 15.30 – театр буйлап сәяхәт. 19.00 – «Авиатор» (Е.Водолазкин).
1 июль – Зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән). Кече залда – «Серая шейка» (Д.Мамин-Сибиряк).
2 июль – фойеда – «Бобровый пруд». Зур залда – «Конек-Горбунок» (П.Ершов). Кече залда – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
6, 7 июль – Театр буйлап сәяхәт.

Дару түгел, агу

Аризона университеты галиме Шоун Юнгштедт йоклата торган даруларны көн саен бер кап тәмәке тарткан кебек үк зыянлы, дип саный. Алар йөрәк өянәге ихтималын арттыра һәм баш миен зарарлый, акылны зәгыйфьләндерә, вестибуляр аппарат эшен боза. Йокысызлыктан бөтен дөнья халкы интегә. Мәсәлән, АКШ та гына да бүген андыйлар саны 100 миллионнан артып китә, аларның күпчелеге дарусыз йоклап китә алмый. Хәзер бу даруларның “Z-препаратлар” дигән яңа буыны пәйда булган, алар бәйлелек тудырмый, дип исәпләнә. Тик аларны кулланучыларның да реакциясе акрыная, чөнки даруларның тәэсире көндез дә саклана. Шунлыктан йокы даруы бик күп автомобиль һәлакәтләренең сәбәбе булып тора. Вашингтон университетында үткәрелгән тикшеренү йокы даруының акылны зәгыйфьләндерүен дәлилләгән. Инглиз галимнәре исә киң таралган йокы даруларының үпкә ялкынсынуы куркынычын арттыруын ачыклаган. Шунлыктан, доктор Юнгштедт әйтүенчә, тиз йокыга китү өчен җиңелчә физик күнегүләр ясау, җәяү яки велосипедта йөреп керү күпкә файдалырак.

(“The Washington Times”).

Лаеклы пенсия!

АКШта яшәүче ирле-хатынлы Джереми Джейкобсон һәм Уинни Цэн, утырып уйлангач, чәч агарганчы эшләү - гомерне заяга үткәрү ул, дигән фикергә килгән. Яшьләр үзләренә 40 яшь тулгач лаеклы ялга чыгарга карар кылган. Планнарын тормышка ашыру өчен, аларга 10 ел вакыт җиткән. Төп стратегия сыйфатында алар радикаль экономияне сайлаган: эш хакларының 70 процентын запаска калдыра башлаганнар. Алар кечкенә фатиргә күчкән, автомобильләрен саткан, нигездә яшелчәләр белән өйдә генә тукланган, кием-салым сатып алмаган. Дистә ел буе билләрен кысып яшәгәч, Джереми һәм Уиннинең хыялы тормышка ашкан. Алар берничә миллион доллар туплаган, эшләреннән киткән һәм дөнья буйлап сәяхәткә чыккан. “Яхшы эш табу, йорт сатып алу, утыз елдан артык эшләү – күпләр өчен бу уңыш билгеләре, – дип акыл сата хәзер Джейкобсон. – Әмма тормыш болардан гына тормый, аны үзгәртеп тә була”. Алар фикеренчә, бары тик сәламәтлекне кайгырту өчен генә беркайчан да акча кызганырга кирәкми.

(“Der Spiegel”).

Яңашәбездәге яшел дөнья

Үсемлек орлыкларының үзенчәлекле “мие” бар икән, нәкъ менә ул аларга кайчан шытарга кирәклекне хәл итә. Флора серләрен өйрәнүче галимнәр ми режимында эшләүче күзәнәкләр төркемендә тап булган. Алар үсемлекләрнең үз-үзен тотышын үзгәртергә һәм һава торышын фаразларга сәләтле. Әлеге “ми” һәр үсемлек тормышындагы төп карарны кабул итә – аңа кайчан үсәргә кирәклекне билгели, чөнки орлык вакытыннан алданрак шытса – аны кырау харап итәргә, соңгарак калса – иртәрәк чыккан туганнары басып китәргә мөмкин. Бирмингем университеты галимнәре үсемлек эмбрионындагы ми кебек эшләүче күзәнәкләр төркемен “арабидопсис” дип атаган. Әлеге күзәнәкләрнең кайберләре орлыкны йоклата, икенчеләре исә уята. Алар үзара гормоннар ярдәмендә аралаша. Мондый механизм безнең баш миендә дә бар, мәсәлән, ул бер урында басып торыргамы, әллә алга барыргамы кебек гади мәсьәләләрне хәл итә. Германиянең танылган урманчысы, “Агачларның яшерен тормышы” китабы авторы Питер Воллебен исә үсемлекләр, куркыныч турында кисәтеп, бер-берсенә электр сигналлары җибәрә, дип раслый. Гомумән, менә нәрсә ачыклана: без моңа кадәр яшел дусларыбыз турында бик аз белгәнбез икән әле, үсемлекләр дөньясының никадәр катлаулы һәм кызыклы булуын хәзер генә әкренләп аңлый башлыйбыз.

(“Le Figaro”).

Иң озын юл

Дөньяда иң озын юл – Панамерика шоссесы, ул АКШның Аляска штатындагы Прадхо-Бэй бистәсеннән Көньяк Америкага, Аргентинаның Ушуайя шәһәренә кадәр 30 мең километрга сузылган. Шоссе Америкадагы континенталь дәүләтләрнең бөтен юл челтәрен бердәм системага берләштерә, 14 ил – Канада, АКШ, Мексика, Гватемала, Сальвадор, Гондурас, Колумбия, Эквадор, Перу, Чили, Аргентина аша үтә, шулай ук Боливия, Бразилия, Парагвай, Уругвай һәм Венесуэлада да мөһим тармаклары бар.

(“Die Presse”).

Алыплар гаиләсе

Бу гаиләдәге ир белән хатынның буе икесе бергә 4 метрдан артып киткәнгә, алар дөньяда иң озын буйлы пар санала. Әмма Вилко һәм Кейша Ван Клиф-Болтоннарның балалары да үзләренә охшаса, алар тиздән җиһанда иң озын буйлы гаиләгә дә әйләнергә мөмкин. Аларның 4 яшьлек уллары Лукасның буе хәзер үк 7 яшьлек баланыкы кадәр – 1,19 метр. 2 яшьлек кызлары Еваның буе да 3 яшьлекләрнеке кадәр – 0,91 метр. Вилко (2,13 метр) белән Кейша (1,96 метр) өйләнешкәч, өйләрендәге бөтен ишек уемнарын зурайтканнар, ә менә йокы бүлмәләренә зуррак карават сыймаганга, һаман да аякларын асылындырып йокларга туры килә. Колледжда каравылчы булып эшләгән Вилко исә озын буеның рәхәтен күрә – кешеләр аның кыяфәтен күрүгә үк шүрли башлый.

(“Интересно.сс”).



Курку белмәс көрәшче

Легендар каратэ остасы, кёкусинкай стиленә нигез салучы, унынчы дан иясе, һөнәре буенча хәрби очучы кореяле Масутацу Ояма (1923-1994) сугыш сәнгатенең иң атаклы вәкилләреннән берсе була. Ояма япон сугышчыларының “суккан саен бер үлем” принцибы буенча эш итә. Көндәше аның беренче сугуына блок куя алса да, икенчесеннән барыбер аяктан егыла торган була. Ояма 17 кат чирәпне, 3-4 кирпечне уч кырые белән бер сугуда вата. Илле ике тапкыр үгезләр белән сугыша, өчесен үтерә, 48 хайванның мөгезен кулы белән бәреп сындыра. Юлбарыс һәм арысланнар белән дә көрәшмәкче була, әмма рөхсәт бирмиләр. Соңрак Ояма үзе дә үзгәрә, көч белән мактану өчен хайваннарны үтерүдән туктый, каратэ турында китаплар яза, аны бөтен дөньяда популярлаштыру буенча бик зур эш эшли.

(“FB.ru”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

3 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10, 9.00 «Здравствуйте!» 16+
9.20 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00, 23.30 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.40 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Ком сәгате». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Гаилә учагы». 16+
17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
22.10 «Реальная экономика». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.45 «Йөрәктән-йөрәккә». Айрат Арсланов турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Башваткыч». 12+
9.50 Спектакль «Артист». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Флера Сафиуллина турында телеочерк. 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30 Спектакль «Беренче театр». 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы». 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
19.30, 0.40 «Калеб». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Людмила Гурченко. За кулисами карнавала». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ВЕСЕЛЫЕ ГАСТРОЛИ НА ЧЕРНОМ МОРЕ». 12+
10.55 «Люди РФ». 12+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВМЕСТЕ НАВСЕГДА». 16+
14.35 «Культурное наследие России». 12+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Тайна горы мертвецов». 16+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ШТРАФНИК». 16+
23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.00 Легенды мирового кино.
7.35 «Катастрофы Древнего мира».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 Цвет времени. Марк Шагал.
8.55 «ПО СЕКРЕТУ ВСЕМУ СВЕТУ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 «НАЗЫВАЙ ЭТО УБИЙСТВОМ».
12.45 Земля людей. «Тубалары. Деревня шаманов».
13.15 «Восточный экспресс. Поезд, изменивший историю».
14.15 «ПЕРЕХОДИМ К ЛЮБВИ».
16.30 «Влюбленные в Россию».
17.15 Мастера исполнительского искусства. Марта Аргерих.
18.20 «Запечатленное время».
18.45 «Я шагаю по Москве». Летний дождь и его последствия».
19.45 Письма из провинции.
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.10 «Сцены из жизни».
21.40 Спектакль «Женитьба».

«НТВ»

5.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «ПАЗЛ». 16+
22.10, 0.00 «МЕДИАТОР». 16+

Сишәмбе

4 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2». 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Төймә».
16.00, 0.50 «Соотечественники». 16+
18.00 «Әдәби хәзинә». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Ватандашлар». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.50 «Йөрәктән-йөрәккә». Бату Мулюков турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 18.20, 23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30 «Заман көзгесе». 6+
11.30 «Нәсыйхәт». 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Халкым минем». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ШТРАФНИК». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВМЕСТЕ НАВСЕГДА». 16+
14.35 «Культурное наследие России». 12+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Тайна горы мертвецов». 16+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.00 Легенды мирового кино.
7.35, 13.15 «Катастрофы Древнего мира».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 Цвет времени. Василий Кандинский. «Желтый звук».
8.55 «ПО СЕКРЕТУ ВСЕМУ СВЕТУ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
11.25 «СПРУТ».
12.45 Земля людей. «Нымыланы. Пленники моря».
14.10 «ПЕРЕД САМИМ СОБОЙ».
16.30 «Влюбленные в Россию».
17.15 Мастера исполнительского искусства. Пааво Ярви.
18.20 «Запечатленное время».
18.45 «Любовь и голуби». Что характерно! Любили друг друга!»
19.45 Письма из провинции.
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.10 «Сцены из жизни».
21.40 Спектакль «Укрощение строптивой».

«НТВ»

4.55 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «ПАЗЛ». 16+
22.10, 0.00 «МЕДИАТОР». 16+

Чәршәмбе

5 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «Бичаракай». 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00, 0.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым». 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем…». 12+
19.00, 0.50 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 0.25 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 18.20, 23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.50 «Йөрәктән - йөрәккә». Гомәр Бәширов турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
9.40 «Йөрәктән - йөрәккә». Флера Сафиуллина турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Кунак БИТ Шоу». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
16.30, 20.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00, 0.15 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ШТРАФНИК». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЕСЛИ ТЫ НЕ СО МНОЙ». 12+
14.35 «Культурное наследие России». 12+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Великая тайна ДНК». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.00 Легенды мирового кино.
7.35 «Фабрика времени».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «ВЫШЕ РАДУГИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 Цвет времени. Ван Дейк.
11.25 «СПРУТ».
12.45 Земля людей. «Эвены. Хранители оленьего царства».
13.15 «Катастрофы Древнего мира».
14.10 «ПРОСТИ НАС, САД...»
16.30 «Влюбленные в Россию».
17.15 Мастера исполнительского искусства. Джошуа Белл.
18.15 «Запечатленное время».
18.45 «Экипаж». Запас прочности».
19.45 Письма из провинции.
20.15 Искусственный отбор.
20.55 «Спокойной ночи, малыши!»
21.10 «Сцены из жизни».
21.40 Спектакль «Тартюф».

«НТВ»

4.55 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «ПАЗЛ». 16+
22.10, 0.00 «МЕДИАТОР». 16+

Пәнҗешәмбе

6 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «Бичаракай». 16+
10.00, 0.00 «ШИРОКА РЕКА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00, 21.10 «Соотечественники». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - наше дело». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.50 «Йөрәктән-йөрәккә». Әлфия Авзалова турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.10 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Гаилә учагы». 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». 6+
16.30 «Таяну ноктасы». 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.20 «Кунак БИТ Шоу». 16+
19.15, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
21.25 «Йөрәктән - йөрәккә». Флера Сафиуллина турында телеочерк. 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ШТРАФНИК». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЕСЛИ ТЫ НЕ СО МНОЙ». 12+
14.35 «Культурное наследие России». 12+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Нонна Мордюкова. Простая история». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
19.50 «Куклы наследника Тутти». 16+
21.00 «Время».
22.00 «МАГОМАЕВ». 16+
23.00 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.

9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «СОФИЯ». 16+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ВСЁ КАК У ЛЮДЕЙ. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.00 Легенды мирового кино.
7.35 «Леди Сапиенс».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «ВЫШЕ РАДУГИ».
10.15 «Наблюдатель».
11.15 Цвет времени. Пабло Пикассо. «Девочка на шаре».
11.25 «СПРУТ».
12.45 Земля людей. «Ассирийцы. Ладони Бога».
13.15 «Фабрика времени».
14.15 «ВТОРОЕ ДЫХАНИЕ».
16.30 «Влюбленные в Россию».
17.15 Мастера исполнительского искусства. Юджа Ванг.
18.45 «Доживем до понедельника». Счастье - это когда тебя понимают».
19.45 Письма из провинции.
20.15 Юбилей Тамары Синявской. Концерт в Большом зале Московской консерватории.
21.10 «Тамара Синявская. Сцены из жизни».
21.40 Спектакль «Кто боится Вирджинии Вульф?»

«НТВ»

5.00 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «ПАЗЛ». 16+
22.10, 0.00 «МЕДИАТОР». 16+

Җомга

7 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
5.50, 7.05, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «Бичаракай». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СЕБЕР КИЯВЕ». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
14.45 «Музыкаль мәйдан». 16+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 16+
23.00 «ПРОЩАНИЕ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.45 «Йөрәктән-йөрәккә». Әнгам Атнабаев турында телеочерк. 16+
7.00, 11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
7.15, 13.05 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 16+
8.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.50, 18.20, 23.10 «Ком сәгате». 16+
9.50, 16.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30, 19.15, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 21.25 «Уроки истории». 6+
15.30 «Әдәби хәзинә». 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан». 16+
18.00 «Яңалыклар». 12+
20.00 «Туган җир». 12+
20.30 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ТАКАЯ РАБОТА - 2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ШТРАФНИК». 16+
11.30 «МЕЖДУ ДВУХ ОГНЕЙ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «КАК ПРОГУЛЯТЬ ШКОЛУ С ПОЛЬЗОЙ». 6+
15.00 «Восемь смертных грехов». 12+
15.30 «Иван Великий. Возвращение государя». 12+
16.20 «ДВЕ ЗИМЫ И ТРИ ЛЕТА». 16+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.20 «Fam TV». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ПОХОРОНИТЕ МЕНЯ ЗА ПЛИНТУСОМ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Церемония вручения премии «Шансон года-2023». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.40, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
15.05 «Гиена Европы». 16+
16.30 «Прямой эфир». 16+
21.30 «Удивительные люди. Лучшее». 12+
23.40 «ЛЕГЕНДА №17». 6+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.30, 10.00, 12.30, 17.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.00 Легенды мирового кино.
7.35 «Колонна для Императора».
8.25 «Жизнь и судьба».
8.45 «ПРО КОТА...»
10.15 «Наблюдатель».
11.10 Цвет времени. Жан-Этьен Лиотар. «Прекрасная шоколадница».
11.20 «СПРУТ».
12.45 «Игра в бисер».
13.25 «Леди Сапиенс».
14.25 «КОГДА МНЕ БУДЕТ 54 ГОДА».
15.50 «Первые в мире».
16.05 Спектакль «Арктур - гончий пес».
17.15 Мастера исполнительского искусства. Иван Фишер.
18.00 «Забытое ремесло».
18.15 «Нина Дорлиак. Высокие ноты».
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 Искатели. «Ветлужский след. Версия».
20.35 Линия жизни.
21.30 «КУРЬЕР».
22.55 «Тамбов. Дворец Асеевых».
23.20 «ДОРОГА НА БАЛИ».

«НТВ»

4.55 «БЕРЕГОВАЯ ОХРАНА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ». 16+
16.45 «ЗИМОРОДОК». 16+
20.00 «ПАЗЛ». 16+

Шимбә

8 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «Әйдә, шаяРТ!» 16+
16.00 «Уроки истории». 6+
17.00 «Татар халык җырлары».
17.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Ватандашлар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит-шоу». 16+
23.00 «ИЩУ ДРУГА НА КОНЕЦ СВЕТА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Кыр казларын бергә каршылыйк» Марсель Иванов җырларынннан концерт. 16+
7.00, 15.05 «Сиңа Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кунак БИТ Шоу». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Шәрәфле Шәрәфи». Равил Шәрәфиевнең юбилей кичәсе. 12+
22.20 Спектакль «Моңлы ядкәр». 16+

«ЭФИР»

5.00 «Культурное наследие России». 12+
5.25 «Курская битва. Время побеждать». 16+
5.50 «Легенды кино». 16+
6.30 «Люди РФ». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты.». 6+
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «НЕЗНАКОМКА В ЗЕРКАЛЕ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МУЖСКАЯ ЖЕНСКАЯ ИГРА». 12+
14.30 «Голливуд страны советов». 12+
14.45 «Обитель Богородицы. Афон». 12+
15.45 «ВО САДУ ЛИ, В ОГОРОДЕ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КРЕПКИЙ БРАК». 16+
22.35 «ИНДИЙСКОЕ ЛЕТО». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.05 «ПроУют».
12.15 Поединки. «Счастье разведчика». 12+
13.45 «КОНЕЦ ОПЕРАЦИИ «РЕЗИДЕНТ». 12+
16.30 «Султанат Оман. Аравийское чудо».
17.30, 18.20 «День семьи, любви и верности». 12+
19.55 «Кто хочет стать миллионером?»
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «ОТЕЛЬ «ГРАНД БУДАПЕШТ». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «СТЕНОГРАММА СУДЬБЫ». 16+
17.50 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «СКОРО БУДЕТ СЧАСТЬЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05, 14.00 Мультфильмы.
8.10 «СОРОКА-ВОРОВКА».
9.30 «Классная тема!»
10.00, 19.30 Новости культуры.
10.15 Тайны старого чердака. «Знакомство».
10.45 «КУРЬЕР».
12.10 «Курьер». Мы перебесимся и будем такими же, как вы».
12.50 «Даты, определившие ход истории».
14.40 Большой балет.
17.10 85 лет со дня рождения Андрея Мягкова. Острова.
17.50 «ГАРАЖ».
19.45 Линия жизни.
20.40 Спектакль «Безумный день, или Женитьба Фигаро».
23.00 «БАНДА ЧЕСТНЫХ».

«НТВ»

5.30 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
6.20 «ТОНКАЯ ШТУЧКА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!» 16+
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Модный vs Народный». 12+
14.20 «Своя игра».
15.20 «Игры разумов».
16.20 «ЗИМОРОДОК». 16+
19.25 «Секрет на миллион». 16+
21.30 «Просто праздник!» 12+
23.00 «Маска». 12+

Якшәмбе

9 июль

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Онытa алмыйм...» 12+
6.00 «Виталий Агаповның 60 яшьлек юбилей кичәсе». 12+
8.30 Мультфильмы.
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы-шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.20 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин. 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.00 «Ватандашлар». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «Музыкаль мәйдан». 16+
14.00 «Наша Республика - наше дело». 16+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00 «История побед. КамАЗ-мастер». 12+
19.35 «Татар халык җырлары».
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 16+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
22.00 «ЖЕЛТОГЛАЗЫЕ КРОКОДИЛЫ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 Спектакль «Мәхәббәт карагы». 16+
7.00 «Йөрәктән - йөрәккә». Туфан Миңнуллин турында телеочерк. 16+
10.00 «Әдәби хәзинә». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Иҗатханә». Рабит Батулланың бәйрәм кичәсе. 12+
15.40 «Кояшларың белән кил син миңа». Резеда Галимова концерты. 6+
16.20, 21.40 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Эльмир Низамов һәм дуслар». 16+
23.30 «Акча корты». «Мунча ташы» спектакле. 16+

«ЭФИР»

5.00 «Культурное наследие России». 12+
5.25 «Курская битва. Время побеждать». 16+
5.50 «Легенды телевидения». 12+
6.30 «Ученые люди». 12+
7.00 «Супер МЯУ».
7.15 «Планета Ай».
7.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты.». 6+
8.00 «Круиз-контроль». 12+
8.30 «География вкуса». 12+
8.45 «ВО САДУ ЛИ, В ОГОРОДЕ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КОВЧЕГ». 12+
14.30 «Голливуд страны советов». 12+
14.45 «Блин. Ком». 16+
15.45 «НЕЗНАКОМКА В ЗЕРКАЛЕ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОФЕЛИЯ». 16+
22.40 «БЕСКОНЕЧНОСТЬ: СУБЪЕКТ НЕИЗВЕСТЕН». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 23.35 Подкаст.лаб «Антропология». 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.10 К 80-й годовщине начала Курской битвы. «И плавилась броня». 12+
15.10 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ОГНЕННАЯ ДУГА». 12+
17.00 «Мина в сердце». 16+
19.00 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
21.00 «Время».
22.35 «СЕРЕБРЯНЫЙ ВОЛК». 16+

«РОССИЯ»

6.05 «МАЛАХОЛЬНАЯ». 16+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.40 «Доктор Мясников». 12+
12.45 «СТЕНОГРАММА СУДЬБЫ». 16+
17.50 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Тайна третьей планеты».
7.25 «ОСЕННИЕ УТРЕННИКИ».
9.40 Диалоги о животных.
10.20 Тайны старого чердака. «Портрет».
10.50 «ГАРАЖ».
12.30 Человеческий фактор. «Подкова доброты».
13.00 «Год цапли».
13.55 «Игра в бисер» «А.С. Пушкин. «Полтава».
14.35 «Полтава».
15.50 Линия жизни.
16.40 «СОРОКА-ВОРОВКА».
18.00 «Пешком...»
18.35 Концерт Тамары Синявской и Муслима Магомаева. 1989 г.
19.30, 19.45 Новости культуры.
20.25 90 лет со дня рождения Элема Климова. Острова.
21.05 «ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ, ИЛИ ПОСТОРОННИМ ВХОД ВОСПРЕЩЕН».
22.15 Асмик Григорян в опере «Русалка». Королевский оперный театр «Реал» (Мадрид).

«НТВ»

4.45 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.50 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.40 «ПРАКТИКАНТ-2». 16+
23.45 «Маска». 12+

Кышкы салкын кичтә Валентин Евдокимов урамга чыга, саф һава суларга чыгуы түгел, махмыр дигән зәхмәт артыннан төртә. Өйдә утырсаң китереп бирүче булмас, ә монда таныш шешәдәшләр, дус-ишләр очрар да баш төзәтү мөмкинлеге туар дип фикерли ул. Ләкин Азнакайның шул тирәдәге урам вә ишегалларын урап чыкса да, өметләр акланмый, хәлен аңлардай кеше күренми. Үз гомерендә күпне күргән 1959 елгы абзый бирешергә, башын түбән иеп өенә кайтып китәргә җыенмый.

Угры урый урамнарны

Беренче тапкыр 1985 елда хөкем ителә ул. Ул чакта 25 яшендәге егет исерек килеш милиция хезмәткәре белән бик хәтәр бәргәләшкән өчен ике елга утыртыла. Аннан кайткач эшләмичә эчеп йөргән ир-ат ул заманнарда ЛТП буларак мәгълүм хезмәт белән дәвалау оешмасына озатыла, ләкин сәрхүшләр профилакториеннан качып кайта һәм моның өчен совет законнары нигезендә ярты елга колониягә ябыла. Аннан чыккач тагын ЛТПга урнаштырыла, кабат табан ялтырата. Бу юлы бер елга ирегеннән мәхрүм ителә. 2000 елда төркем белән кеше талауда катнашып өч елга утыртырга дигән хөкем ала, әмма амнистия буенча әлеге җәзадан азат ителә. Әйтергә кирәк, акылга утыра дип булмаса да, шуннан соң җинаять җаваплылыгына тартылмый ул. Ләкин 2023 елга кадәр дип өстәргә туры килә.

21 февраль кичендә теләгәнә ирешә, ягъни бер чәкүшкә аракы эләктерә Валентин һәм өендә шуны эчеп сәламәтләнгән рәтләгәннән соң йокларга ята. Тиздән бушаган шешәне полиция оперативникларына тапшырырга туры килә, чөнки аны җинаять эшенә «вещдок» итеп теркәргә кирәк була. Чәкүшкә законлы ысул белән кулга төшерелми, димәк.

В. Евдокимов урам буйлап селкенеп йөри торгач, шул яклардагы «Пятерочка» кибетенә барып керә дә, күптәнге танышы вә яшьтәше Рим Җәләевнең сусаганны баса торган эчемлекне алуын шәйли һәм шактый явыз ысул белән шешәне тартып алу планын кора. Шул нияттән, кеше-кара күргәнче кибеттән чыгып шыла, арткы якта өелгән тартмалар һәм башка чүп-чар арасыннан саллы гына агач борыс табып ала.

Ул арада аз-маз салмыш Р. Җәләев кибеттән чыгып туры сукмак буйлап өенә таба тәпили, әлбәттә, артыннан калын такта тоткан В. Евдокимов килә дип уйлап та карамый, бер мәлне туктап чүгәли дә хәл алырга керешә, шул рәвешле, эзәрлекләүчегә эшне җиңеләйтеп куя. Кыскасы, Валентин борыс белән баш түбәсенә кундырып, чынлыкта, утырган Җәләевне карга мәтәлдерә, шешәле яшел пакетны эләктереп табан ялтырата. Рим агайның әйтүенчә, ул бик тиз аңына килә, китеп баручы ир-атны да күрә, өенә кайтып полиция һәм ашыгыч ярдәм чакыра. Табибләр баш түбәсендәге канлы яраны эшкәртеп, авыруны район сырхауханәсенә илтә. Эксперт аның сәламәтлегенә җинел зыян китерелгән дигән нәтиҗә ясый.

Оперативниклар такта белән тондырып 239 сумлык «Тундра»ны чәлдергән кешене тиз таба. Чөнки ул «Пятерочка»дагы һәм үзе яшәгән йорттагы видеокүзәтү җайланмалары язмасына эләккән була. Даими сатып алучыларны супермаркет хезмәткәре дә күреп һәм хәтерләп калган булып чыга. Шулай итеп абзыйга гаебен танып тәүбә итәргә туры килә.

Р. Җәләев рәсми күрсәтмәсендә, күрәсең, тикшерүче соравына җавап биреп, мин аңа башыма такта белән орырга һәм аракымны алырга рөхсәт итмәдем, дип белдерә. Ошбу сүзләр сәеррәк күренсә дә, чынлыкта, корал рәвешендәге әйбер кулланып кеше гомере һәм саулыгы өчен куркыныч һөҗүм, ягъни разбой дигәнне аңлата. Тикшерү комитетының Азнакай районара бүлегеннән Раил Зарипов В. Евдокимовка шундый житди җинаятьтә гаепләү белдереп бер атна дигәндә эшне суд карамагына тапшыра. Анда исә такта белән сугучыга таякның юан башы эләгә, В. Евдокимов 64 яше тулган көннәрдә ике елга ирегеннән мәхрүм ителә. Яклау ягы мөрәҗәгате буенча җинаять эше Татарстан Югары судында да каралачак. Әмма хөкем карарына үзгәреш кертелү ихтималы юк дәрәҗәсендә.

* * *

Урамнарда селкенеп йөреп төрле явызлыклар кылучылар арасында яшүсмерләр, хәтта малай-шалай да еш очрый. Узган елгы көзге кичләрнең берсендә Бөгелмә эчке эшләр бүлегенә Юлия исемле ханым шалтыратып, үзенә һәм әтисенә 15 яшьләрендәге ике малай һөҗүм итүе, телефон һәм башка әйберләрен талавын хәбәр итә. Өстәвенә, аларның берсенең әнисе Светлана исемле икәнен, аның «Лада Гранта» машинасында йөрүен, фатирын әйтә алмаса да, кайсы йортта яшәвен дә житкерә. Шуңа күрә полиция 8 нче сыйныфта укучы малайларны тиз таба. «Бристоль», «Рыбный мир» кибетләре бинасындагы видеокүзәтү язмалары вакыйганы ачыкларга мөмкинлек бирә.

Ул кичтә тегендә-монда сугылып йөргән малайлар ике ир-аттан тәмәке сорап тарта, «юмарт» бәндәләр аларны сыра белән дә сыйлый, кулларына бер банка шул эчемлекне тоттырып җибәрә. Әлбәттә, батырайта, канатландыра кәттә «егетләрне» сыра. Эзләгән таба дигәндәй, сәбәбе дә килеп чыга. Кибет каршында туктаган машинадан өлкән яшьтәге ике абзый төшеп кала, кызмача яшүсмерләр алардан тартырга сорый, 1967 елгы Сергей Кабалин үзләренең тәмәке алырга килүләрен әйтеп гозерне кире кагу гына түгел, малайларга ничә яшь икәнен сорый, унсигез, дигән җавапны ишеткәч, алайса сатып алыгыз, дип кибеткә кереп китә. Тегеләр ошбу дорфалыкны кимсетү дип кабул итә һәм моны җәзасыз калдыра алмый. Кибеттән алданрак чыккан В. Исмәгыйлев малайларга сигарет бирә үзе, ә алар С.Кабалинны көтә. Шул арада бераз читкәрәк абзыйларны китереп куйган «Лада-Веста», димәк, безгә полициягә шалтыратучы буларак мәгълүм Юлия, С.Кабалинның кызы килеп туктый. Агайлар шул якка юнәлгәч, «разборка» башлана, озынрак буйлы Тимур Мөхәммәтҗанов (балигъ булмаганнарның исемнәре үзгәртелә) С.Кабалинга җикеренә башлый, бераздан сугарга да керешә. Аңа дусты Иван да кушыла. Анысы Кабалинга типкәләп алганнан соң В.Исмәгыйлев белән тарткалаша. Кыскасы, Бөгелмәнең Ленин урамында шау-шулы тамаша башлана.

Алдан әллә ни активлык күрсәтмәгән Сергей, авыз-борыныннан кан киткәч, кабының китеп озын хөрәсәнгә әйбәт кенә эләктерә, бер мәлне алар икәүләп асфальтка егылып тузан туздырып әүмәкләшә, явыз Тимур яткан килеш әллә ни сугыша алмый, өстәвенә, машинасыннан атылып чыккан Юлия әстери, йолкый аны, ахыр чиктә, саллы гына гәүдәсе белән өстенә егылып бөтенләй аста калдыра. Ошбу кәмит 10 минут чамасы дәвам итә. Көрәш-сугыш барышында билдән югары киемнәре салынган Сергей агай машинага кереп утыра, бер ботинкасы төшеп калган Тимур дусты белән читкәрәк тайпыла, ләкин тиздән йөгереп килеп Кабалинның аунап яткан футболка, олимпийка һәм барсеткасын эләктереп чаба.

Бусы инде куышлы тамаша башлануын белдерә, чөнки «Лада Веста» табан ялтыратучылар артыннан китә, аның тәрәзәсеннән тегеләргә төбәп яман сүзләр оча. Эзәрлекли торгач, машина туктый, аннан атылып чыккан чая хатын угрыны куып тотып әйберләрне тартып ала. Иван юкка чыгып өлгерә, ләкин Юлия аның танышы Светлана малае икәнен танып калган була инде.

Шулай итеп вакыйга «кыю» малайлар файдасына тәмамланмый. Т.Мөхәммәтҗанов олимпийка, футболка, барсетка, андагы телефон, 3800 сум акча, димәк, җәмгысе 13800 сумлык матди байлыкны талаган булып чыга. Хатын-кызның бик кыю эш итүе нәтиҗәсендә ошбу әйберләрне үзләштерә алмый ул. Шуңа күрә җинаять эше дә таларга омтылыш ясау очрагы буенча кузгатыла. Алданрак җинаять икәүләп, ягъни төркем белән кылынган дип исәпләнә, ләкин тикшерә торгач, Иван шаһит итеп калдырыла. Әлбәттә, ике чабата – бер кием, дигәндәй, ошбу малай бөтенләй үк гаепсез дигәнне белдерми бу. Шулай итеп 8 нче сыйныфта укучы Тимурга аңа бәйле булмаган сәбәпләр аркасында барып чыкмаган талауда гаепләү белдерелә. Әнисе соңгы вакытта юньсез малайлар белән аралашуы аркасында тәртибе бераз начараюын искәртсә дә, улын үтә уңай бәяли, төрле түгәрәкләрдә, спорт секцияләренә йөрүен, ярышларда катнашып уңышларга ирешүен сөйли, бары тик укуы ни дәрәҗәдә икәненә тукталып тормый. Ана кеше бәлагә юлыккан баласы турында начар сөйләми инде ул, җинаять эше кузгатылып эшләр зурга киткәч малаеның уңай якка үзгәрүен дә белдерә. Ләкин аның 55 яшьлек абзыйга карата кылган явызлыклары тынычланырга урын калдырмый.

Әлеге очрак юньсез малай өчен яхшы тәмамлана. Ана гозерен тыңлап зарар күргән як хөкем ителүчене җәзасыз калдыруны сорый. Бөгелмә шәһәр суды якларның килешүе сәбәпле дигән билгеләмә белән аңа 16 яшен тутырган яшүсмергә карата җинаять эзәрлекләвен туктатырга дигән карар чыгара.

Наил ВАХИТОВ.

Мәдәни җомга

Курчак кына димәгез

«Курчаклар ясау белән мин егерме ел шөгыльләндем, – диде Светлана Маликова. – Ә менә соңгы вакытта агачтан ясалган чәй йортларын декупаж ысулы белән бизәклим. Мин сәнгатьтәге төрле юнәлешләрне өйрәнеп карадым, әмма күбесенә карата кызыксынуым сүрелә барды. Кечкенә чактан ук нәрсә булса да иҗат итәргә омтылдым. Матур рәсемнәрне альбомга күчереп ясарга ярата идем. Дүрт ел Казанның 2 нче балалар сынлы сәнгать мәктәбенә теләп йөрдем. Урта мәктәптән соң, бәлкем, Казан сынлы сәнгать училищесына кереп, рәссамлыкка да укып чыккан булыр идем, тик тиз арада гаилә кордым һәм укырга җай чыкмады. Гаиләдә ике ир, ике кыз бала үстердек. Улларыбыз – башка һөнәр ияләре, ә менә кызларым сәнгать юлын сайлады: берсе – дизайнер, икенчесе – сынчы. Декрет ялында чакта иҗат итеп карау теләге көчәйде. Шулай итеп, курчак ясау серләренә төшенә башладым».

Беркөнне әтисе Светлананы телевизор каршына чакырган. Мәскәүдә курчак ясарга өйрәтү курсы эшләве турында сөйлиләр икән. Әтисе кызына шунда укып кайтырга киңәш иткән. Светлана Мәскәүгә шылтыратып, курс җитәкчелеген эзләп тапкан һәм 2003 елда Мәскәүгә барып, курчак ясау нечкәлекләрен өйрәнгән. «Мин соңрак та башкалага еш бардым әле. Танылган курчак осталарыннан да дәресләр алдым. Бу сәнгать юнәлеше ул чакта Казанда популяр түгел иде. Курчак осталары хакында ишеткәнем дә булмады. Һәм мин беркемне дә үз артымнан ияртә алмадым. Чөнки курчак ясау – кыйммәт сәнгать төре, моның өчен кирәкле материаллар чит илләрдә җитештерелә. Югары температура кулланып чыныктырылган пластика (полимер балчык), тукымалар, сыйфатлы буяулар берсе дә арзан тормый. Аннары бу юнәлештә иҗат итүче холкы белән дә бик сабыр булырга тиеш. Күз күреме яхшы булу да сорала. Оста иҗатында һөнәрчелекнең күп төрләрен куллана: курчакларның кием-салымын, баш һәм аяк киемнәрен үзе тегә, чәч рәвешен ясый, фигураны килешле итеп буйый һ.б.»

«Бервакыт, Казанның меңьеллык бәйрәме алдыннан, миңа Президентыбыз Минтимер Шәймиев образын Татарстан дигән зур корабны алга алып баручы адмирал кыяфәтендә ясарга тәкъдим иттеләр. Башта каушап калдым, бу минем өчен зур җаваплылык иде. Аннары тәвәккәлләдем. Нәтиҗәдә, Президентның образы әзер булды. Шәймиевкә бу үзенчәлекле бүләк бик ошаган икәнен аңладым: бүләкне тапшырган мизгелнең фотосурәте бер журналда нәшер ителде.

Шуннан соң Рөстәм Миңнехановка охшаш курчакны да ясадым. Беләм, портретка карап ясаучы осталар бик күп түгел, мондый заказларга алынырга атлыгып тормыйлар, чөнки бу – прототипның образын төгәл иҗат итү, башкалар ышанычын аклап чыгу да бит әле...»

«Кызыклы, юмор хисе кушылган образлардагы курчакларны да теләп ясадым, әйтик, «Бөҗәкләр» сериямне күпләр ошатты. Балачактан ук шундый әкияти дөньяга гашыйк кеше мин. Курчаклар ясау – бер караганда, ул үзенә нык җәлеп итә торган процесс, ул – башкаларны кабатламыйча, үз сәләтләреңне үстерә белү дә, ә менә икенче яктан, әлеге юнәлештә, минемчә, бер төп шарт бар – бу сәнгать бары тик игелеккә генә илтергә тиеш. Шуңа күрә теләсә кайсы сәнгати образ рәссам-останың үз эчке дөньясы чагылышы да булып тора, әлбәттә».

Оста ел ярым «Әкият» дәүләт курчак театрында рәссам-бутафор булып эшләп алган. Үз сәләтен балалар өчен китапларны бизәп тә раслаган. Татарстан Милли музее өчен буклет, музей эшчәнлегенә багышланган китапны нәшер итүгә дә үз өлешен керткән.

«Курчаклар ясау белән мавыксам да, Россия күләмендәге зур күргәзмәләрдә катнашканым булмады. Бу көннәрдә кызым Альбина чынаяклар ясарга тәкъдим итте әле. Аларны үзле балчыктан эшләп караячакмын, күптән түгел керамика курсын тәмамлаган идем. Иҗат күпкырлы булганда гына мавыктыргыч бит ул!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.



ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 30.06.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2624

16+